Безнең МИРАС

11

ноябрь 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

22 октябрь көнне Әлмәттә 10 нчы тапкыр Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияне тапшыру тантанасы булды. Кичә барышында «Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе Рөстәм Мөхәммәдиев яңа лауреатларны котлады, истәлекле бүләкләр тапшырды.

Киләчәккә әйди «Рухият»...

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
11(46)
ноябрь 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

68



38 ГАМБӘР МУЛЛА.
Ринат Фәхретдинов

108 ШАМАИЛ.
Гүзәлия Җәләлева

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Шагыйрьләр.** *Ә.Атнабаев*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Көнчыгыш төрбә.** *Н.Шәйдуллина*
6 **«Хак хөкменә коллар риза булу кирәк...»** *А.Мөхәммәдиев*
14 **Грюнвальд аланында татар җайдаклары.** *Г.Гарифуллин*
19 **Төрек вә татар тарихы.** *Ә.Вәлиди*
22 **Зөһрә Акчуринаның әнисе Фатыйманың кабер ташы.** *Н.Таиров*
24 **Татар халкының сармат бабалары.** *Ф.Гарипова*

ТАТАР ГАМЕ

30 **Казанга Гаспринский скверы кирәк!** *С.Таишева*
35 **Рафаэль Мостафин: «Әниемә минем исем ошамаган».** *Ф.Дәминова*
38 **Гамбәр мулла.** *Р.Фәхретдинов*
44 **Арт капкадан кергәндә...** *И.Кыямов*
51 **Хәтер-хатирә.** *Н.Вилданова*
53 **Таҗи Гыйззәт исемендәге тәүге премия**
54 **Муллалар илендә**
56 **«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсының йомгаклары**

ПЕДАГОГИК МИРАС

57 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре.**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

58 **Сүз һәм сурәт.** *М.Имашев*

ӘДӘБИ МИРАС

60 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
64 **Кыйссаи Таһир илә Зөһрә.**
68 **Сәнәкчеләр.** *З.Мөэминов*
74 **Бәрәкәтле Оренбург туфрагы.** *Л.Хәмидуллин*
82 **Алтынга бакыр ябышмый.** *М.Галиев*
85 **Мөдәмил Әхмәтовның язма мирасы.** *Л.Лерон*
88 **Хушлашырга ашыкты...** *А.Хәмзин*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

91 **Тукай энциклопедиясе.** *Р.Харрасова*
92 **Салих абый Сәйдәшев белән очрашу.** *Н.Фәттах*

СӘНГАТИ МИРАС

94 **Сәет белән Бикә.** *Р.Сәгъди*
96 **Моң иясе.** *К.Саттаров*
110 **И җыр гынам, җырым...** *Г.Ибушев*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

100 **Ач сереңне, илаһият!..** *Р.Низами*

ТАБИГЫЙ МИРАС

104 **Кызыл Байрак авылы**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

106 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 **Шамаил.** *Г.Җәләлева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның ноябрь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Ноябрь*

Заказ №О-3099. Тираж – 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 02.11.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, авторларның, Г.Камал театры һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Акмулла. Халык шагыйре». 2010.
Киндер, майлы буяу. *А.Абзгильдин рәсеме.*



Әнгам Атнабаев
(1928-1999)

ШАГЫЙРЬЛӘР

Күптөрле заманнар булганнар.
Күптөрле шагыйрьләр туганнар,
Берәүләр үзләрен сатканнар,
Берәүне базарда сатканнар,
Берәүләр үзләрен атканнар,
Берәүне дуэльдә атканнар,
Берәүләр үзләрен асканнар,
Берәүне мәйданда асканнар.

Кап-кара заманнар булганнар,
Яп-якты шагыйрьләр туганнар.

Замана тудыра шагыйрьне,
Шагыйрьләр күтәрә заманны,
Күтәрә халкының күңелендә
Бикләнеп йоклаган аңнарны.

Күтәрә үлемле яуларга,
Җиңүле таңнарга күтәрә,
Халкына атылган укларны
Йөрәге аркылы үткәрә.

Шагыйрьне патшалар тыялмый.
Төрмәләр, палачлар куркытмый,
Тукайлар кулында кылычлар
Сынсалар сыналар — тутыкмый.

Сап-салкын зинданда шигырьләр
Язылa ташларга уеп та;
Җәлилләр язганнар җырларын,
Башларын балтага куеп та.

Шагыйрьләр — халыкның намусы,
Халыкның сәяси солдаты.
Узганнар заманнар өстеннән,
Елларын көмештәй чыңлатып.
Яшәгән халыкны җырлатып,
Үлгәннәр халыкны елатып.

Күптөрле заманнар булганнар,
Күптөрле шагыйрьләр туганнар,
Шагыйрьләр туганнар,
булганнар һәм барлар.

БОЛГАР. КӨНЧЫГЫШ ТӨРБӘ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Көнчыгыш төрбә (Никола чиркәве) ак таштан, урта гасыр көнчыгыш мөселман төрбәләре тибында — чыгарылма порталлы итеп төзелгән. XIY гасырның 30 нчы елларында корылган. Эчке өлешендә ярымсфера рәвешендәге гөмбәзе бар. Диварның периметры буенча билгеле бер урыннарына балчык савытлар уелган. Портал уемы тоташтырылган керү өлеше көньякка юнәлтелгән. Бинаның турыпочмаклы формасы кыйшату нәтиҗәсендә салмак кына сигез кырлы рәвешкә күчә. Туф кирпечләрдән төзелгән ярымсфералы гөмбәз яхшы сакланган.

Күләм-план төзелмәсе буенча Көнчыгыш төрбә — Урта Азия төрбәләренә, ә төзелеш материаллары, техник алымнар һәм деталь формасы буенча Кавказ арты һәм Кырым төрбәләренә охшаш.

1712-1735 елларда, Болгар шәһәрлеге территориясендә Успение монастыре булган чорда, Көнчыгыш төрбә православие храмына әйләндерелә. Бу тарихи ядкяр археологлар тарафыннан 1964-1966 елларда һәм 1991 елда тикшерелгән. Биредә Алтын Урда чорына караган агач һәм таш төрбәләрнең җидесенең сакланып калган өлешләре чистартылган, кайберләрендә күмелгән кешеләрнең сөякләре табылган. Реставрация эшләре 1967-1968 елларда үткәрелгән, ә 2011-2012 елларда төрбәнең нигезен ныгыту, уратма галереяны урнаштыру буенча ашыгыч төзекләндерү-коткару эшләре башкарылды. Төрбәнең эчке һәм тышкы диварлары махсус эретмәләр белән эшкәртелде, нигезе төзекләндерелде. Объект музейлаштырылды — анда мультимедиа экспозициясе булдырылды. ■

Кол Гали. Бакый Урманче эше. 1965 ел



«ХАК ХӨКМЕНӘ КОЛЛАР РИЗА БУЛУ КИРӘК...»

(Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә нигезләнеп Идел болгарларының хокукый мөнәсәбәтләрен өйрәнү)

Алмаз Мөхәммәдиев,
тарих фәннәре докторы

Идел болгарларының хокук тарихы буенча хезмәтләр язылмауның бик күп объектив һәм субъектив сәбәпләре бар. Шуларның берсе – күршеләрдәге «Русская правда» һәм Дунай Болгарстанындагы «Закон судный людям» кебек язма чыганакларның сакланмавы. Гарәп яисә урыс истәлекләрендә дә бабаларыбызның хокукый мөнәсәбәтләренә кагылышлы хәбәрләр чәчелгән, сибелгән – фрагментар рәвештә генә урын алган.

Димәк, бу өлкәне өйрәнергә теләгән кешегә өстәмә (халык авыз иҗаты, әдәбият, этнография) һәм «кыек» (тугандаш халыкларның хокук тарихы) чыганакларга мөрәҗәгать итми чара юк. Тәгаен безнең очракта, мәсәлән, Кол Галинең XIII гасыр башында туган «Кыйссаи Йосыф» әсәре шактый ярдәм күрсәтергә мөмкин. Игътибар белән укысак, без анда гаиләгә, сәүдәгә караган байтак мисаллар, борынгы ватаныбызда очраган җинаятьләр һәм җәзалар, гадел хөкем, шәхесара килешүләрнең төп принциплары, кагыйдәләре һ.б. турында бихисап мәгълүмат таба алабыз.

Шиксез ки, сюжет беренче чиратта никах (өйләнешү) һәм гаилә кору проблемаларын күтәрә. Истә тотыйк: поэма Идел Болгарстаны мөселманлык кабул иткәннән соң язылган, шуңа күрә әлеге әдәби җәүһәрдә болгарлар арасындагы хокукый мөнәсәбәтләрнең ислам кануннарына нигезләнеп бирелүе табигый.

Әсәр бик зур җәмгыяви-әхлакый һәм фәлсәфи көчкә ия. Урыс телендә чыккан китапның кереш сүзендә Нурмөхәммәт Хисамов әйткән фикер белән килешми ярамый — чыннан да, Кол Гали, үзе шуңа ихлас инанган халәттә, сәламәт һәм бәхетле гаиләнең нигезе итеп бердәнбер мәхәббәт идеясен алга сөрә[1]. Автор, һичшиксез, халык арасында ислам динен популярлаштыру тарафдары булуга карамастан, «Кыйссаи Йосыф», нигездә, барыбер дөньяви эчтәлекле, рациональ юнәлешле иҗат җимеше. Әсәр гуманист тәрбияләүне, халыкның һәм дәүләтнең иминлеге шартларын икърарлаудан тыш, гадел җәмгыять төзү, камил гаилә мөнәсәбәтләрен кору үрнәген күрсәтүне — ягъни, «тормыш дәреслеге» вазифасын үтәүне максат итә. «Кыйссаи Йосыф»ка татар халкының бөек әдәби һәйкәле итеп карау гына аз, аның әле болгар чоры тарихын өйрәнүдә бәһасез чыганак икәнен дә хәтердә тоту зарур.

Поэмада гаиләгә аерата зур игътибар бирелә, дидек. Гайнетдин Әхмәров XIX гасырда Казан татарлары арасында кыз алуның өч төре киң таралганлыгын әйтә: кызның (туганнарының да) теләгенә каршы килеп урлау, кызның ябышып чыгуы, димләп өйләнешү[2]. Бу йолаларның тамыры бик тирәнгә — төркиләрнең мәҗүси чорына ук барып тоташа һәм, табигый, болгарлар ислам кабул иткәннән соң да ул гореф-гадәтләр эзсез югалмый әле, берникадәр үзгәрә генә.

Димләү турында. Гаилә корганда шәригать ике якның да бу никахка ризалыгын мәҗбүри шарт итеп куя. Мөселман болгарлар да, күпчелек очракта, гади-гадәти димләү ярдәмендә башлы-күзле булган булса кирәк (мисал өчен, К.Ф.Фукс, XIX гасыр башы Казан татарларын сурәтләгәндә яучылап өйләнешү турында яза: кияү җибәргән яучы кәләш йортына килә һәм шунда ук, беренче килүдә, йә ризалык, йә ризасызлык алып китә. Ризалык алу исә ике якның калым турында килешүенә нигез булып тора[3]. «Кыйссаи Йосыф» та нәкъ менә шушы төр кыз алуның болгарлар арасында киң таралганлыгын раслый. Зөләйхәгә бик күп димчеләр килүен искә төшерик:

Нәкъ егерме җиде бәктән ***ялавачлар***[4]*,*
Һәрберсенең башларында алтын таҗлар,

[1] Кул Гали. Сказание о Йусуфе (перевод Сергея Иванова). — Казань: Татарское книжное издательство, 1985. — С.11.

[2] Ахмеров Г.Н. Избранные труды. — Казань: Татарское книжное издательство, 1998. — С.191-192.

[3] Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань, 1844; Краткая история города Казани. Казань, 1905. Репринтное воспроизведение. — Казань: Фонд ТЯК, 1991. — С.66.

[4] Ялавачлар — илчеләр, яучылар.

Казыйга киңәш-табышка килү. 1335 ел

Китергәннәр күптөрле мал, алтын хачлар,
Барчасы да Зөләйхәне сорый инде.

Һәрбересе бер мәликтән килгән иде,
Зөләйхәне хатынлыкка ***димләр*** *иде,*
Ә Зөләйхә атасына болай диде:
«Мисырдагы гъәзиз мине алсын инде».

Ике строфадан соң янә:

«Күп солтаннар ***сорый*** *үзен — кызым бармый,*
Тик берсен дә өстен күреп, күңел салмый,
Сине генә хәтереннән һич чыгармый,
Теләр булсаң, безләргә тиз белдер инде»[5].

Бу очракта без яучы җибәрү, димләү кебек күренешләргә юлыгудан битәр, никахлашканда кызның фикере дә исәпкә алынуын, хәтта ул фикернең мөһим, хәлиткеч булуын күрәбез. Кызның кияүне кабул итәргә, яисә, киресенчә, кире кагарга хаклылыгы халык авыз иҗаты үрнәкләрендә дә ярылып ята. Мисал өчен, XIII гасырның икенче яртысына караган «Хан кызы Алтынчәч» риваяте болгарларның монгол илбасарларына каршы көрәшенә багышланган. Эчтәлектән күрәбез ки: хан кызы монгол ханының хатыны булырга катгыян баш тарта, шуның аркасында ыруглар арасында сугыш куба[6].

Ике як та гаилә корырга күнгәндә никах килешүе төзелгән, андый килешү үрнәге «Кыйссаи Йосыф»та да (Зөләйхәнең әтисе Таймус белән Кыйтфир «кияү» арасында) искәртелеп үтелә:

Ә Мисырда ул чак гъәзиз — Кыйтфир иде,
Илчеләр шул хатны тотып аңа килде,
Хатны укып, ризалыгын шунда бирде,
Җавап язып, илче аша салды инде.

[5] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989. — Б.87-88.

[6] Хан кызы Алтынчәч/ Борынгы татар әдәбияты. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1963. — С.165-167.

«Һәркем мине тели икән, мин дә телим,
Йөз мең теләк белән аны табам, эзлим,
Малым-милкем барчасын да фида кылыйм,
Җаным белән кабул иттем», — диде инде.

Кыйтфирнең бу илчеләре килде исә
Һәм Таймуска шул җавапны бирде исә,
Хатны укып, хәлне аңлап белде исә,
Зөләйхәне юлга җайлап озатты инде[7].

Бу мисал (никах килешүен кызның әтисе белән төзү) — табигый хәл саналырга хаклы, чөнки мөселман хокукы мондый эшләргә хатын-кызның катнашуын кирәк тапмый. Баласын кияүгә бирү шартларын әти кеше сөйләшә һәм «йөрәк мае» өчен мөмкин кадәр күбрәк калым алырга тырыша.

Никах килешүе телдән дә, язмача да төзелергә мөмкин саналган. Алдагы өзектән чыгып фикер йөртсәк, болгар җәмгыяте үсә-үзгәрә барган саен мондый гамәлләр күбрәк язмача башкарылган, дигән фикергә киләбез. Язмача ныгытылган килешү, билгеле ки, рәсми документ буларак, ышанычлырак исәпләнгән һәм килешүдә теркәлгән шартларны ике якның да төгәл үтәвен тулырак тәэмин иткән. Инде гел дөрес булсын, дигәндә, документ кимендә ике шаһит (ир-ат җенесеннән) хозурында казый тарафыннан тутырылган. Туган-тумачалык, потка табыну кебек күренешләр никах укымаска җитди сәбәптән йөргән.

Никах килешүенең болгар җәмгыятендә нинди зур көчкә ия булуын без Йосыф урынына, ялгышып, Кыйтфиргә кияүгә чыккан Зөләйхәне юатучы хатын-кызлар авызыннан ишетәбез:

«Ягъни синең бу хәләлең Кыйтфир була,
Әдәпсезлек эшли күрмә!» — диләр инде[8].

Дөрес, мәҗүси гореф-гадәтләр дә болгарларда озак яшәгән әле. Гамирҗан Дәүләтшин шул чорларга караган «Айбикә» риваятенең бер вариантын ошбу фикергә мисал итеп китерә: әсәрдә явыз Чуракай каракның Алабуга шәһәрендә гомер кичергән мәгълүм затның кызын урлавы турында бәян ителә. Дөрес, һәр әкият шикелле, бу кыйсса да матур тәмамлана — батыр егет Чуракайны җиңеп, кызны әтисенә кайтарып бирә[9]. Мәгәр мондый мәҗбүри, кыз теләгенә каршы кылынган гамәлдән «кыз урлау» йоласын аера белергә кирәк: икенче очракта кәләшне ике якның да ризалыгы белән «урлыйлар», шуңа күрә ул шәригать кануннарына каршы килми.

Тарихчылар күрсәтүенчә, хәтта XV-XVIII гасырларда да Казан татарлары арасында яшьләрне мәҗбүри өйләндерү гадәте хөкем сөргән — ни егетнең, ни кызның рөхсәтен-ризалыгын сорап тормаганнар. Нәтиҗәдә, сирәк булса да, «качып» (әти-әни, туганнарга белдермичә) никахлашу күренеше барлыкка килгән.

Шәригать кануннары буенча, никах укылганнан соң ир-ат хатынына *мәһәр* (кияүнең кәләшкә бирәсе милке, малы) түләргә тиеш. Болгар дәүләтендә (һәм башка төрки халыкларда да) бу йола *калым түләү* белән кушылган, ике институт берләшкән. Калым күләме кызның сыйфатларына карап билгеләнгән (яшьлеге,

[7] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.88-89.

[8] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.89.

[9] История татар с древнейших времён в семи томах. — Том I. Народы степной Евразии в древности. — Казань: Издательство «Рухият», 2002. — С.576.

чибәрлеге, ата-анасының мәртәбәлелеге, хокукый дәрәҗәсе) һәм өлкән яшькә таба кими барган. Тол хатыннар да калым дәгъва итә алган. Калым никахлашуның хокукый нигезләреннән саналган, аннан башка никах кылынмаган.

«Кыйссаи Йосыф»та яучыларның Зөләйхәгә *«күптөрле мал, алтын хачлар»* китерүен дә без «кияүләрнең» мәҗбүри төстә калым (мәһәр) түләве, дип санарга хаклыбыз.

Кәләшнең бирнәсе ата-ана мал-милкеннән дә, кияү биргән калым өлешеннән дә тупланырга мөмкин булган. Хәер, мөселман кануннары, гомумән, андый күренеш турында искәртми, бу хакта сүз йөртүне әдәпсезлек саный һәм аны тулаем эти-әни теләгенә вә ихтыярына тапшыра. Әмма без бирнә китерүнең болгарлар арасында киң таралганлыгына «Кыйссаи Йосыф»ны укып инана алабыз:

«Мин кызымны хакыйкатьтә сиңа бирәм,
Мең дөялек йөк җиһазы булыр ***бирнәм.***
Мең качырга йәнә күп мал төяттерәм,
Дөя йөге асыл ефәк була инде.

Тагы мең кол, мең карауаш[10] *бүләк була,*
Һәрчак алар кул астыңда хезмәт кыла,
Алар даим сезгә тугры башын ора,
Кайсы хыта[11]*, кайсы руми*[12] *була инде»*[13].

Мең дөягә маллар төяп йөкләттерде,
Аларга мең кол-карауаш атландырды.
Шул рәвешле кыз Мисырга килеп керде,
Сарайда ул тәхет куеп утырды инде.

Мәҗүсиләрдән аермалы мөселман болгарларда баланы бабай (әнисенең этисе) түгел, ә, яңа тәртип буенча, ата үзе тәрбияләргә тиеш булган. «Кыйссаи Йосыф»та да һәммә нәселе өчен Йагъкуб җаваплы. Ул чын ата. Зөләйхә үлгәч, Йосыф турында да шулай әйтелә: *«угъланнарын тәрбияләп яшәде инде»*[15]. «Котадгу белек»тә Й.Баласагуни балаларны, бигрәк тә кызларны, өйдә тәрбияләргә, аларга күркәм сөт анасы табарга, сәламәтлекләрен кайгыртырга, гыйлемгә өйрәтергә кирәк, дип яза. Угыллар эшсез утырмасын, аларны вакыт җитүгә өйләндерү, ә кызларны кияүгә бирү зарур, ди[16].

Болгар җәмгыятендә ата-ана үз баласына карата игътибарын кызганмаган, бәгъзе гаиләләрдә йә сатып алынган, йә ялланган даяларның , тәрбиячеләрнең булуы шуны раслый. Яңадан «Кыйссаи Йосыф»ка мөрәҗәгать итик:

Анасы үлгәч, Йосыф ятим сабый калды,
Йагъкуб сәүче бер карауаш сатып алды,
Карауашны Йосыфына ***дая кылды,***
Ә баласын ул аерып сатты инде[18].

Икенче урында:

«Йагъкуб сәүче мине сатып алган иде,
Йосыфына мине ***дая кылган*** *иде,*
Бәшир атлы сабыемны саткан иде —
Нәкъ җитмеш ел хәсрәтендә янам инде[19].

[10] Карауаш — хезмәтче, кәнизәк.

[11] Хыта — Кытай, кытайлы.

[12] Руми — грек.

[13] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.88.

[14] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.89

[15] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.213.

[16] Баласагунский Юсуф. Благодатное знание. — Москва: «Наука», 1983. — С.344-345.

[17] Дая — сөт анасы.

[18] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.198.

[19] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.200.

Шунысын да онытмыйк: автор *«Йагъкубның бар иде тагын үги кызы»*[20], дип тә искәртә әле. Соңыннан Мисыр хакиме Йосыфның үзен дә «уллыкка ала», Зөләйхәгә әйтә:

«Миннән артык олыла син һәм хезмәт кыл,

Балабыз юк, бу — ***угълыбыз булсын*** инде»[21].

Кол Гали әсәреннән күренгәнчә, төркиләр арасында исламга кадәр яшәгән үги бала тәрбияләү, үстерү кебек игелекле гамәл болгарларда мөселманлыкка күчкәч тә яшәвен дәвам иткән. Йосыф пәйгамбәрнең «уллыкка алынуы» изге китап мотивларына нигезләнгән сюжет сызыгы өчен кирәкле, мөһим деталь, дип тәгаенләгән очракта да, алга таба хуҗалыкта файдалану өчен гап-гади үги кыз тәрбияләү — табигый һәм мантыйкый хәл исәпләнергә хаклы.



Зөләйхәнең бирнәсе. Бохара. XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы

Гаилә кору Коръән һәм Сөннәт тарафыннан хупланганга күрә, башка дин вәкилләрендә даими күзәтелгән ялгызлык-буйдаклык мөселманнар арасында очрамаган, диярлек. Шәригать ир-атка дүрт хатын алырга да рөхсәт итә. Идел Болгарстанына күпхатынлылык хас булуын без «Кыйссаи Йосыф»тан да күрәбез. Әмма бу хәл Болгарда киң таралганмы соң? Ихтимал, юктыр. Чөнки әсәр тулаем бу күренешкә каршы чыга.

Зөләйхә Йосыфның бердәнбер җәмәгате итеп күрсәтелә. Ул иренә уники ул (угыл) алып кайта. Гаилә бәхетен шагыйрь балаларның күплеге белән дә бәйли. Нурмөхәммәт Хисамов билгеләгәнчә, мәхәббәт һәм гаилә темасын яктыртуда Кол Гали үзенең бөек замандашы Низами Ганҗәви белән бер рәттә тора, алар икесе дә һәм иҗатында, һәм тормышта моногамияне яклаганнар. Ачы язмышлар, ата-ул фаҗигасе, җитмеш ел күрешмәүләре — Йагъкубның күпхатынлылыгы аркасында килеп чыккан күңелсезлекләр, дип уйларга да урын бар — аның төрле аналардан туган балалары бердәнбер атаның мәхәббәтен бүлешә алмый һәм, нәтиҗәдә, энеләреннән котылырга ният кыла. Йосыф, билгеле, этисенә капма-каршы рәвештә, әсәрдә үрнәк гаилә башлыгы сыйфатында тәкъдим ителә[22].

Йосыф белән Ибнейәмин — бер анадан, Рәхилдән[23]. Калган улларның кемнән, ничә анадан тууы әсәрдә әйтелми, өчесенең исеме генә мәгълүм: Рауил, Шәмгун, Йәхүдә[24]. Болгарларның

[20] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.24.

[21] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.99.

[22] Кул Гали. Сказание о Йусуфе. — С.11-12.

[23] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.25.

[24] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.29.

берхатынлылык һәм күп балалылыкны хуплавы әсәрнең буеннан-буена ассызыклана, Кол Гали шундый гаиләләр корырга чакыра, дисәк тә ялгышмабыз:

Йосыф әйтте: «Безнең уллар болар бары,
***Барчасы да Зөләйхәдән** туган инде»*[25].

Йосыф хәтта хәләл җефетен җир куенына тапшыргач та икенче хатынга өйләнергә уйламый:

«Озакламый Зөләйхәсе вафат булды,
Ә Йосыфның күңле сагышхәсрәт тулды,
*Шуннан кабат **өйләнмәскә** карар кылды…»*[26]

Гәрчә, шул ук вакытта, бай йортларда хатыннар белән бергә кәнизәк-җарияләр дә булмаган түгел:

Тәңре саклый Кыйтфирдән гел Зөләйхәне,
Йосыф өчен саклый иде шулай аны,
Кыйтфир исә бөтенләй дә белми моны,
Хаҗәт булса, пәри кызы килә инде.

Зөләйхәбез Кыйтфиргә һич буен бирми,
Үзен саклый, һич тә аңа якын килми,
Кыйтфир исә бу әвхәлнең аслын белми,
Җен кызын ул Зөләйхә, дип коча инде[27].

Йосыф Зөләйхәнең кайнар кочагыннан кача. Камалетдин Бәхзад рәсеме. 1488 ел

Гарәп сәяхәтчесе һәм миссионеры әл-Гарнәти язмаларында берничә мәртәбә Саксиндагы төрки (бәлки, болгардыр?) кәнизәк-хатыннарын («кәнизәк-аналар») һәм алардан туган бихисап балаларын искә алып уза. Үзгә урында ул Болгарга килгәнче бер гаиләдән кыз сатып алуы һәм аннан туган үле сабыен өч ай буе җиргә иңдерә алмавы турында яза — «тимердәй нык» туфракны казырлык булмый «…һәм мәет таш кебек ката»[28].

«Хуҗа»дан бала тапкын кәнизәкләр үз ишләренә караганда бер баш үскән, югарырак үр яулаган — аларны ни сатып җибәрә, ни бүләк итә алмаганнар, ә хуҗаларының вафатыннан соң алар, гомумән, азат ителгәннәр.

«Кыйссаи Йосыф»та гаилә мөнәсәбәтләренә караган үзгә күренешләр дә ачыла. Мәсәлән, болгар җәмгыятендә хөкем сөргән

[25] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.202.

[26] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.213.

[27] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.91.

[28] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную Европу (1131-1153).

майорат принцибы. Йосыфның агалары «өлкәнлек хокукы»ның бозылуын, энеләренең киләчәктә үзләре өстеннән хаким булырга тиешлеген күтәрә алмый:

«Әгәр ул төш шулай чынга чыгар булса,
Йосыф олуг бер падишаһ булыр булса,
Без барыбыз аңа хезмәт кылыр булса,
***Бу безгә бик каты гарьлек**», — диләр инде*[29].

Шәригать зинаны иң зур җинаятьләрдән саный. «Кыйссаи Йосыф» та, җәмгыяви-эстетик һәм әхлакый юнәлешле әсәр буларак, бу эшне кабул итми, хыянәтне гаеп, гөнаһ эш саный. Йосыф «киртәне» узмый, чөнки, аныңча (һәм исламча да), болар — ни Аллаһ, ни җәмгыять тарафыннан кичерелерлек гамәлләр түгел:

«Шуның өчен угъыллыкка кабул кылды,
*Атама мин ничек **хаин** булам инде?!»*

***Хыянәтнең әһлен тәңре кичералмый**,*
Газабыннан дошманнарын һич чыгармый...»[30]

«Зина — гөнаһ» мәгънәсендәге гыйбарәләр Кол Гали иҗатында аерата күп очрый:

Кисәтүле аять ачык булды шуннан:
*«**Хак** җәзасын алачактыр гөнаһ кылган»,*
Йосыф нәби бу әхвәлне белде чыннан,
Коткаруны илаһыннан сорый инде[31].

Башка урында:

Йосыф исә азгынлыктан тыелып калды:
*«Бу эшләрне **тәңре күрә**», — диде инде.*[32]

Зина — гөнаһ кына түгел, җинаять тә саналган, дидек. Ул чорның фольклор һәм әдәбият җәүһәрләре, фәнни-дини текстлар мондый җинаятьләрне Идел Болгарстанында гаиләгә һәм әхлакка каршы кылынган гамәлләр исәбендә йөртә[33]. Һәрхәлдә, Ш.Мәрҗани тикшеренүләре аша безнең көннәргә килеп җиткән болгар хезмәтләре (дөресрәге, өзекләре) шулай дип уйларга җитди нигез бирә.

«Кыйссаи Йосыф»та төп каһарман Зөләйхәнең кайнар кочагына аумыйча чак тыелып кала:

Шул ук сәгать дәһшәтле өн яңгырады:
***«Гөнаһка син якын барма!»** — диде инде...*

***«Нәфесеңне уйнаштан тый!»** — диеп инде*[34].

Күрәбез, әсәрдә зинаның гөнаһ һәм җинаять булуын ассызыклаган урыннар бихисап. Ул юлларда «уйнаш» өчен тән җәзасына гына түгел, ә Илаһ Тәгаләнең каргышына да тару куркынычы даими искәртелеп бара.

Ахыры киләсе санда

Публикация О.Г.Большакова, А.Л.Монгайта. — Москва: Главная редакция восточной литературы, 1971. — С.27, 40, 58.

[29] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.24.

[30] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.110.

[31] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.114.

[32] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.115.

[33] Мухамадеев А.Р. Право Волжской Болгарии. Часть 1. Преступления и наказания, правосудие. — Казань: Институт истории имени Ш.Марджани АН РТ, 2013. — С.92.

[34] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.114.

ГРЮНВАЛЬД АЛАНЫНДА ТАТАР ҖАЙДАКЛАРЫ

Гамир Гарифуллин

Германиялеләрнең көнчыгыш тарафка юнәлтелгән яуларының төп кораллы көче дип рыцарь-монахларның хәрби оешмаларын (орден), аерым алганда, прус кабиләләре җирләрендә төзелгән Тевтон орденын (1128) һәм эст, латгал, лив һ.б. кабиләләр биләмәләрендә оешкан Ливон орденын атарга кирәк. Бу ике хәрби-дини оешма 1237 елда Тевтон ордены бөек магистры кул астында берләшәләр. (Өсләрендәге ак плащларына кара тәре сурәте төшерелгәнгә күрә, аларны да «тәре йөртүчеләр» дип йөрткәннәр.)

Тәре йөртүчеләрнең күзе Литваның Балтыйк диңгезенә чыгу юлында яткан һәм Тевтон-Ливон орденнарын бер-берсеннән аерып торган Жмудь өлкәсенә төшә. Бу өлкәне яулап алган очракта, рыцарьларга хакимиятләрен тагын да җәелдерү белән беррәттән, орденнарны бербөтен дәүләткә берләштерү мөмкинлеге дә туар иде.

XIV нче гасыр азагында Литваның бөек кенәзе Витовт (Витаутас) өчен

сәяси вазгыять катлаулана. Шул сәбәпле, ул Жмудь өлкәсен калдырып китәргә мәҗбүр була. Орден шунда ук бушап калган җирләргә үз гаскәрен кертә. Әмма тора-бара җирле халык яңа тәртипләргә түзә алмыйча, туган җирләрен ташлап, Литвага качып китә башлый. Витовт, әлбәттә, качакларны кабул итә. Орден бу уңайдан канәгатьсезлек белдерсә дә, Витовт моңа игътибар итми, ватандашларын яклап чыга. Халыкта бу гамәл орденга каршы баш күтәргән тәкъдирдә, Витовтның ярдәм күрсәтәчәгенә өмет тудыра. Түнтәреш 1409 елның маенда башлана. Баш күтәргән гавам илбасарларны утарлардан сөреп чыгарса, ярдәмгә килгән Витовт гаскәрләре рыцарьларны калалардагы гарнизоннардан куып җибәрә.

Әлеге вакыйгалардан соң, 1409 елның җәендә бөек магистр илчеләре Польша короле Ягайло хозурына килеп, Жмудь өлкәсен югалту сәбәпле, Орденның Литвага каршы сугыш башларга теләвен һәм бу очракта Польшаның үзен ничек тотачагын, ягъни Литвага ярдәм итү-итмәвен белергә телиләр. Беркадәр вакыттан соң илчеләргә Польшаның үз союздашын (бу чакта әле Польша-Литва униясе гамәлдә була) бәладә берүзен калдырмаячагы хәбәр ителә. Шуңа күрә сугыштан тыелып калуны кабул итмәгәч, 1409 елның августында бөек магистр Польшага сугыш игълан итә. Ике як та киләсе 1410 елда буласы бәрелешкә әзерләнә башлый.

И.Литвин «Тевтонский орден» дигән мәкаләсендә сугышка әзерләнүнең бер чарасын менә ничек бәян итә: «1409 елның декабрендә Брест шәһәрендә Ягайло белән Витовт очраша. Алар анда җентекләп тәре йөртүчеләргә каршы яу йөрү планын карап-тикшереп чыгалар. Киңәшмәгә Бөек Литва кенәзлегендә сыену урыны тапкан Туктамыш хан угылы Җәләлетдин дә чакырулы була. Ханзадәгә яу кырына билгеле бер санда атлы гаскәр чыгару бурычы куела. Бу изге гамәле өчен Витовт аны атасының тәхетенә утыртырга вәгъдә итә. Шул хакта рәсми килешү төзелә».

Мәгълүм булганча, Батый хан яуларыннан соң Киев Русе яшәүдән туктый, ә аның территориясенең байтак өлешенә Литва Бөек кенәзлеге хуҗа була. Шуңа күрә, кенәзлек составына этник литва гына түгел, ә хәзерге Белоруссиянең шактый өлеше, шулай ук элеккеге Киев кенәзлегенең «рус» халкы да кергән *(дөресрәге, «русин»нар — Г.Г.).* Алар Польша корольлеге составында да байтак булган. Шул рәвешле, союздашлар армиясенә Польша корольлегеннән, Литва Бөек кенәзлегеннән, Алтын Урда татарларыннан, чех ирекләләреннән һәм башка этник төркемнәрдән торган җыелма гаскәр кергән.

Тәре йөртүчеләр ярдәм сорап католик илләргә мөрәҗәгать итәләр. Чакыру авазына колак салып, Европаның төрле почмакларыннан маҗара эзләүче рыцарьлар килеп җитә. Әмма ярдәмгә килгән көчләрнең иң зурысын герман җирләреннән җыелган немец рыцарьлары тәшкил иткән.

Висла елгасы буенда урнашкан Червинск шәһәреннән союздашларның берләшкән гаскәре орденның башкаласы Мариенбургны (хәзерге Мальборк) күздә тотып, Пруссия җирләренә яу сәфәренә кузгала. Юл өстендә, Грюнвальд авылы янында аларны бөек магистр Ульрих фон Юнгинген җитәкләгән тәре йөртүчеләр каршы алып, Мариенбургка юлны бикләп куя.

Тарихчы галимнәр якларның көчләр нисбәтен болай фаразлый: Тевтон ордены армиясендә 27 мең, ә союздашлар гаскәрендә, Җәләлетдиннең 3 мең җайдагын да кертеп барлыгы 31 мең кеше исәпләнгән. Тикшеренүчеләр шуны да билгеләп үтә, поляк — литва — татар җыелма гаскәре сан ягыннан күбрәк булса да, баштанаяк коралланган, үзләре генә түгел, атларын да тимергә төргән тәре йөртүчеләр хәрби

осталык буенча да, кораллану ягыннан да, аеруча литвалылардан, шактый өстен торган.

Орден гаскәре якындагы урман аланында, биегрәк урында ике рәт булып тезелә. Аның Грюнвальд авылы белән янәшә булган уң флангысын урман ышыклый, ә сул кырые Танненберг авылына килеп терәлә һәм Марша елгасы буендагы сазлыклар белән ышыклана. Сафлар алдында бер сызыкта йөз туптан (бомбарда, татарча «түфәк») торган артиллерия урын ала. Туплар арасында җәяүле укчыларны һәм арбалетчыларны бастыралар. Иң алда яшерен «бүре базлары» казыйлар, аркылы-торкылы аударылган агачлардан тоткарлыклар ясыйлар.

Союздашлар тәре йөртүчеләр торган аланга 15 июльнең таңында килеп җитә. Алар 3 рәт булып тезеләләр: поляклар сул флангыга, шул ук Грюнвальд урманы янәшәсенә баса. Ә литвалар бераз алга узып, уң флангыда, Танненберг авылы янында урнаша. Литва гаскәре составына кергән Җәләлетдин атлылары уң флангыны капларга тиеш була. Моннан тыш, аларга һөҗүмгә сигнал бирелүгә, Витовт атлылары белән бергә дошман өстенә ташланырга, тупларны сафтан чыгарып, җәяүле укчы, арбалетчыларны кылычтан уздырып алга узарга һәм «бүре базлары» артында торган авыр коралланган атлы рыцарьларны хәйлә белән союздашлар өчен җайлы урынга чыгару бурычы йөкләнә.

Тәре йөртүчеләр башлап һөҗүмгә күчәргә уйламый. Чөнки, алар фикеренчә, беренчедән, каршыдагы гаскәр сан ягыннан күбрәк булганга, аларның җиңел коралланган атлылары флангыларны уратып узарга мөмкин; икенчедән, шундый зур тырышлык белән эшләнгән «бүре базлары»ның, башка тоткарлыкларның мәгънәсе бетә. Шуңа күрә, тевтонлылар ачык аланда эссе июль кояшы астында кызган көбә киемнәрендә әлсерәп, дошман һөҗүмен көтәргә мәҗбүр була.

Ягайло белән Витовт гаскәрләрен урман кырые буйлап күләгәдә урнаштыралар. Аларга эсселек янамый. Шуны истә тотып, дошманны алдан ук хәлсезләндерер өчен, Польша короле Ягайло ашыкмый. Ике мәртәбә гыйбадәт кылырга куша, батырлык күрсәткәннәргә рыцарь исемен бирү йоласын үткәрә, артта калганнарны көткән була. Шактый вакыт ул шул рәвешчә сафта торган рыцарьларны интектерә.

Ниһаять, рыцарьларның гына түгел. үз гаскәрләренең дә түземлеге төкәнә башлаганын күреп, Ягайло сәгать 12ләр тирәсендә гомуми һөҗүмгә күчәргә боерык бирә. Менә быргыларның һаваны ярган ачы тавышлары астында польша-литва гаскәре алга кузгала. Тәре йөртүчеләр якынаеп килүче дошманны барлык тупларыннан атып каршы ала. Куркыныч, әле күнекмәгән йөзләгән тупларның гөрселдәве күп йөрәкләргә шом салса да, күпчелек ядрәләрнең һөҗүм итүче сафларга килеп җитмәве сәбәпле зур зыян китермәвен күреп, сафтагылар янә җанланып, алга баруларын дәвам итә. Ачы дары төтене аша бернәрсә күренмәгәнгә, икенче залп тагын да уңышсызрак була. Соңрак, аланда кыямәт башлангач, артиллерия бәрелеш беткәнчегә кадәр бүтән ата алмый.

Хәер, бомбардаларның файдага караганда зыяны күбрәк булуын рыцарьлар үзләре дә аңлап ала: ике залптан соң алар ягына авышкан төтен баганасы артында тевтонлылар, гомумән, дошманны күрмәс була. Бу Витовтның алдынгы төркемнәренә һәм Җәләлетдин җайдакларына куйган бурычны үтәргә мөмкинлек бирә. Алар югалтусыз диярлек туплар урнашкан сызыкка килеп җитә һәм тупчыларның, укчы-арбалетчыларның бик күбесен кылычтан уздырып, калганнарын качып китәргә мәҗбүр итә. Бер үк вакытта Җәләлетдин җайдаклары тоткарлау киртәләрен җимерә.

...Тевтонлыларның бөтен сул ка-

наты буйлап каты бәрелеш башлана: магистр башта Витовт гаскәрен тар-мар итеп, бөтен көчләре белән поляклар өстенә ташланырга тели. Яу кырын кылычлар чыңлавы, сөңгеләрнең шартлап сынуы, атлар кешнәве, көбә киемнәрнең бер-берсенә бәрелеп гөрселдәве, җайдакларның төрле телдә усал сүгенү-кычкырулары, яралыларның ыңгырашу һәм ярдәм сорап ялварулары, башка орыш тавышлары күмеп китә.

Аяусыз кисешү бер сәгать чамасы дәвам итә. Әмма тевтонлыларның өстенлеге сизелә башлый. Дошман басымы астында литвалылар белән татарлар башта әкрен-әкрен генә чигенеп барса, бераздан инде алар яу кырын ташлап, чаптырып урман эченә кереп югалалар. Тыгыз сафларын таркатырга мәҗбүр булган рыцарьлар качкыннарны эзәрлекләп урманга килеп керәләр һәм бу шөгыль белән шулхәтле мавыгып китәләр ки, алдан Җәләлетдин әзерләп куйган поскынга (засада) ничек килеп эләгүләрен сизмичә дә калалар. *(Мондый хәйләләү тактикасы урдалыларның күптәнге һәм сыналган алымы була. — Г.Г.)* Бернинди хәвеф-хәтәр көтмәгән рыцарьлар киң мәйданга таралып, берберсеннән аерылап хәрәкәт иткәнгә, тыгыз сафлардагы бөтен өстенлекләрен югалталар (мәсәлән, күршесен ышыклау-каплау мөмкинлеге). Агачлар арасында бик шәп бара алмаган рыцарьга көтмәгәндә чытырманлыктан берьюлы берничә кеше ташланып, аны йә ияреннән сөйрәп төшерә, яки атының аягын чабып ега. Шулай итеп, урман эчендә тевтонлыларның беренче рәте тулысынча диярлек юк ителә. Калганнарына кире борылудан башка чара калмый. Тик аланга чыкканарга да бәхет елмаймый: артларыннан куып киткән татар җайдаклары үзләрен арканнар ыргытып, ыргаклар белән эләктереп, ат өстеннән йолкып алып, җиргә ташлый. Егылудан миңгерәүләнгән рыцарьларны бугазлап чыгу, әлбәттә инде, кыен булмаган.

Ачык аланда тевтонлыларның әллә ни зыян күрмәгән икенче рәте үзләрен тәртипкә китереп һәм яңадан тыгыз сафларга тезелеп, урманнан эзәрлекләп чыккан җайдакларны туктата. Алар тагын агачлар арасына кереп югала.

Витовт белән Җәләлетдин төрле якка таралган-сибелгән кешеләрен җыеп, орден гаскәренең артына төшәр өчен, урман эченнән Танненберг авылы тарафына юнәлә.

Ә бу чакта аланда мөшкел хәл килеп туа. Көне буе дәвам иткән канкойгыч бәрелеш ахырына якыная шикелле: тевтонлыларның уң канаты һәм Витовт гаскәрен туздырган сул канатның зыян күрмәгән икенче рәте ялгыз калган полякларның үз-үзләрен аямыйча каршылык күрсәтүенә карамастан, аларны һәрьяктан кысрыклап, чолганышка алу куркынычы тудыра.

Нәкъ менә шушы хәлиткеч мизгелдә, кичке сәгать 7ләр тирәсендә, Танненберг авылы ягыннан бәрелеш урынына бик тиз якынлашып килүче атлы гаскәр пәйда була. Рыцарьлар бик тиз югалып торган дошманнарын шәйләп ала, алар арасында паника башлана. Шунда ук полякларны кысрыклау да зәгыйфьләнә, тевтонлылар ашык-пошык сафларын үзгәртеп тезәргә тотынса да, инде соң була. Арттан килеп суккан Витовт һәм Җәләлетдин атлылары, дәртләнеп киткән поляклар белән бергә, рыцарьларның үзләрен камалышка алалар. Тиздән алар тулысынча диярлек тураклап ташлана.

Бәрелеш Тевтон ордены өчен искиткеч авыр нәтиҗәләр белән тәмамлана. Яу кырында 8 мең рыцарь ятып кала, 14 меңе әсир төшә. Тевтонлыларның өч югары хәрби җитәкчеләреннән барысы да һәлак була. Литвалар белән татарлар каршында торган сул канат җитәкчесе маршал Валленрод Җәләлетдиннең мең җайдак башлыгы (меңбаш) Йосыф бәй тарафыннан корбан китә. Ә бөек магистр (командующий) Ульрих фон Юнгинген исә Пруссия тикшеренүчесе А.Коцебу фаразлавынча, морза Ба-

гардин (Бәдретдин?) кулыннан һәлак була. Уң канат җитәкчесе бөек комтур (бөек магистр урынбасары) Лихтенштейнның гомере поляклар белән алышканда өзелә.

Мәгълүм булганча, һәр сугышта иң зур хурлык булып хәрби берәмлекнең байрагын югалту санала. Тевтонлылар бу орышта 52 байрактан барысын да югалта. Шуларда 51е бөек магистрның «байраклар байрагы» җиңүчеләр кулына эләгә.

Аерым алганда, Җәләлетдин җайдаклары исәбендә ике байрак, 14 әсир (шул исәптән ике комтур — гарнизон башлыклары) булуын да әйтеп үтәргә кирәк.

Җиңүчеләр биниһая күп ганимәт малына ия була. Хәрби табыш арасында ядрәләре, дары белән йөзләп бомбарда, тау-тау өелгән башка корал һәм көбә кием (алар арасында зиннәтле, алтын йөгертелгәннәре бихисап була), саклагыч тимер япмалары белән дистәләрчә мең баш менә дигән сугыш атлары, лагерьда мичкә-мичкә югары сыйфатлы шәраб һ.б. мал була.

Кәеф-сафа кылып бару аркасында җиңүчеләр Мариенбург янына 10 көннән соң гына, ягъни 25 июльдә генә килеп җитәләр (100 чакрым араны!). Мариенбург Европада иң куәтле ныгытмаларның берсе булганга, кыенлыклар башлана: саклаучылар яу кырыннан исән-сау ычкына алган биш меңләп рыцарьлар исәбенә саклану чараларын тагын да камилләштерә. Берничә һөҗүм зур югалтулар белән кире кайтарыла. Нәтиҗәдә, союздашларның мондый көчле крепостьларны камау һәм алу тәҗрибәсе булмаганга, алар 18-19 сентябрь көннәрендә Мариенбургны калдырып китәргә мәҗбүр була.

Килешү турында сөйләшүләр башлана һәм 1411 елның 1 февралендә Торунь шәһәрендә ике арада килешүгә кул куела. Килешү шартлары буенча Тевтон ордены Польшаның 1409 нчы елны тевтонлылар тарафыннан басып алынган Добжински җирен кире кайтарырга һәм Ягайло белән Витовт исән чагында Жмудь өлкәсенә дәгъва белдермәскә тиеш була.

Моннан тыш орден 1409-1411 елларда ике арадагы сугыш вакытында союздашлар тарафыннан алынган ныгытмаларны һәм әсирләрне кире кайтарган өчен заманы өчен гаять зур акча — 300 меңгә якын гульден түләргә йөкләмә ала.

Шулай да, килешү ирешелгән җиңүгә тәңгәл килми: тәре йөртүчеләр тарафыннан басып алынган Польшаның Поморье өлкәсе әле алар кулында кала, бер үк вакытта алар Жмудь өлкәсен дәгъвалаудан да баш тартырга уйламыйлар.

Татар атлыларының күрсәткән ярдәме Торунь килешүендә билгеләп үтелә һәм Витовт Җәләлетдингә Кырымны алуда булышлык күрсәтә (1411).

***PS.** 2010 елның 25 ноябрендә Польшаның Гданьск шәһәре паркында атка атланган татар җайдагы сыны урнаштырылды. Ул Польша-Литва дәүләтенең Грюнвальд бәрелешендәге тарихи җиңүнең 600 еллыгы уңаеннан куелды. Польша президенты Бронислав Коморовский һәйкәл ачу тантанасында әлеге бәрелештә татар улларының күрсәткән батырлыгы турында чыгыш ясады. Татар яугирләренең Европа сугышларындагы кыюлыклары турындагы истәлекләрне бик күпләр искә төшерде ул көнне.* ■

ТӨРЕК ВӘ ТАТАР ТАРИХЫ

Әхмәтзәки Вәлиди

Бәркә хан

БӘРКӘ ХАН

Улакчы урынына Батуның энесе, Җучиның угылы Бәркә хан булды (1255). Ул Мәнгү (Мөнке) каанга күп һәдияләр[1] җибәрде. Бәркә Бату вакытында чакта ук дин исламны кабул итмеш иде. Тәхеткә утырганнан соң хатыны Чәчәк, кардәше Тукайтимур вә башка олуглары илә бергә исламны кабул иттеген рәсми игълан итте. Вә исемен дә «Бүркә»дән «Бәркә»гә (Бәрәкә) әйләндерде. Ислам хәлифәсе Мөстәгсыйм биллаһка[2] бәйгать биреп[3] вә хатлар язышып торды.

Бәркә хан булмастан элгәре, Тули ханның Һүләкү исемендәге углы, Мәнгү каанның әмере илә, Иран җәһәтләрен яулап алып, Исмәгыйлия исемендәге аерым бер ислам дәүләтен бетерде (1253) вә Насретдин Туси[4] исемендә бөек бер ислам галимен үзенә вәзир вә киңәшче итте. Ошбу бөек галим могтәзилә вә шига (шигый) мәзһәбендә иде. Һүләкү, мәмләкәтен янә киңәйтергә теләп, азәрбәйҗан тарафыннан Кстантина (Константинополь) тарафларына йөрергә ният итте. Ошбу бөек галим шул көн ислам хәлифәсенең пайтәхете вә хисапсыз гыйлем йортлары вә голәмәнең оясы булган Багдад шәһәрен иң элек алмак лязимдер, дип киңәш бирде. (Багдад Чыңгыз вакытында сәламәт калмыш иде.) Һүләкү моны мәгъкуль күрде вә Багдадка барырга әзерләнде. Ошбу хәбәрне Бәркә ишеттеге илә Һүләкүне агасы Бату тарафыннан тыйдырды.

[1] Һәдия - бүләк.

[2] Мөстәгсыйм биллаһ— Габбасилар нәселеннән соңгы Багдад хәлифәсе — Әбү Әхмәт Габдулла әл Мөстәгсыйм (1213-1258).

[3] Бәйгать бирү — тугрылыклы булу.

[4] Насретдин Туси (1201-1274) – фарсы математигы, механигы һәм астрономы.

[5] «Ясак» — Җучи мәмләкәте чорында кануннар тупланмасы, «Яса».

[6] Ибне Голками шигый мәзһәбендә иде. Хәлифә, бервакыт Багдад мөселманнарының өзлексез сөнни, шигый низагларын юк итү өчен, бәгъзы шигыйларны үтертеп, мәхәлләләрен гаскәр тарафыннан талатмыш иде. Ибне Голками ошбуның үчен алмак кайгысында иде. Һүләкүне дәгъват итте. Һәләкү килеп, Багдадны камаган вакытта,

Бу эш Бәркә иҗтиһады илә генә булды. Юкса Багдадны алмактан (гына) түгел, бөтен дөньяның астын өскә әйләндерүдән дә «Ясак»ның[5] тыйганы юк иде.

Бату үлгәч тә комсыз Һүләкү, Насретдинның теләдегенчә вә Мөстәгсыйм хәлифәнең вәзире ибне Голкаминың дәгъвате буенча, Багдадка килде вә ибне Голкаминың хәйләсе илә[6], әүляд[7] вә гыялы[8] илә хәлифәне вә эчендә бер миллион кадәр җан булган Багдад халкын һәммәсен үтереп, дөньяда мисалы күрелмәгән золымны башкарды. Вә ошбуның илә мөселманнарны янәдән күп гасырлар терелмәслек итеп һәлак итте. Никадәр бөек мәдрәсәләр, китапханәләр бар исә, барчасын җир илә бәрабәр итте (1258).

Багдадтан соң Һүләкү Мисыр өстенә йөрде. Бәркә ошбуны күреп-белеп торыр иде, ни итәргә шашты, аптырады. Ошбу вакыт Мәнгү каан күп гаскәр илә Кытай эчендәге фетнәне басмак өчен китеп барыр иде, вафат итте. Мәнгү үз янына иптәш итеп бөек энесе Кубла (Хубилай, Кубилай) ханны алып, үз урынына Каракорымда кечек энесе Артыкбүкә ханны утыртып китмеш иде. Юлда Мәнгү урынына, олуг улдыгы өчен, Кубланы каан иттеләр. Форсат күзәтеп кенә торган Бәркә өчен монда бик уңай бер эш килеп чыкты. Ул Каракорымдагы Артыкбүкәгә: «Син каанлыкны үз кулыңнан җибәрмә. Мин сиңа ярдәм өчен гаскәр җибәрдем», — дип хәбәр күндерде. Артыкбүкә үзен каан игълан итте. Моны ишеткәч тә Кубла гаскәре илә әйләнеп кайтты вә Артыкбүкә илә сугышырга кереште. Бу хәбәр Һүләкүгә җитешеп, ул гаять уңайсызланды. Мисыр чигендәге гаскәренә Көтбуга исемендәге берсен баш итте дә, үзе туган Марага шәһәренә кайтты. Һүләкү киткәч тә, Мисыр солтаны Сәйфетдин Катыйз Котлы гаскәре илә чыгып Һүләкүнең ун мең гаскәрен ахырына кадәр бетереп һәлак итте (1260).

Болар һәммәсе дә Бәркәнең төзегән планнары иде[9]. Эшләр камил ул теләгәнчә килеп чыкты. Әгәр Бәркә булмаса иде, Мисыр да бөтенләй Һүләкү кулында көлгә әйләнәчәк иде.

Һүләкү ошбу кадәр уңайсызлыклар сәбәбеннән теләгәнчә мәмләкәтләр яулый алмады, бәлки Иранда Мараганы пайтәхет итеп, барлык җирләрен идарә итеп тора башлады[10].

Һүләкү бу кадәр бәлаләрнең бар сәбәбе Бәркә идекен бик яхшы белә иде. Бәркә илә Һүләкү арасында электән үк була килгән дошманлык бу кәррә янә куәтләнде. Ахырда Һүләкү Бәркә илә сугышу фикеренә төште. Бәркә, Һүләкүне ислам падишаһларын нигезеннән бетерүдән тыеп алып калу илә генә канәгатьләнмичә, Һүләкүдән үз кулы илә үч алу кайгысында иде. Бу хәлдә Һүләкүнең сугыш теләве үзе Бәркәнең максуды иде.

«Ясак» буенча ганимәтләр Чыңгыз балалары арасында бүленү лязим иде. Бәркә, илче җибәреп, Һүләкүдән алган ганимәтләреннән үзенең өлешен сорады. Һүләкү Бәркәнең илчеләрен үтерде. Һәм ошбу сәбәптән бик тиз сугыш башланды. Бәркә хан тарафыннан Нугай исемендә, Һүләкү тарафыннан Нуян исемендә башлыклар Кавказиядә, Ширзан тарафларында сугыштылар. Әүвәл мәртәбәдә Нугай өстен чыкса да да, соңыннан Нуян җиңүче булды (1261).

Ибне Голками хәлифәгә: «Һүләкү сезне һаман хәлифәтегездә калдыра вә углыгызга үзенең кызын бирә вә сезне хәзер дәүләтнең бөтен дәрәҗәле түрәләре илә шәһәр янына туйга дәгъват итте», — дип хәбәр бирде. Хәлифә барлык түрәләр илә шәһәрдән чыкты. Ошбу урында Һүләкү тарафыннан үтерелделәр. Соңра бөтен Багдад халкы үтерелделәр (Ә.В.).

[7] Әүляд — нәсел-токым.

[8] Гыял — өй җәмәгате, бала-чага.

[9] Морад әфәнде тарихыннан (Ә.В.) (Мәшһүр татар тарихчысы Морат Рәмзи — *Ред.*).

[10] Һүләкү Багдадта гыйлем йортларын һәлак иттерде исә дә Марага гыйлем йортларын бина иттерде. Гыйлем вә мәгарифнең тәрәккыйсе өчен көллиятле вәкыфлар вә хәзинәләр оештырды, вә Марагада шул вакытка кадәр мисалы булмаган бер расыйдханә (обсерватория) эшләтте. Дүрт йөз меңнән артык том нәфис китаплар туплап, мөкәммәл



Һүләкүнең Багдадны алуы

Соңра 3 нче сугышта янә Һүләкү, өстен калып, Бәркә иленә чыкты. Кыпчак халыклары чатырларына гаскәрен җибәреп һәртөрле кабахәтлекләр иттерергә керешкән иде, аңламастан, күп гаскәр илә Бәркә килеп чыкты һәм Һүләкүнең гаскәрен бөтенләй туздырды. Бу сугыш Тимер Капу сугышы дип аталадыр. Моның соңында Һүләкү янә Дәште Кыпчакка бару кайгысына керсә дә, һич эш башкара алмады. Ахырдан каты кайгылар эчендә вафат итте (1266).

Җиренә угылы Абака хан булды. Бу янә Бәркә өстенә гаскәр җыеп барып сугышты, ләкин җиңелүдән башка нәтиҗә күрмәде.

Артыкбүкә илә Кубланың сугышуы ике елга кадәр сузылды. Ахырда Кубла каан булды вә күп гаскәр илә янә Чин эченә сәфәр итте, Пекин (Ханбалык) шәһәрен Каракорым шәһәре урынына пайтәхет итте.

Бәркә хан ислам кабул итүе илә бөтен татарлар дин исламны берьюлы кабул иттеләр вә бөтен ихласлары илә дин исламга ябыштылар. Мөселман булмаган халыклар бу эшкә аптырап калды. Бәркә үзен дин исламның, Коръәннең яклаучысы дип игълан итте. Бәркә мәмләкәтендә дин исламга каршы тел кузгалтмак имкянсыз[11] булып калды. Бәркә дин исламны үгрәтмәк[12] һәм кыпчак мәмләкәтенә гыйлем нәшер итмәк өчен ислам мәмләкәтенең һәр тарафыннан галим-голәмәләр китерде, мәдрәсә вә мәсҗедләр бина итеп вәкыфлар оештырды. Ошбу сәбәптән ислам голәмәсе Бәркәгә «Насретдин Аллаһ», «Әбелмәгали» дип ләкабләр[13] куйдылар. Ислам голәмәсе зурларыннан Нәҗметдин әз-Заһиди Бәркәгә нисбәт илә «Насыйрия» исемендә китап язып Бәркәгә һәдия итте.

Бәркә хан илә Мисыр падишаһы Мәлик Заһир Бәйбарыс хатлар язышалар, бүләкләр илә илчеләр җибәрешәләр иде. Сарай шәһәре Бату хан вакытында бина ителеп җитмәгән иде, аны Бәркә тәмам итте.

Бәркә хан 1266 нчы елда вафат итте. Үзенең урынына калырга бер баласы булмадыгыннан, Бату ханның Тукан исемендә угылының баласы Мәнгү Тимер хан ителде. ■

бер китапханә төзеттерде. Гыйлем һәм һөнәр ияләрен һәр тарафтан җәлеп итеп, аларга акча тәгаен иттереп, бөек бер академия тәшкил иттерде (Ә.В.).

[11] Имкянсыз — мөмкин түгел.

[12] Үгрәтмәк - өйрәтү.

[13] Ләкаб - кушамат.

ЗӨҺРӘ АКЧУРИНАНЫҢ ӘНИСЕ ФАТЫЙМАНЫҢ КАБЕР ТАШЫ

Наил Таиров

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, —
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!
«Өзелгән өмид», Габдулла Тукай

Төрки-татар мәдәнияте тарихында эшкуар Акчуриннар нәселеннән булган хатын-кызлар зур роль уйнаган. Мәсәлән, Хәдичә Акчурина — төрки-татар дөньясында беренче хатын-кыз рәссам, ә Зөләйхә Акчурина — беренче хатын-кыз археолог.

Зөһрә Акчурина исә тарихка беренче татар хатын-кыз журналисты буларак кереп калган. Ул ире Исмәгыйль Гаспралы белән Кырымда «Тәрҗеман» газетасын иҗат итә. Аның әтисе Әсфәндияр Курамша углы (1830-1903) — мәшһүр сәүдәгәр, Сембер губернасы Коромысловка авылында сукно фабрикалары җитәкчесе. Аның тормыш юлы фәнни-популяр басмаларда күпмедер дәрәҗәдә өйрәнелгән.

Зөһрәнең әнисе — Фатыйма (Бибифатыйма) — Сөнгәләй өязе Зөябаш авылында сукно мануфактураларын оештырып җибәргән Сөләйман Габдулла углы Акчуринның кызы. Фатыйма һәм Әсфәндияр туганнан

Илһам Таиров фотолары

Ульян өлкәсе Барыш районы Зөябаш авылы зиратында Фатыйма Акчуринаның кабер ташы

туган кардәшләр булган. Шунысын да әйтергә кирәк, Акчуриннар арасында сәламәтлеккә начар йогынты ясый торган мондый кан кушылдырулар берничә мәртәбә булган.

Иң кадерле кешесе — әнисе Фатыйманың вафат булу хәбәре Зөһрә өчен олы кайгы һәм зур сынау була. Зөһрә Акчуринаның тормыш юлын өйрәнгән галимнәр Фатыйманың кайчан бакый дөньяга күчүе турында язмый (мәсәлән, А.Х.Мәхмүтова). Белгечләр Фатыйманың әтисе Сөләйман исемле булуын да телгә алмый.

Ләкин бу сорауларга төгәл җавапны Фатыйманың кабер ташындагы язмаларны укып белергә мөмкин. Зиратта сакланучы шактый затлы эшләнгән әлеге һәйкәл татар халкында бу төр сәнгатьнең яхшы ук үсеш алганлыгына янә бер дәлил. Ташъязманың тексты гарәп телендә язылган. Шуның нигезендә без Фатыйма Сөләйман кызының 1879 елның 29 гыйнварында, хәзерге стиль белән 10 февралендә вафат булганлыгын ачыклыйбыз. Әсфәндияр хатыны вафат булганнан соң Хәдичә Ильяс кызына өйләнә. Бу никахтан мәшһүр библиограф, археолог Зөләйхә Акчурина туа.

Кызганыч ки, Татарстан Республикасында хәзерге көнгә кадәр Зөһрә Акчурина исеме белән бәйле дәүләт бүләге юк. Татар матбугатында каләм тибрәтүче журналистларыбызның күп өлешен тәшкил иткән хатын-кызларыбыз, һичшиксез, моңа лаек. Ә бу исә, үз чиратында, Зөһрә Акчуринаның исемен мәңгеләштерүдә бер гамәл булыр иде.

Игътибарыгызга Фатыйма Акчурина кабер ташындагы язмаларның мәгънәсен татар теленә тәрҗемә итеп тәкъдим итәбез*.

Ташның алгы ягы: *«Хөкем бары тик Аллаһныкы. Бирегә сыену урыны һәм тынычлык тапкан шәрәфәтле мәрхүмә Фатыйма мәрхүм хаҗи Сөләйман Акчурин кызы, сәүдәгәрләрнең асылы Әсфәндияр Курамша мәрхүм улы Акчурин хатыны. Аллаһ аларга шәфәгатен кылсын. 1296 елда вафат булды, сәфәр аеның 10 нчы көнендә. Аллаһы Тәгалә аны җәннәт бакчасына кертсә иде».*

Ташның икенче ягы

Арткы ягына: *«Миляди буенча 1879 елның 29 гыйнварында. Һәр көнең синең дөнья рәхәтлеге белән алданып, уен һәм гафләттән тора. Ә һәрбер төнең синең ком белән капланачак — моннан качып котылу мөмкин түгел. Һәрбер кеше вафат була һәм йокы (ягъни бакый дөньяга күчү) белән башлана».* ■

* Ташъязманың текстын Марсель Әхмәтҗанов, Аяз Мингалиев тәрҗемә итте.

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ САРМАТ БАБАЛАРЫ

Фирдәвес Гарипова
(1941-2014)

Бер-берсе артыннан куышкандай ике Чирмешән ага... Алар элеккеге Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм хәзерге Татарстан җирләреннән ага.
Һәр ике Чирмешән дә Габделҗаббар Кандалый (1797-1860) шигырьләрендә еш очрый.

Зур Чирмешән — Куйбышев сусаклагычы кушылдыгы. Ул Татарстан Республикасы, Ульяновск һәм Самара өлкәләре җирләреннән агып уза.

Кече Чирмешән — Зур Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Ул Татарстан Республикасы һәм Самара өлкәләре аша агып үтә.

Чирмешән атамасы төрле тарихи чыганакларда искә алына. 921-922 елларда Идел-Кама Болгарстанына Багдад хәлифәлегеннән килгән илчелек составында булган Әхмәт ибн-Фазлан язмаларында ул — Җәремсан, рус елъязмаларында — Черемисан, Әлки районының Ташбилге авылы янында табылган кабер ташында — Чәримсан рәвешле бирелгән. Чирмешән атамасы тарихи актларда, Казан, Самара, Сембер җирләрендә урнашкан торак пункт атамаларын исәпкә алган исемлекләр тупланган һ.б. ономастика өчен кирәкле документ-белешмәләр урнаштырылган тарихи-географик, географик-статистик, тарихи-этнографик чыганакларда еш очрый.

Казан ханлыгы чоры авыл атамалары арасында Чирмешән атамасы белән 5 торак пункт күрсәтелгән. Аларның дүртесе Җөри юлы өстендә, ә берсе Нугай юлы өстендә дип билгеләнгән (1: 289).

Татарстан җирлегендә Чирмешән лексик берәмлеге белән ясалган байтак кына географик атамалар очрый. Кайберләре хәзер кулланылмый.

Кама аръягы Чирмешәннәре. Чирмешән районы үзәге Чирмешән авылы Зур Чирмешән елгасы ярында урнашкан. Ул тимер юл үзәге Шонталыдан — 26, Чистай пристаненнан 107 чакрым ераклыкта утырган (2: 204). Чирмешән (Чирмешән ныгытмасы) В.П.Семёнов редакцияләгән китапта искә алына. Ул 1741 елда Кама аръягында ныгытылган линия төзү максатларын күздә тотып салына.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң рус дәүләтенеке булып саналган чикләрне күчмә кабилә-кавемнәрдән саклау өчен ныгытылган линиянең якъягына урыслар, удмуртлар, мари, мордвалар һәм йомышлы татарларны күчереп утырталар. Күчеп утырган халыкның бер кулында корал булса, икенче кулында китмән һәм башка ашлык үстерү өчен кирәкле әсбаплар булган.

1768 елда бу ныгытманы И.И.Лепехин карап китә. Ул монда инде хәрбилекне ташлаган 1085 кеше яшәгәнлеген теркәп калдырган. 1901 елга монда яшәүчеләр саны 3 меңгә

Фирдәвес Гарипова

җиткән, шифаханә, базар булган (3: 433).

1859 елда Чирмешән (Чирмешән ныгытмасы) авылында 223 йорт булып, анда 732 ир-ат һәм 850 хатын-кыз яшәгәнлеге мәгълүм. Авылда базар булган (4: №462, б.26).

Д.А.Корсаков тарафыннан бастырып чыгарылган җыентыкта хәзерге Чистай районында Кече Чирмешән елгасы ярында Татар Чирмешәне авылы күрсәтелгән һәм ул Майна дип тә аталган (5: 196). Бу авыл (Черемыш татарский) Җөри юлы өстендә утырган дип Казан ханлыгы торак пункт атамалары составында да саналган (1: 289).

Хәзерге вакытта Кече Чирмешән елгасы ярына урнашып яшәгән Татар Майнасы авылы Казан ханлыгы чорыннан калган торак пункт булса кирәк, дигән уй башка килә.

Чирмешән елгасы һәм аның кушылдыклары буена урнашкан авыллар халкында татар тарихы белән бәйләнешле бик күп истәлекләр сакланган. Ул тирәләрдә борынгы чорларга мөнәсәбәтле шәһәрлек һәм авыл хәрабәләре, кабер ташлары һәм язма истәлекләр табылган.

Казан арты Чирмешәннәре. Казан артының Балык Бистәсе районында Чирмешән атамасы бар. Авылның рәсми атамасы Шетнев-Чирмешән булуга карамастан, авыл халкы аны Чирмешән дип кенә йөртә. Хәер, рәсми рәвештә Шетнев-Чирмешән дип язылуы да дөрес түгел. Чирмешән яисә, һич булмаса, Шитнәү Чирмешән дип беркетү кирәк иде. Авыл үзидарә үзәге Корноухово авылыннан — 6, Казаннан 95 чакрым ераклыкта урнашкан (2: №43, б.171).

Авыл атамасы төрле тарихи чыганакларда очрый.

Әшнәк суы буендагы бу авыл Казан ханлыгы чорында булган. Ул Нугай юлы өстенә утырган Черемша авылы дип күрсәтелгән (1: 290). Д.А.Корсаков җыеп чыгарган авыл атамалары исемлеге арасында Чирмешән елгасы Казан артындагы Әшнәк елгасының уң кушылдыгы дип ныгытылган. Д.А.Корсаков төзеп чыгарган белешмәдә бу авыл Шетнеево дип күрсәтелгән. И.А.Износков авылны болай сурәтли: «Авылда 87 хуҗалык, анда ислам дине тота торган 218 ир-ат һәм 225 хатын кыз яши. Күршедәге Җүҗи (Зюзино) авылы кешеләре сөйләвенә караганда, бу авылда элек өч туган яшәгән. Аларның берсе вакытлар үтү белән Югары Шитнәүгә (Югары Ырга), икенчесе Кама аръягына күчеп киткән, өченчесе биредә калган. Җүҗилеләр дә бу авылны Чирмешән авылы дип йөртә. Күршедәге халык Шитнәү-Чирмешәндәге бер нәселне башкаларыннан аерып карый, аларның хәтта башка авылдашларыннан аерым җирләре дә булган» (6: №174, б.24).

Диалектолог-галимә Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Шитнәү Чирмешән (Чирмешән) авылы халкы күршедәге Олы Елга, Кече Елга, Олы Әшнәк, Олы Солтан, Янтык авыллары халкы белән бергәләшеп Җөзен җыены үткәргән. Ул июнь башларында булган (7:42).

Авылның тирә-юнендә географик

атамалар шактый. Солтан авылына бара торган юлда Шикнәү таулары бар. Иң күренекле географик атамаларның берсе — Изгеләр чишмәсе. Ул авыл башындагы зират янында. Бу чишмәнең суын элегрәк Казаннан килеп тикшергәннәр. Чишмә суы бик сирәк очрый торган минералларга бай, дип әйтеп киткәннәр.

«Казан шәһәре теркәү кенәгәсе»ндә Казан артындагы Норма суы бассейнында тагын бер Чирмешән исемле авыл телгә алына (8: 64). Хәзер ул авыл беткән булса кирәк.

Ленино-Кокушкино (Черемыш-Апакай) авылы район үзәге Питрәч районыннан 20 чакрым ераклыкта урнашкан. Казан белән ике арасы 40 чакрым. Бу авыл — җирле үзидарә үзәге. (2: №40, б.167).

Җөри юлы өстенә урнашкан бу авыл Казан ханлыгы чорында Черемыш-Апакаево дип аталган (1: №439, б.289). Үшнә суы ярына утырган Черемыш-Апакай авылында чукынмаган, ясак түләүче крәстияннәр көн иткән. Авыл исеме РСФСР Югары Советының 1964 елгы указы белән В.И.Ленин (Ульянов) хөрмәтенә Черемыш-Апакаеводан Ленино-Кокушкино дип үзгәртелә.

Авыл Черемышево (Апакаево), Малое Черемышево, Черемышево Поганое, Малое Апакаево, Апакай Чирмеш атама төрдәш-вариантлары белән тарихи белешмәләрдә шактый очрый.

Бүгенге көндә Ленино-Кокушкино бистә (посёлок) тибындагы торак пункт. Биредә 20дән артык милләт вәкилләре яши һәм эшли.

Апакай җирләре басу-кырларга, елгаларга һ.б. табигый сулыкларга бай. Күренекле елгаларның берсе — Үшнә суы. Ул авылның төньяк тарафыннан ага. Су тегермәннәре корылганчы бу елга бик сай булган, тегермәннәр салынганнан соң аның суы тирәнәйгән. Кызганыч, хәзер елга саекканнан-саега.

Үшнә суының сул ярында шактый күп чишмәләр тибеп чыккан. Аларны Завод чишмәсе, Зират Чишмәсе, Урыслар чишмәсе, Ташчишмә дип атап йөртәләр. Завод чишмәсе хәзер ябылган, эзе дә калмаган. Аның атамасы заводка нисбәтән бирелгән булган. Кайчандыр гөрләп яшәгән бу заводта керамик әйберләр җитештергәннәр. Зират чишмәсенең атамасы аннан ерак түгел төньяктарак урнашкан татар зиратына мөнәсәбәтле. Урыс чишмәсе — аннан урыс халкы су алганга шулай аталган. Ташчишмә ташлыктан тибеп чыккан һәм хәзер дә Үшнә бистәсе халкын су белән тәэмин итеп тора.

Тау ягы Чирмешәннәре. Тау ягында, Апас районында Чирмешән суы буенда Чирмешән авылы бар. Ул район үзәге Апастан 22 чакрым ераклыкта урнашкан (2: №6, б.45).

Д.А.Корсаков җыеп, туплап, редакцияләп бастырып чыгарган чыганакта бу авыл Икенче Чирмешән дип ныгытылган (5: 339). Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Чирмешәннән ике чакрым ераклыкта урнашкан Багыш авылы элек Өченче Чирмешән исемендә йөргән икән (5: №138, б.390).

Диалектолог-галимә Нәҗия Борһанова бу авыллар катнашында җыен да уздырылуын ныгытып калдырган. Чирмешән, Багыш, Югары Балтай, Урта Балтай, Түбән Балтай, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чирү, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чәтбаш, Коллар, Шәмәк, Күкшем, Тутай, Аксу, Дәүләки авыллары халкы июнь урталарында Кушкапка исемле җыен бәйрәме үткәргәннәр (7: 60).

Чирмешән авылы элек Көтмәс елгасы (чыгыры) янында булган. Бу урын бик тынычсыз булып чыккан һәм халык хәзерге авыл урынына килеп утырган. Бу тирәләрдә зур-зур агачлардан торган урманнар үскән. Олы Роман, Пулат, Сергей ышналары урман төпләп ясалганнар. Шалкан ышнасы дип аталган басуда элек күп итеп шалкан чәчкәннәр икән. Хәзер ул басу беткән. Элек Чирмешән елгасында 4

су тегермәне, 1 пар тегермәне эшләгән. Шуның өчен аның суы мул булган.

Авыл халкы авыл урамнарының Янган капка (Урта урам), Канатсыз, Җомагыл, Кутыр, Болын, Югары оч, Аръяк дигән элекке исемнәрен кулланышта йөртә.

Тау ягындагы Апас районында Чирмешән үзәге («үзәк» — елга) Бола елгасының уң, ә Чирмешән суы — Боланың сул кушылдыгы. Апас районында тагын Чирмешән чаты (кыр), Чирмешән чишмәсе, Чирмешән болыны, Чирмешән куаклыгы, Чирмешән буе һ.б. атамалар бар.

Апас районындагы Чирмешән елгасы ярына урнашкан Чирмешән авылы халкы матур тормыш белән яши.

Йортлар яңа, зур һәм күркәле, тәрәзәләреннән нур сирпелә.

Галим Н.Ф.Калинин Тәтеш шәһәреннән 15 чакрым түбәндәрәк тә Чирмешән елгасы булуы турында яза.

Чирмешән атамасы белән аталган табигый географик берәмлекләр һәм башка исем-атамалар Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә шактый күп очрый.

Кармасан һәм Чирмәсән — Урал төбәгендәге су чыганаклары атамалары. Чирмәсән кичүе 1773-1775 еллардагы Пугачёв хәрәкәте белән бәйләнешле документларда очрый. Элекке Пермь губернасының Верхотур өязендә Чирмешән елгасы һәм аның ярында Чирмешән авылы искә алына. Мари иле Җөмһүриятенең Портянур авылындагы кабер ташы язмасында Чирмешән атамасы ныгып калган. Саратов өлкәсенең Хвалын шәһәреннән 6-7 чакрым ераклыкта староверларның (православие динен искечә тотучылар) үзәге, аскет монахлар торган Чирмешән исемендәге атаклы монастырь булган. Шул ук Хвалын шәһәре янында Чирмешән исемендә ике күл, бер санаторий һәм ике ял йорты беркетелеп калган. Элекке Ставрополь өязенең Хрящевка исемен йөрткән торак пункттан 25 чакрымда өстәрәк ага торган Чирмешән елгасы ярында Чирмешән (Никольское) авылы урнашкан. Бу урыннан Чирмешән елгасында пароход һәм суднолар йөреше башланган. Самара өлкәсендәге Шонталы районы җирләреннән агып үткән Чирмешән елгасы бассейнында Чирмешән бистәсе (посёлогы) теркәлгән. Самара шәһәренең бер урамы «Чирмешән» исемен йөртә. Димитров шәһәрендәге бер футбол командасына Чирмешән исеме бирелгән. Чиләбе өлкәсенең Югары Уфалы районында шәһәр тибындагы Чирмешән бистәсе бар. Чирмешән атамасы Кырымда, элекке Дон гаскәри казаклары өлкәсендә, Төньяк Кавказда һ.б. урыннарда очрый. Приморье краеның Дальнегорск районында да Чирмешән бистәсе теркәлгән. Чирмешән атамасын Алтайда, Югары Иртеш бассейнында да берәр елга йөртә.

Чирмешән сүзенең нәрсә аңлатуын күп генә галимнәр ачыкларга тырышканнар. Кайберләре әлеге атаманың мари-чирмешләргә мөнәсәбәтле булырга тиешлегенә дәлилләргә тырышты. Археолог-галим Р.Г.Фәхретдинов Зур Чирмешән һәм Кече Чирмешән елгалары ярларын археологик яктан бик җентекләп күздән үткәрә, ләкин яр буйларында һәм тирәюньдә мари-чирмешләргә мөнәсәбәтле бер генә истәлек тә тапмый. Ул Чирмешән атамасының төрки телләр нигезендә аңлатылырга тиешлегенә һич шикләнми. Мин дә бабаларыбыз кулланган Балымат, Юрмат, Шонгат, Урмат, Кыят һ.б. атамалар кергән система-ояга — ат компонентына тәмамланган сармат кавем-кабиләләре дә керә, димәк, без дә бабаларыбыз сарматларның варис-оныклары, дип уйлыйм.

Фәндә Чирмешән атамасының сармат этнонимы белән бер икәнлеген раслаган дәлилле фикерләр бар.

Иң беренче булып, галим П.Д.Шестаков (XIX гасыр) сармат сүзе белән сярмысның аһәңдәшлегенә,

охшаш яңгырашына игътибар итә (9: 69). Иске татар телендә киң әйтелешле «а» авазының «и»гә һәм «и»нең «е» авазына күчеше законлы күренеш. Сабир → Сибир → Себер; Сармат → Сирмеш → Чирмеш — фонетик вариантлар. Борынгы төрки һәм иске татар телендә с-ч-ш-т авазлары күчешә: чишмә~сишмә~тишмә; сай~чай~шай~тай; чишен~шишен~тишен~сишен һ.б.)

Елгалар ярына килеп урнашкан һәм шул урында авыл корып яши башлаган сарматларның елгага да, авылга да үз исемнәрен бирүләре табигый хәл.

Мариларның зур галиме Ф.И.Гордеев Чирмешән атамасы, халыкларның бөек күчеше вакытында хәзерге Башкортстан җирләреннән Урта Идел буйларына кысып чыгарылган соңгырак чор сарматларга бәйләнешле, ягъни сармат кабиләләренең этнонимнары, дип уйлый (10:183-184). Бу турыда, ягъни Чирмешән атамасының сармат кабиләләренә мөнәсәбәте булуын мин 1991 елда Мәскәүдә «Фән» («Наука») нәшриятында дөнья күргән «Гидронимия Татарстана» дип аталган монографиямдә язган идем (11: 183-184). Шулай ук «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында 1989 елда ук 27 август санындагы «Чирмешән» дип аталган мәкаләмдә һәм 1998 елда дөнья күргән «Татарская гидронимия (Вопросы этногенеза татарского народа по данным гидронимии)» дип аталган монографиямдә дә язып чыккан идем (12: 336-337). Бу тикшеренүләр археологлар тикшеренүләре белән дә дәлилләнә. 1988 елның җәендә Уфа археологлары Оренбургтан 100 чакрымга көнбатыштарак урнашкан Филипповка авылы янындагы сармат курганнарыннан өч йөзгә якын бик матур итеп эшләнгән әйберләр тапкан. Табылдыклар арасында иң күбесе — болан, сайгак, кабан, бүре, юлбарыс, балык, ташбака, фантастик кошлар һәм башка җәнлек, кош сурәтләре. Бу орнаментлар төркиләргә һәм шул исәптән безнең бабаларыбыз сарматларга хас бизәкләр.

Сарматларның да тарихы катлаулы, алар да тарихи сәбәпләр нигезендә урыннарыннан күчеп йөрергә мәҗбүр булган. Сарматларга нисбәтле матди культура истәлекләре урнашкан урыннарны Татарстан җирендә археолог-галимнәр А.Х.Халиков, П.Н.Старостин, Е.П.Казаков һ.б. тапкан, тикшергән.

Чыганаклар:

1. Селения казанского ханства по писцовым книгам//Археология и этнография Татарии. Вып.1./Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. — Казань, 1971.
2. Республика Татарстан. Административно-территориальное деление на 1 января 1992 года.
3. Россия. Полное географическое описание нашего отечества (Среднее и Нижнее Поволжье и Заволжье). Под ред. В.П.Семёнова. — СПб., 1901. — т.4.
4. Список населённых мест по сведениям 1859 г. XXXVI: Самарская губерния.//Обработан А.Артемьевым. 1864.
5. Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке, изданный под редакцией Д.А.Корсакова//Известия общества археологии, истории и этнографии в Императорском Казанском университете. — Т.XVIII. - Вып.4-6. — Казань, 1908.
6. Список населённых мест Казанской губернии. Лаишевский уезд. Составил И.А.Износов. — Вып.1. — Казань, 1898.
7. Бурганова Н.Б. О системе народного праздника джиын у казанских татар//Исследования по исторической диалектологии татарского языка. —Казань, 1982.
8. Невоструев К.И. Список с писцовых книг по г.Казани с уездом. — Казань, 1877.
9. Шестаков П.Д. По поводу сообщения Н.И.Золотницкого: «Лингвистическая заметка о названиях булгар, биляр и моркваши»// Известия общества археологии и этнографии. 1880-1882. — Казань, 1884. — Т.3.
10. Гордеев Ф.И. Позднесарматские элементы в топонимии Волжско-пермских языков// Всесоюзная научно-практическая конференция «Исторические названия — памятники культуры». 17-20 апреля 1989 г. Тезисы докладов и сообщений. — М., 1989.
11. Гарипова Ф.Г. Гидронимия Татарстана. — М.: Наука, 1991.
12. Гарипова Ф.Г. Татарская гидронимия (Вопросы этногенеза татарского народа по данным гидронимии) — Казань, 1998. ■

КАЗАНГА ГАСПРИНСКИЙ СКВЕРЫ КИРӘК!

Сөмбел Таишева

Ошбу фәһемле очрашуда без бишәү катнаштык – И.Гаспринский исемендәге матбугат үзәге җитәкчесе Айдер Әмиров, Симферопольдәге И.Гаспринский исемендәге кырымтатар китапханәсе директоры Гөлнара Яхъяева, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм мин – «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева. Әңгәмәбез барышында гомумтатар тарихына һәм бүгенге вазгыятькә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде.

Сөмбел Таишева. *Кырымда яшәүче кардәшләребез белән һәр очрашу — безнең өчен зур шатлык. Мәгълүм сәбәпләр аркасында өзелгән үзара туганлык җепләребез, ниһаять, отыры ялгана вә ныгый бара. Татарстанга бу юлы сәфәрегез кем тарафыннан һәм нинди максатларны күз уңында тотып оештырылды?*

Җавап. Быелның август аенда Ялтада Россия Федерациясе Дәүләт Советының күчмә утырышы узды, анда туризм мәсьәләләре буенча фикер алышуда Россия Президенты Владимир Путин белән Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Без Рөстәм Нургали улын бөтен татарларның лидеры буларак кабул итәбез. Әлеге очрашуда ул безгә һәм Кырымда яшәүче башка милләт вәкилләренә дә, Казанга килеп, Татарстанның күпьеллык уңышлы тәҗрибәсен өйрәнергә тәкъдим ясады. Шулай килеп чыкты ки, безне — кырымтатар вәкилләрен — делегация составына иң соңгы моментта гына расладылар.

Мин үзем берничә ай элек кенә Кырым Республикасы Министрлар Советы тарафыннан оештырылган Исмәгыйль Гаспринский исемендәге медиаүзәкне җитәкли башладым. Без төрле телләрдә фәнни-популяр әдәбият, милли мәгълүмат чаралары нәшер итәргә ниятлибез. Татарстандагы коллегаларыбыз белән нәкъ менә шушы өлкәдә хезмәттәшлекне ныгытасыбыз килә дә.

С.Таишева. *Бүген — Татарстанга эшлекле сәфәрегезнең өченче көне. Тәэсирләрегез, тәүге нәтиҗәләрегез нидән гыйбарәт?*

Җавап. Кызыклы очрашулар шактый булды. Шуларның берсен аерып әйтәсем килә. Ул — Казан Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашу. Рөстәм Нургали улы безгә Исмәгыйль Гаспринский исемендәге Медиаүзәк белән Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы арасында үзара хезмәттәшлек килешүе төзергә тәкъдим итте. Татарстан китап нәшриятында да булдык. Без Алтын Урда, Кырым һәм Казан ханлыкларына кагылышлы уртак басма проектлар тәкъдим иттек. Китапларыбызны алмашу теләге дә зур бездә. Барчабызга да билгеле факт: гасырлар дәвамында Кырымга бөтен ислам дөньясыннан — Мисырдан, Сүриядән, Ираннан, Әстерханнан һәм Казаннан китаплар килеп торган.

С.Таишева. *Иван Грозный гаскәрләре 1552 елда Казанны яулап алганнан соң, хан китапханәсе юкка чыга. Тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Сөембикә китапханәне Кол Шәриф мәчете мәдрәсәсенә тапшыра. Хан хәзинәсе һәм китаплар бүгенге көндә Мәскәү Кремлендә яисә Польшада саклана, дигән фаразлар да бар. Ә менә Кырым ханнары китапханәсенең язмышы нинди?*

Җавап. Тарихчылар фикеренчә, Кырымдагы хан китапханәсендә Алтын Урда ханнарының да кыйммәтле кулъязмалары булган. Вәләкин алар хан сараендагы 1835 елгы янгын вакытында юкка чыккан. Исән калган өлеше дә Россия Кырымны яулап алгач, 1783 елда Бакчасарайдан Симферопольгә (Ак мәчеткә) күчерелә. 1905 елда барлык архивлар тартып алына һәм Симферопольдән чыгарыла, 1975 елда әлеге бәһа биргесез хәзинәне Санкт-Петербургның (ул чакта — Ленинград) Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәсенә тапшыралар. Чыгарылган кулъязмалар арасында «Казаскәр дәфтәрләре»[1] дә була. Биредә Казан ханлыгына нисбәтле булган документлар саклануы да ихтимал.

Төрле мәрәкәгә таруга карамастан, Кырым Республикасы Дәүләт архивында, шулай ук И.Гаспринский исемендәге китапханәдә Кырым һәм Идел буе татарларының үткән тормышын чагылдырган басма мәгълүматлар бихисап.

Вахит Имамов. *Ватаныннан сөрелгән милләтләр аклана башланган көннәрдә кырым татарларының фаҗигале язмышы хакында татар әдипләреннән иң беренче булып Рөстәм Кутуй язып чыкты. Соңрак исә журналист Венера Якупованың «Крымские татары или привет от Сталина» дип аталган китабы дөнья күрде. Шәхсән үзем Кырымда 1989 елда булдым. Җирле хакимиятләрнең күп афәтләр, күп михнәтләр кичергән кырым татарларына үзләренең тарихи ватаннарында йорт салу өчен җир бирмәскә җан талашкан вакыт иде бу.*

Сүз уңаеннан, Сөләйман солтан турындагы яңа романымда Кырымга кагылышлы өлеш тә бар. Әйтегез әле, кырым татарлары бүген ни хәлдә яши?

Җавап. Кырым татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләү — иң зур проблемабыз. Кырымда якынча 260 мең милләттәшебез бар. Шул ук вакытта Төркиядә җиде миллионга якын кырым татары яши. Ни кызганыч, депортация-сөрелүләр фаҗигаи эшен эшләде. Илдәге кардәшләребезнең күпчелеге ана телен юньләп белми. Без — ярымутрауның төп халкы — бүген биредә яшәүчеләрнең фәкать 10-12 процентын гына тәшкил итәбез.

Ләбиб Лерон. *Казан журналистлары кырым татар телендәге ATR тирәседәге вазгыятьне игътибар белән күзәтте. Быелның сентябрь аенда сездә «Милләт» дип аталган телевидение каналы ачылды. Әмма ATRнең Киевка күченүе сездә үкенү хисе уятмадымы?*

Җавап. Анкарадагы диаспора вәкиле — танылган бер тарихчының чыгышын интернеттан да табарга була. «Әгәр дә сез Путинның максатын беләсегез килсә, караимнәргә карагыз. Бүген алар берничә йөз меңгә генә калды һәм туган телләрен тулаем югалтты. Икенче вариант — Татарстан», — дип куркыта ул. Менә без Татарстанга килдек тә, һәммәсен үз күзебез белән күрдек. Борынгы Болгарга сәяхәт вакытында делегациябездәге һәркем — грекмы ул, әрмәнме, украинмы — барысы да таң калды. Беркемгә дә сер түгел ки, татарны тезләнергә дучар кылган заманнар булган. Әмма вакыт җиткән, татар иң башта бер аягына, аннары исә, менә хәзер, икенче аягына да нык басып тора! Яшәеш-тормышның бик күп яклары белән сез Россиягә, Мәскәүгә үрнәк булып торасыз. Милләт үзенең татарлыгы белән горурлана! Никадәр

[1] Казаскәр — «гаскәр казые», Госманлы империясендә хәрби һәм дини мәсьәләләр буенча баш хөкемдар.

оешмаларыгыз «Тат...»тан башлана — «Татнефть», «ТАТМЕДИА», «Татар-информ», «Татцентр»... Республикада яшәүче гайре милләтләр дә татарстанлы булулары белән горурлана, дип уйлыйм. Кырымда исә, ни кызганыч, кырымтатар лидерлары вазгыятьне катлауландыра. Бу җәһәттән ATR каналы да үзеннән өлеш кертә. Бер-береңне аңларга теләмәү һәм таркаулык яшьләрне Төркиягә яисә Аурупага мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр итә. Халыкка үз лидеры кирәк. Лидерсыз халык бетә, юкка чыга!

В.Имамов. *Әле күптән түгел генә Казанда яшь төрки шагыйрьләр фестивале булды. Анда, шагыйрьләре тумый башласа, халык бетә, юкка чыга, дигән фикер яңгырады.*

Җавап. Тирән фикер. Сәләтле яшьләрне күрә, күтәрә белергә дә кирәк. Без, бергәләшеп, уртак татар һәм кырымтатар шигърияте җыентыгын чыгара алыр идек. Әдәбиятларыбызның тамырлары да уртак лабаса. Габдулла Тукай барча төрки халыклар өчен дә — даһи шагыйрь. Гомере дә булып, инкыйлабтан соң да иҗат итеп яшәсә, ни булыр иде, дип тә уйлыйм. Күренекле шагыйребез Әмди Гәрәйбайга да (Амди Гирабай) кыска гомер насыйп әйләде. Аны, милләтчелектә гаепләп, 29 яшендә Бутырка төрмәсендә атып үтерәләр. Ә нинди үзенчәлекле, биниһая зур талант! Ул Төркиядә укыган чорында «Кырым тарихы» дип аталган фәнни эш яза. Төрки халыкларның тел вә фикер, максат берлеге хакында була ул. Вәләкин ошбу легендар шәхес кардәш халыкларга бик аз билгеле. Аның каравы, гомумтөрки мәгърифәтчебез Исмәгыйль Гаспринскийның иҗатын һәммәсе белә. Ул һәм аның хәләл җефете Зөһрә Акчурина (Сембер губернасында туып үсә) иң беренче гомумтатар газетасы «Тәрҗеман»ны 1883 елда Бакчасарайда нәшер итә башлый.

Ә нигә дип әле Гаспринскийга Казанда бюст яки барельеф урнаштырмаска?! Россия империясендә йөзләгән мәктәп И.Гаспринский исемен йөрткән. Симферопольдәге бер мәктәп әле бүген дә — аның исемендә. Киләсе елда мәшһүребезнең тууына 165 ел тула, ә бит инкыйлабка кадәр Габдулла Тукайны — Кырымда, ә Исмәгыйль Гаспринскийны Казанда да үз иткәннәр.

Төрки милләтләр алдында Исмәгыйль бәй Гаспринскийның хезмәте биниһая зур. Аның кырым татарларын Төркиягә күчмәскә өндәве дә кадерле безгә! Габдулла Тукайдагы кебек: «Китмибез!»

Амди ГИРАЙБАЙ,
къырымтатар шагыйре
1901-1930

ТОКЪАЙГЪА

Эй тюрк-татар дюньясына шавле, нур сачкъан, Токъай,
Къара халкъкъа ана тильмен анъ ёлун ачкъан, Токъай,
Дертимизни, арзумызны джырлагъан, айткъан, Токъай,
Пек вакъытсыз гульдай солып, аслына къайткъан, Токъай.

Токъай, сенинъ къыйметинъни савлыгъынъда бильмедик,
Сен биз ичюн джан талаштынъ, джырладынъ да, сайрадынъ,
Талий сени къорлагъанда, козьяшынъны сильмедик,
Тек башынъа, озь башынъа такъдирге тиш къайрадынъ.

Ничюн, Токъай, арамызда танъ аткъанджек къалмадынъ?
Ничюн, Токъай, къалып кене ёлбашчымыз болмадынъ?
Бугунь матем тутамыз биз эшиталмай сёзюнъни,
Ёкълугъынъны пек туямыз, хатырлаймыз озюнъни.

Устазымыз, чолпанымыз, сен башымызсынъ, Токъай,
Джол косьтердинъ джашлыкъкъа сен о огъурсыз туньлерде.
Бугунь кене оджамызсынъ, ёлбашчымызсынъ, Токъай,
Бир чыракъдай корьдик сени биз къаранлыкъ куньлерде.

Дертли Токъай, монълы Токъай, омрю къыскъа джаш Токъай,
Халкъчы эдип шаирлернинъ ордусына баш Токъай,
Сенсинъ, Токъай, къальбимизде халкъ сюйгюси яраткъан,
Сенсинъ, Токъай, бугунь бизни «къара халкъкъа» къараткъан.

Инан, Токъай! Бугунь бу халкъ кучюн алды къолуна,
Талий чыкъып токътаталмаз энди онынъ джолуна,
Бакъыргъанынъ, чакъыргъанынъ сенинъ нафле кетмеди,
Ах, не языкъ коралмадынъ, омрюнъ вефа этмеди.

Урьмет сагъа тюрк-татарнынъ сайып сюйген Токъайы,
Акъикъаткъа, хакъкъа бола джанып кюйген Токъайы,
Тарихымыз байрам этсин, козь айдынлар ясасын,
Сендай шаир етиштирди, токъаизм яшасын!..

Акъмесҗит, 13 апрель, 1920

РАФАЭЛЬ МОСТАФИН:
«ӘНИЕМӘ МИНЕМ ИСЕМ ОШАМАГАН»

Соңгы вакытта Татарстан Милли музее фондлары язучы Рафаэль Мостафин мирасы белән дә тулыланды. Ә инде әдипнең вафатына 7 ел кала тутырган анкетасы журнал укучыларына да кызыклы булыр, дип уйлыйбыз.

Бигүк кыска булмаган гомеремдә миңа йөзләрчә анкета тутырырга туры килде. Торгынлык елларында чит илгә чыкканда яисә яңа эшкә урнашканда, төрле тикшерүләр, бүләкләүләр, персональ эшне тикшергән чакларда һ.б. Кайсыдыр югары начальник сине үзенә чакыра, ә синнән элек аның өстәлендә шәхси эшең ята...

Әлеге анкетаны исә мин укучы дусларым өчен тутырам.

Фамилия. Мостафин – татарлар арасында киң таралган бик гади фамилия. Каян килеп чыккан ул? Элек бит татарларда фамилия булмаган. Бабаем сөйли иде: аның әтисен, ягъни минем бабамның бабасы Габдулланы XIX гасырның икенче яртысында Оренбург губернасының Яңа Мусин авылы старостасы итеп билгеләгәндә, аның фамилиясен күрсәтү кирәк булган. Кайсысын сайларга, дип озак баш ватканнар. Габдулланың әтисе – ыру башы Мостафа исеменә тукталганнар. Өяздә моны хуплаганнар. Шулай итеп, без Мостафиннар булып киткәнбез.

Кайнар йөрәкле, эшчән һәм фәһемле Габдулла бабамны яхшы хәтерләгән кешеләр белән аралашу бәхетенә дә ирештем мин. Теләсә кемне алты мәчетле зур авылга староста итеп куймыйлар. Ә безнең ыру башын минем бабамнан башка беркем дә хәтерләми. Бабам сөйләгәнчә, Мостафаның ике хатыны булган, аның әбисе яшь хатынның җәберләүләреннән бик изаланган.

Бабамның кабере сакланган, мин анда булгалыйм. Ә башкаларның каберләре үлән белән капланган.

Исем. Исемем мөселманча түгел, татарларга да хас түгел – Рафаэль. Минем әтием Әхмәт – 20-30 нчы еллар комсомолы – яңа тормыш өчен көрәшкән. Ул бик тә сәнгатьне яраткан, улының рәссам булуын теләп, мине итальян даһиы исеме белән атаган. Әниемә бу исем ошамаган, ул миңа Әнис дип исем кушарга теләгән. Ләкин, чын татар хатыны буларак, иренә каршы килергә кыймаган.

Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, кешенең исеме аның характерын һәм сәләтен чагылдыра. Минем мисалда исә олы исем кешенең холык-фигыле түгел, ә исем кушкан кешенекен күрсәтә булып чыга. Үз үзеңә бит исем сайламыйсың!

Әтинең исеме. Ничек кенә булмасын, мин үземне исемле иттем. Меңнәрчә кешеләр мине китапларым һәм мәкаләләрем буенча Рафаэль Мостафин буларак белә. Күбесенчә миңа өйгә яисә эшкә шылтыратып: «Рафаэль Мостафинны телефонга чакырырга мөмкинме?» – дип сорый. «Бу нинди панибратство?!» – дип хатыным ачулана, билгеле мин моңа ияләшкән. Минем әтиемнең исеме – Әхмәт. Ул – кадровый офицер, Фрунзе исемендәге Кызыл Армия академиясен тәмамлый. Полк командиры, аннан — дивизия штабы начальнигы вазифасында 1943 елның 26 сентябрендә Ленинград янындагы сугышларда һәлак була. Авиабомба штаб машинасына турыдан-туры эләгә...

Туган елым. Паспорт буенча 1931 елның 14 мае. Ә чынында исә шул елның 3 мае. Әти землемер, яңа оешкан Баулы совхозында җир үлчәгән, мин туган көнне командировкада булган. Ун көннән кайтып ЗАГСка баргач, минем 3 майда ук туганлыгым турында әйтергә оялган...

Бу хәтта бик җайлы. 3 майда мине туганнарым һәм иң якын дусларым тәбрик итсә, 14 майда барлык рәсми кешеләр һәм оешмалар котлый.

Милләтем. Татар. Туган телен белсә дә, күбесенчә рус телендә сөйләшүче һәм язучы шәһәр татарлары бар. Мин ике телле татарлардан, миңа рус мәдәнияте татар мәдәнияте кебек үк якын. Россиядән аларны аерып булмый.

Профессиям. Язучы һәм журналист. Дөресрәге – әдәби тәнкыйтьче. Ярослав Гашек әйткәнчә, әгәр дә яза белсәм, мин шулайрак язар идем әсәрләрне,

Сулдан уңга: Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев, Флүс Латыйфи. Аккош күле буенда. 2004 ел

дип өйрәтүче. Профессия бигүк данлыклы булмаса да, соңгылардан да түгел. Мине ашатучы, хәтта миңа шөһрәт тә китерүче профессия.

Белемем. Югары. 1954 елда иң мәртәбәле югары уку йортын – Казан университетын тәмамладым һәм мин моның белән горурланам. Университет миңа күп нәрсә бирде: аякка бастырды, кеше итте. Гади кеше генә түгел, XX гасыр зыялысымын. Мин, ярты гасыр үткәч тә, университет белән элемтәне өзмим, журналистика бүлегенең Дәүләт имтиханнар комиссиясен җитәклим.

Эш урыным. Ярты гасыр эчендә мин күп эш урынын алыштырдым. Барысын да санап тору озынга китәр иде. Татар мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыттым. Баулы районында райком комсомолы секретаре булдым. Район һәм шәһәр газеталары редакциясендә эшләдем. Казан телевидениесендә әдәби программаларның баш редакторы, Татарстан Язучылар берлегендә җаваплы сәркатип, «Казан утлары» һәм «Татарстан» журналларының баш редакторы вазифаларын башкардым.

Басылган хезмәтләрем. 36 китабым бер миллион 260 мең данәдә басылып чыкты.

Хөкүмәт бүләкләре. «Почёт билгесе» ордены, М.Җәлил исемендәге премия лауреаты, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Киләчәккә планнарым. Берничә китап әзерләдем һәм аларның басылып чыгуына өметләнәм. Шулай ук оныкларымның үсеп җитүен һәм аларның балаларын күрәсем килә.

2004

Матбугатка Татарстан Милли музее өлкән гыйльми хезмәткәре ***Флёра Дәминова*** *әзерләде*


ГАМБӘР МУЛЛА
Ринат Фәхретдинов
Д.Нәурузова коллажы

— Җегетләр, торыгыз, уяныгыз инде! Болай озак йоклап ятсагыз, балык калмый бит елгада...

Бу тавыш миңа бик ерактан килгән кебек тоелды. Шулвакыт әтәч кычкырып куйды. Сыер мөгерәп алды. Эт өргән тавыш ишетелде...

— Әйдә, Әнвәр, торыйк, балыкка соңламыйк.

— Мин әзер!

Без, Таһир белән икәү, җәһәт кенә баскычтан төшкәндә Әлдермеш Әлмәндәрен хәтерләткән Әхмәт бабай болдыр янында, кулына комган тотып, иңбашына ак тастымал асып, безне көтеп тора иде...

Абзар янындагы арбага бәйләнгән ат, безне күргәч, канәгатьсез генә пошкырып куйды. Әхмәт бабай аны җигәргә кереште. Таһир Әхмәт бабайга булыша башлады. Миңа, шәһәр малаена, аларга кызыгып карап торырга гына туры килде. Әхмәт бабай барлык кирәк-яракны алдан хәстәрләп куйганга күрә, без ишегалдыннан бик тиз җыенып чыгып киттек. Арба шыгырдап барган көйгә мин тагы йокыга талганмын. Чишмә тавышын ишетеп уянган вакытта Әхмәт бабай зур пластик савытка су тутырып азаплана иде. Мин арбадан җәлт кенә сикереп төшеп, бабайга сулы савытны күтәреп куярга булыштым да улактан аккан чишмә суын кушучлап эчәргә тотындым. Су бик тәмле булып тоелды.

— Нәрсә, улым, су тәмлеме?

— Бик тәмле, Әхмәт бабай.

— Тәмле булмаска, Гәмбәр мулла чишмәсенеке бит ул! Мондый тәмле, шифалы су тирә-якта бүтән юк. Хак булса, Бөек Ватан сугышыннан кайткач, Гамбәр мулла чишмә урынын башта винтовка штыгы белән казыган, диләр. Бәреп чыккан чишмәнең суы искиткеч тәмле булуын күргәч, Гамбәр бабайның ул чишмәне зурайтып, агач бура белән бурап, имәннән улак ясап куйганын мин дә хәтерлим әле. Бигрәк тә көчле шәхес иде шул Гамбәр мулла...

— Бабай, сөйлә әле безгә Гамбәр мулла турында.

— Сөйләрмен, улым, сөйләрмен...

...Әхмәт бабай кай арада учак якты да кай арада гына без тоткан балыклардан уха пешереп өлгертте. Хәер, балык тоту мәрәкәсе белән без вакытның ничек үткәнен дә сизмәдек. Әхмәт бабай таллар ышыгына табын әзерләп, уханы тирән тимер тәлинкәләргә салып безне чакырды.

Бераздан Әхмәт бабай агым суга карап тын калды. Мин шуннан файдаланып:

— Әхмәт бабай, син Гамбәр мулла турында сөйлим, дигән идең бит! Без тыңларга әзер! — дидем.

Бабай шул сүзне генә көткән кебек, безгә ялт итеп карап алды. Бераз тамак кыргалап алгач, учакка утын өстәде дә ашыкмыйча гына сөйли башлады...

— Колхозлар төзелә башлаган елларда Гамбәрне әти-әнисе, ягъни атаклы Абдулла мулла һәм аның хатыны Айбикә абыстай белән бергә Себергә сөрәләр. Мин моны хәтерли алмыйм, чөнки ул чакта тумаган булганмын әле. Халык сөйләвенә караганда, авылдан чыккач, кулларындагы төенчекләрен җиргә куеп, алар өчәүләп бик озак намаз укып дога кылганнар. Ул вакытта булачак Гамбәр муллага унике-унөч яшьләр булгандыр. Әйтергә кирәк, ул вакытта аны беркем дә Гамбәр дип йөртмәгән, чөнки аның чын исеме Гали иде. Ә Гамбәр дигән исем-атны халык аңа соңыннан бирде. Ни өчен андый исем бирелгәнен бераздан төшенерсез, җегетләр. Авылдан чыгып киткәндә алар ни теләп дога кылганнардыр, аны белсә,

бер Аллаһы Тагәлә генә беләдер. Минемчә, алар туган-үскән җиргә кире кайтырга язсын, дип теләгәннәрдер. Тик аларның берсенә генә туган якка әйләнеп кайтырга насыйп булды — ул да булса Галигә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Гали Себердән үз теләге белән фронтка китә. Дүрт ел сугыш кырларында артиллерист булып дошманга каршы көрәшә ул. Сугыштан соң аның авылга кайтканын мин бик яхшы хәтерлим. Яшь егетнең гимнастёркасы тулы орден-медаль иде. Ул хәтле күп хәрби бүләккә лаек булган кеше бүтән юк иде безнең авылда. Капитан дәрәҗәсендә булгангамы, фронтовиклар арасында аның абруе зур булды. Ә фронтовиклар, беләсегез килсә, теләсә кемне хөрмәт итми.

Колхоз председателе сугыш героеның авылда калу теләгенә каршы килми. Галинең халык дошманы баласы булуына күз йомарга мәҗбүр була, чөнки авылда хезмәткә ярарлык ирләр бармак белән генә санарлык. Яшь һәм көчле егетнең колхоз өчен бүләк булуын күз алдына китерүе кыен түгел. Гали җиң сызганып тимерче булып эшли башлый. Киң күңелле, алтын куллы эшчән егетне авыл халкы чын күңелдән ярата. Тик колхоз җитәкчеләренә аның көненә биш тапкыр намаз укуы бер дә ошамый, ләкин алар тимерченең бу изге шөгыленә бер сәерлек итеп кенә карап, күз йомарга мәҗбүр була. Озакламый Гали авылның иң матур кызларыннан булган Нәфисәгә өйләнә. Алар ике кыз, бер ул үстерәләр. Алтмышынчы еллар башында Шәйхелислам хәзрәт вафат булгач, Гали абый ике вазифаны — тимерче һәм мулла булуны берьюлы башкара.

Дөресен генә әйткәндә, аның вазифалары елдан-ел арта барды. Мәсәлән, ул халыкны дәвалау белән дә шөгыльләнде. Баштарак кешеләргә киңәшләр генә бирсә, соңыннан чын табибларча практик ярдәм күрсәтә башлады.

Шулай көннәрдән бер көнне уналты яшьлек Салих, өянәге тотып, кибет каршында егыла. Ул, авызыннан күбекләр чыгарып, тыпырчына башлый. Аның янына шундук халык җыела, ләкин беркем дә бу мескенгә ярдәм күрсәтә алмый. Салихның бәхетенә кибет яныннан тимерче Гали узып барган була. Ул, йөгереп килеп, егетнең авызына агач ботагын сындырып каптыра, берничә ирнең кәчтүмнәрен салдырып, аның баш очына куя да Салихның тәннәрен сыйпап әкрен генә дога укый. Бераздан авыру тынычлана. Шулвакытта Салихның атасы Саескан Зөфәр чабып килеп җитә дә, улын кочаклап, үкереп елап җибәрә. Зөфәрне тикмәгә генә Саескан дип атамаганнар, чөнки ул ашыгып-кабаланып сөйләгәндә сүзләрнең бер өлешен йотканга күрә күпләр аның сөйләгәнен аңлап бетерми иде. Тимерче Гали аны тынычландырырга керешә:

— Елама, Зөфәр. Терелтәм мин улыңны. Ышанасыңмы шуңа?

— Ышанам, син бит гамбәр! Гамбәр бит син!

Галинең күршесе Хәмит аптырап сорый:

— Нинди Гамбәр булсын ул! Акылдан шаштыңмы әллә?

— Гамбәр ул, пәйгамбәр!

Хәмиткә Саескан Зөфәр әйткән сүзләрнең мәгънәсе барып җиткәч, ул шаркылдап көлә башлый:

— Пәйгамбәр-гамбәр, ха-ха-ха!

Халык, Хәмиткә кушылып, рәхәтләнеп көлә. Шушы көннән башлап авыл халкы Галине Гамбәр мулла дип йөртә башлый да инде. Әйтергә кирәк, Гамбәр мулланың дәвасы гади, ләкин нәтиҗәле булуы белән кешеләрне җәлеп итте. Ул авыруның кулын тотып, күзләрен йомып, бераз мәрткә киткән кеше кебек торганнан соң, өшкерер, йә булмаса, үзе җыеп ясаган үләннәр төнәтмәсе бирер иде. Башка төрле дәвалары да гадәти булмавы белән аерылып торды. Шуңа мисал — тимерче булышчысы Фәритнең ямьле җәй уртасында күзенә кечкенә тимер кыйпылчыгы керүе турында вакыйга. Ул көнне Гамбәр мулла йомыш белән күрше авылга киткән

була. Фәритнең күзендәге тимер кыйпылчыгын авыл медпунктында алып булмаганлыктан, аны район үзәгенә машина белән озаталар. Район үзәгендәге күз табибы да Фәриткә ярдәм итә алмый. Ул республика хастаханәсенә юллама биреп, бернинди дә ярдәм күрсәтмичә, егетне авылга кайтарып җибәрә. Бу хәбәрне ишеткән Гамбәр мулла үзенең ярдәмчесен, әлбәттә, авыр хәлдә калдырмый. Ул идәнгә палас җәйдертә дә, Фәритне шуңа яткызып, аның кып-кызыл булып шешенгән күзеннән теле белән ялап тимер кыйпылчыгын чыгара. Икенче көнне Фәрит берни булмагандай эшкә чыга. Гамбәр мулланың даны күрше авылларга да таралгач, аның янына авырулар бик күп килә башлады. Хәзрәт бик тә кешелекле, риясыз шәхес булганлыктан, ул дәвалаганы өчен кешедән сукыр бер тиен дә алмый иде. Шулай да аның шөһрәтеннән көнләшүчеләр һәм табиблык эшенә аяк чалучылар җитәрлек иде.

Беркөнне «Кызыл байрак» гәҗитендә «Ялганчы мулла — алдакчы табиб» дигән мәкалә чыкты. Мәкалә авторы Гамбәр мулланы халыкны алдап акча җыюда гаепләде. Авылга районнан тикшерүче килеп төште. Дөньяда намуслы бәндәләр дә аз түгел шул. Олы яшьтәге тәҗрибәле тикшерүче, кешеләр белән аралашкач, хәзрәтнең гаепсез икәнен аңлап алып, кире район үзәгенә кайтып китә.

Олыгая башлагач, Гамбәр мулла тимерчелек һөнәрен калдырып, руханилык хезмәтен гомеренең соңгы көненә чаклы башкарды.

Мең тугыз йөз сиксән өченче елда булса кирәк, Гамбәр мулла белән бик кызык бер вакыйга була. Җәйнең матур кичләренең берсендә, көтү кайткач, Гамбәр мулла колхоз председателенең идарә каршында торган машинасын күреп ала да, җитәкче бүлмәсенең ишеген шакып, рөхсәтне дә көтмичә бүлмәгә уза. Бу вакытта ике авылдаш һәм сыйныфташ — колхоз председателе Мансур һәм райкомның беренче секретаре Госман Наилевич — өстәл янында «бер ярты»ны «бөкләп» утырган чак була.

Гамбәр мулла бик тә уңайсызланып:

— Гафу итегез, егетләр. Мин башка вакытта керермен, — ди дә ишеккә таба борыла. Госман Наилевичның кәефе күтәренке булгандыр, күрәсең. Ул:

—Тукта, Гамбәр абзый. Без бит чит кешеләр түгел. Ни йомыш белән килдең, сөйләп җибәр! — ди.

— Бик зур йомыш белән килгән идем дә бит менә... Зират коймасы бик беткән, егетләр. Терлекләр каберләр өстеннән йөри. Барыбыз да шунда ятасы, такталар белән ярдәм итсәгез иде.

Госман Наилевич кырлы стаканга аракыны тутырып сала да, хәйләкәр елмаеп, Мансурга күз кыса:

— Гамбәр абзый, әгәр шушыны бетергәнче эчеп җибәрсәң, ипидер менә, ярдәм итәчәкбез. Шулай бит, Мансур!

Колхоз председателе канәгать төстә баш селки.

— Шаяртмагыз инде, егетләр! Гомердә кабып караган нәрсәм түгел, зур гөнаһ бит ул чын мөселман кешесенә, — ди Гамбәр мулла.

— Шартымны үтәмәсәң, ярдәм итмәячәкмен. Үзеңә кара...

Гамбәр мулла беразга уйга талып торган да, кинәт, стакандагы сыеклыкны төбенә хәтле бушатып куйган. Ике сыйныфташ шаулашып кул чаба башлаган.

— Егетләр, моны сезгә кызык булсын дип эчмәдем. Ә барлык мәетләрнең рухлары рәнҗеп ятмасын өчен шулай эшләдем. Сугыш вакытында госпитальдә йөрәк яныннан снаряд кыйпылчыгын алган вакытта да спирт тәкъдим иткәннәр иде, ул вакытта грамм да капмадым! — дигән дә хәзрәт күлмәген күтәреп кызыл җәрәхәт эзләрен күрсәткән. Мондый борылышны көтмәгән ике дус бик тиз авызларын җыйган. Госман Наилевич, җитдиләнеп:

— Син безне, ике ахмакны, зинһар, гафу итә күр! Ә әйткән сүзебездә без торырбыз, ярдәм итәрбез!

Чынлап та зиратны әйләндереп алырлык такта да, койманы буяп чыгарлык буяу да табылды. Хәтта зират капкасының башына тимердән ясалган, алтынга буялган ай да барлыкка килде.

Бу вакыйгадан соң күп тә үтмәде, беренче секретарьның хәләл җефете вафат булды. Ярты елдан соң Госман Наилевич күрше авылдан үзеннән унике яшькә кече Сания исемле инсафлы һәм бик тә чибәр бер кызга өйләнергә уйлый. Кызның ата-анасы каршы килми килүен, әмма бер шарт куя — ЗАГСка хәтле мулладан никах укытырга. Әлбәттә, район коммунистлары башлыгына бу шарт бик ошап бетми. Әмма ризалашмыйча да булмый.

Кышкы көн кичкә авышкач, Гамбәр мулла яшәгән йортның капка төбенә кара «Волга» машинасы килеп туктый. Рульдә райком секретаре үзе, ә аның янында чибәр Сания һәм арттагы урында председатель Мансур һәм аның хатыны утырган була. Алар, хәзрәт өенә кереп, мөселман кануны буенча никах укуны үтенәләр. Гамбәр мулла ике шаһит алдында никахны укып, Госман белән Санияне ир һәм хатын дип игълан итә. Госман Наилевичка теш кайрап йөрүчеләр, бу хәбәрне ишетеп, партиянең өлкә комитетына шикаять яза. Имзасыз хатта алар райкомның беренче секретарен динне яклаучы һәм дин кануннары белән яшәүче кеше итеп күрсәтә һәм, дәлил итеп, зиратны төзекләндерүдә матди ярдәм итүен, дин әһеленнән никах укытуны язган була.

КПСС өлкә комитетының идеология бүлеген җитәкләүче зур чиновник имзасыз хаттагы фактларның дөреслеген тикшерергә үзе килә. Райкомга Гамбәр мулланы да чакырталар. «Госман белән Саниягә никах укыдыңмы?» дигән сорауга акыллы мулла күзен дә йоммыйча:

— Ул Алласыз бәндәгә тагы никах уку! Урамда сәлам дә бирә белми бит ул, борынын күтәреп, күрмәмешкә салышып үтеп китә. Вакыты җиткәч Ходай Тагәлә янына барасын онытып йөргән кешедән ни көтәсең. Кызганыч, шундый кеше район хакиме булсын инде. Никахны, беләсегез килсә, лаеклы кешеләргә генә укыйм мин.

«Зиратны төзекләндерүдә ярдәм иттеме?» дигәч, мулла ярдәмне кире какмый, ләкин ул эшне атасы Наилнең каберендә терлек йөрмәсен өчен эшләгәнен әйтә. Имеш, көтәрсең аңардан изгелек, ул атасы хакына гына эшләнгән эш бит, дип җавап биргән мулла. Гамбәр мулла Госман Наилевичны никадәр сүксә, шулкадәр райком секретарена файда иткәнен бик яхшы аңлап, аның «кирәген бирә». Кыскасы, зур чиновник имзасыз хаттагы фактларны дөрес түгел дип таба һәм безнең хәзрәтнең акыллы эш итүе аркасында талантлы җитәкче үзенең урынында кала. Менә шушы хәлдән соң Госман Наилевич белән Гамбәр мулланың дуслыгы ныгый. Бер караганда, аларны бернәрсә бәйләми кебек. Киресенчә, чын коммунист буларак, район җитәкчесе Аллаһы Тәгаләгә ышанмый, ә Гамбәр мулла бар дөньяны юктан бар иткән Бөек Затка җаны-тәне бәлән табына. Район башлыгы авылга кайткан саен зирәк, укымышлы мулланы күрергә тырыша, аның белән бик озак гапләшеп торырга ярата. Алар үзләренең дөньяви карашларын бер-берсенә һич кенә тагарга тырышмый һәм шулвакытта бер-берсе белән аралашудан искиткеч ләззәт таба иде.

Үзгәртеп кору елларында Гамбәр муллага халык еш агылды. Беркөнне Гамбәр мулланың йортына илледән узган, кырынмаган, әрсез күзле бер шома кеше килеп керә. Аның шешенүдән кечерәйгән күзләре, кырынмаган йөзе, кызыл борыны аракыны артык еш кулланып яшәгәнлеген ап-ачык күрсәтә иде. Ул кергән вакытта мин мулланың өендә йомыш белән булганлыктан, аларның сөйләшүенә шаһит булырга туры килде. Гамбәр мулла керүчегә текәлеп карап торды да, көлемсерәп:

— Әһә, килдеңме? Син бит журналист, минем турында бик күптән мәкалә язган идең, шулаймы?

— Шулай. Мәкаләнең исеме «Ялганчы мулла — алдакчы табиб» иде. Менә, ялгышлыгымны төзәтергә килдем.

— Син ялгышлыгыңны төзәтә торган кеше түгел. Вакыт төзәтер синең хатаңны. Син бит теге вакытта килеп тә карамадың яныма, ә мәкаләңне яздың. Ник хәзер килдең, килмичә генә язарга иде.

— Начар гамәлне чиктән тыш искә алу мулла кешегә килешми. Минем эшем шундый иде дә вакыты шундый иде.

— Аны искә алу килешмәгәнен беләм, синең белән килешәм, тик вакытка яисә һөнәргә сылтап кешегә яла ягуны акларга хәтта муллага да бик кыен шул. Әле бит мин сиңа Госман өстеннән имзасыз хат язуың турында белгәнемне әйтмәдем. Ярар, Аллаһы Тәгалә кичерсен үзеңне. Ник дисәң, синең җавабыңны алдан ук беләм. Зур урындагы кешеләр кушты, каршы килә алмадым, дип акланырсың…

— Дөресе шул бит аның!

— Синең дөреслегең намуслы кешеләрнең дөреслегеннән нык аерыла шул. Минем сиңа киңәшем шул: ташла эчүеңне һәм кылма начарлык кешеләргә. Әле алда гомерең бар. Яшә чын кешечә. Ә хәзер чыгып кит, мин сиңа әйтәсемне әйттем.

Озак та үтмәде район гәҗитендә «Гамбәр мулла — чын халык табибы» дигән мәкалә чыкты. Мәкаләнең авторы Гамбәр мулланың дәвалау осталыгын чамадан тыш мактаган иде. Ләкин бу язма Гамбәр хәзрәткә ләззәт китермәде. Чөнки ул урамда минем кулымдагы яңа гына басылган гәҗиткә ымлап:

— Укыдыңмы тегенең мәкаләсен? Кешенең фикере ничек тиз үзгәрә. Мактавы да чын түгел, ниндидер ясалма, тьфү! — Мулла бу сүзләрне чын күңеленнән әрнеп әйтте.

Гамбәр мулла озын гомеренең азаккы көненә кадәр хәрәкәттә булды. Ике мең дә унберенче елның егерме сигезенче октябрендә аңа 94 яшь тулды. Ә егерме тугызынчы октябрьнең иртәсендә авылдагы ирләргә кабер казырга әйтеп йөрде. Бу хәзрәт тарафыннан гадәти хәл булганга, берсе дә гаҗәпләнмәде. Тик гаҗәбе шунда иде ки, кем вафат булды, дип кем генә сорамасын, Гамбәр мулла барчасына, өйләдән соң белерсез, дип әйткән. Кабер казучылар, үзләренчә фаразлап, күрәсең, хәзрәткә телефоннан шылтыратканнардыр да, ул, олы кеше буларак, вафат булучының исемен хәтерендә калдырмагандыр, дип уйлаган.

Гамбәр мулла шул арада өйдәгеләреннән мунча яктырып кереп, чиста яңа киемнәрен киеп, өйлә намазын укыган да, күптәннән әзерләгән кәфенлеген янына хәстәрләп, түшәктә кулларын йөрәк янына куеп, мәңгегә йокыга талган…

Менә, егетләр, әгәр дә безнең арабызда Гамбәр мулла кебек кешеләр булмаса, милләтебез тозсыз аш кебек булыр иде…

Бу сүзләрне әйткәндә, Әхмәт бабай кулындагы таягы белән күмерләре суына башлаган учакны яңадан тергезергә маташты.

Мин Әхмәт бабайның соңгы җөмләсе турында уйлый башладым. Чынлыкта, Гамбәр мулла, Әлдермештән Әлмәндәр, Әхмәт бабай, Госман Наилевич һәм аларга охшаган миллионлаган кеше булмаса, татар чын татар булмас иде. Алар бакыйлыкка киткәч, җирдә без калырбыз, ә без киткәч — кем калыр? Милләтебез тозсыз аш кебек булмасмы? Авыл юкка чыккан саен саф чишмә суы кебек изге милләт кешеләре каян ургылып чыгар икән? Вакытында утын салмасаң, күмерләре суына башлаган учакны тергезү кыен ул. Үзгәртеп коруның утыны күпмегә кадәр барыр икән?

Минем бик үк күңелле булмаган уйларымны кәккүк тавышы бүлдерде: бер, ике, өч… егерме… егерме биш… Кемнең гомерен саныйсың син күке? Сөекле милләтемнекен түгелме? ■

Зур Буа күренеше

АРТ КАПКАДАН КЕРГӘНДӘ...

Илдар Кыямов

(Татарстанның Чирмешән районы Кара Чишмә авылында яшәүче якташларым турында уйланулар)

Кара Чишмә авылының Аръяк күренеше

«АВЫЛ КЕШЕСЕ БИТ УЛ»!

Татар халкының бүтән төркемнәреннән мишәрләр аерылыбрак тора. Бу хакта күренекле тарихчыларыбыз да язып калдырган. *«Мишары народ рослый и довольно красивый. По характеру добрый, гостепреимный, в поступках своих смелый и благородный, народ бравый и стыдливый, в обещаниях своих твердый».* (Гайнутдин Ахмеров. Избранные труды. ТКИ. 1998, 158 стр.) Ефимий Малов та безнең адреска җылы сүзләр әйтә: *«На самом деле мишары добродушнее и благорасположеннее к другим, чем татары-мухаммедане, последние уклончивее и хитрее»*, — ди ул «Сведения о мишарях» дигән хезмәтендә. (Типография императорского университета. Казань. 1885 г.) Ефимий бабай белән бер нәрсәдә генә килешеп бетеп булмый: шомалыкка, «чошлыкка» һәм хәйләкәрлеккә безнең мишәр халкы да әлхәмделилләһи генә… Мин моны Кара Чишмә авылы мисалында дәлилләргә тырышырмын.

Мишәрнең күркәм вәкиле булган безнең авыл халкы, чыннан да холык-әхлак ягыннан, райондашлар фикеренчә дә, читтән килгән кешеләр күзәтүенчә дә шактый үзенчәлекле. Тел дә үзгә, сөйләшү рәвеше, үзара мөнәсәбәт, чит-ят кешегә мөгамәлә — бар да аермалы. «Кара Чишмәдән кыз алма, Кара Чишмәгә кыз бирмә», дип сөйлиләр иде бабайлар», — ди Бәркәтә егете, эшмәкәр Радик Төхфәтуллин. (Алай да беренче хатынының тамырлары Кара Чишмәгә килеп тоташа...) Метрика кенәгәләренә күз салганда да Кара Чишмә егетләренең тирә-як авыллардан гына түгел, хәзерге Аксубай-Норлат ягы, Чистай тирәсе, Бөгелмә, хәтта Самара өлкәсеннән дә килен төшерүләре күренә. Начар кешегә кыз бирмәсләр иде! Ул заманнарда кыз баланың нинди гаиләгә, кем кулына барып төшәчәген ата-ана бик нык тәфтишләгән бит...

Туймәтләрнең безгә карашы да үзенчәлекле. Күрше авылыбызның бер агае Кара Чишмәдән Кәлимә исемле кызны алган була. Ул гомер буе: «Карешмәдән эт алсаң, усал була, ә хатын алмасаң — яхшы», — дип сөйләгән имеш. (Безнең Кәлимә әбекәй бөтенесен җептән генә йөрткән ахрысы!) Болар барысы да халыкның шаяруы гына, әлбәттә. Бездә укытучы булып эшләп алган Иске Кади егете Марсель Мортазин да: «Элек Кара Чишмә кырыенда кара багана утыртылган булган, шуны күреп юлаучылар авылны читләтеп узып китәргә тырышканнар. Сездә үткен, усал кешеләр яшәгән, авылның исеме дә «кара» бит», — дигәнрәк фикер әйткәне бар. Болары — халыкның иҗат фантазиясе нәтиҗәседер. Бабайларыбыз ул дәрәҗәдә үк кансыз булмагандыр, дип беләм. Мәгәр үткенлек, һәртөрле хәлдән дә чыгу җаен табу, берникадәр эпатаж, хәтта артистлык сыйфатлары — боларын инде яшереп калып булмый. Авылдашлар турында яман фикерләрне исә безнекеләрдән кыен күргән, үз булдыксызлыгы аркасында «чыбык ашаган» кешеләр тарата, дип беләм. Безнең халык дөрестән дә гаделсезлекне, урынсыз золымны, чамадан чыгуны, кирәгеннән артык масаеп китүне, «эре бәрәңге ашаганнарны» өнәп бетерми шул. Ә инде ихлас, пакь

Ындыр табагында. 1937 ел

Авылның балта осталары. 1960 нчы еллар

күңелле, булсынга йөрүче бәндәләрне, әдәп-хәя белүчене кем кыерсытсын? Бу фикеремне дәлилләрдәй вакыйга авыл тарихында да бар. Сугыш арты елларында районнан исәпсез-хисапсыз тикшерүчеләр, надзор-дозорлар, уполномоченныйлар, инструкторлар армиясе авылга ябырыла. Ач үлемнән ничек булса да исән калырга теләгән крәстиән халкының соңгы кисәген тарткалаганнары да очрый, колхоз эшен күзәтәләр, икмәкне дәүләткә «югалтусыз» озатуны кайгыртталар. Аларның да төрлесе булгандыр инде. Кайсысы халыкның хәлен аңлаган, кайсысы мескен колхозчының яшергән бер уч бодаен «күрмәгән»дер. Күрсә дә кисәтү-фәләннән узмагандыр. Арадан берсе — районнан килгән «уполноймоч» аеруча принципиальлеге белән аерыла. Көнне-төнгә ялгап кырда бил бөккән апаларның гына түгел, ил азатлыгы хакына гомерен биргән фронтовикның ятим баласын да кызганмыйча, кулларындагы ризыкларын, җыйган печәнен, капчыкларын алып кала, суд юлларында йөртә икән. Йә, фашистлардан ни аермасы бар? Инде бала-чага, хатын-кызны кимсетүе генә түгел, ирләргә дә кул күтәрә башлагач, Европаны азат итеп кайткан икешәр метрлы гайрәтле егетләребез бу бәндәгә хәйләкәр тозак әзерли — үзе сизмәгәндә генә тарантасына бер капчык бодай салалар да аулак җирдәрәк туктаталар.

— Йә, абзый, нәрсә бу? — диләр аңа. — Ач колхозчы баласының авызыннан бөртекләп тартып аласың, үзең дәүләт байлыгын капчыклап урларга булдыңмы? Әйдә, бодаеңны үлчибез... Вәкил нәрсә әйткәндер, ләкин безнең егетләр аны ныклап кисәтә:

— Кара аны, абзый, әгәр тагын авылның берәр кешесен рәнҗетсәң, җаен табабыз, черетәбез, шуны белеп тор!

Авыл халкына бердәмлек, татулык сыйфаты да хас. Нинди генә сынау башка төшсә дә, бергәрәк булу, бер-береңә ярдәмләшү гадәте! Тормышның меңләгән сынавы алдында калганда, язмыш дилемма каршына китереп терәгәндә, «Авыл кешесе бит ул!» дигән тылсымлы сүз ярдәмгә килә. Димәк, Кара Чишмә бәндәсе юлыңа тарыды икән, хәлеңнән

килсә, булыш. Юк икән, аңа комачаулама, мөмкин кадәр аны рәнҗетүдән саклан — бусы да язылмаган кануннарыбыздан, дип беләм...

КАРАБОДАЙ СУ ҮТКӘРӘ

Иң әүвәл телдән башлыйк. Кара Чишмәнең ике кешесе үзара сөйләшә икән, өченче кеше, читтән килгәнрәк булса бигрәк тә, боларның ни турында гәп корганын аңламаска мөмкин. Хөсәенов Хәниф, бригада җыеп, читкә шабашкага чыккан. Ләкин ни сәбәптәндер, эшләре комга тәрәлгән, әллә материалны бозганнар, әллә хуҗа арзанга эшләтмәкче. Мондый очракта бер генә ысул бар — качып китәргә. Тик тоткарлык чыга: егетләр качарга җыенганда гына... хуҗалары төзелешкә килгән дә, текәлеп карап тора икән. Безнең егетләр ишек элеп маташкан мәл. Эш шулхәтле «кызу» — боларга мөмкин кадәр тизрәк ычкынырга кирәк. Шуннан Хәниф бабай «Кара Чишмә алымына» керешеп болай ди:

— Егетләр, ишекне эләргә кирәк, баштан сызабыз. Мин бу яктан «сызам», сез теге яктан җайлап кына «сызарсыз».

Тел мәсьәләсендә Кара Чишмәләр чыннан да киная, әйтеп бетермәү, төрттерү, шуклык, читләтеп «суктыру», халыкча әйтсәк, «күзгә карап артка тибү» алымнарын яратып куллана. Лашманнан Карешмәгә кунаклар төшә. Табынга утыралар. Хуҗабикә бер әтәләм (кавын формасында) ак май чыгара. Лашманнарның берсе майны кашыгы белән буеннан-буена сыдырып каба. Шуннан безнең бер кеше телгә килә:

— Бүген иртән кырга чыккан идем. Кырпак кына кар төшкән. Шунда чана белән үтеп киткәннәр, нишләптер, бер табан эзен генә күрдем! — ди.

Әкъдәс Мисбахов Әмир авылыннан безгә 1969 елны колхоз рәисе булып килә. Укытучылар көненә җыелалар. Укытучы ханымнар соравы буенча, председатель җәмәгате Разыя апаны да алып килә. Мәҗлес башлана. Хатын-кызлар бөтенләй чит темага сөйләшкән сыман сүз башлый:

— Фәррахша абзыйлар ягындагы кыркапканың такталары төшкән икән...

Разыя ханым бөтен барлыгы белән борчылып:

— И, Ходаем, чөгендер кырына маллар чыгар инде алайса! — дип куя.

Кара Чишмә халкын белеп өлгергән хуҗа, тост әйтеп котлагач, болай ди:

— Җәмәгать, ул капканың такталары ышкылап әзерләп куелган инде, тик кадакларга гына өлгермәдек...

Шунда тынлык урнаша. Баксаң, Разыя ханымның ике теше төшкән булган, шуларны Шенталага барып куйдыртырга өлгермәгәннәр икән. Бу очракта «түбәдән су үткән» булып чыга. Аңлаешлы телдә әйтсәк, әңгәмә геройларының берсе безнең шартлы телне төшенә, сер фаш ителә, дигән сүз. Мондый очракта безнекеләр бер-берсен «башы карабодай белән япкан», дип кисәтеп куючан. Ягъни, арада безне төшенүче бар, сак булыгыз!

Әнә шулай «су үткән» хәлләрнең берсе 1969 елны була. Язучыларның бер төркеме көзге дәвердә Чирмешән районы буйлап йөри. Кара Чишмәгә Разил Вәлиев белән Батулла килеп чыга. Авыл уртасындагы кибеткә керәләр болар. Мичкәсе белән кызыл аракы кайткан, авыл ирләре шуның өстенә утырып ят кешене күзәтә икән. Батулланың сакал-мыек җибәргән чорлары. Безнең ирләр мондый йөнтәс кеше күргәннәре булмагач, үзара сөйләшә икән:

— Карале, быел Чатлауда урмаган арыш калдырганнар. Нәрсә дип калдырганнар икән инде аны?

Эшне тиз төшенеп алган Батулла:

— Комбайны ватылган иде шул! — дип куймасынмы... Бу вакыйганы мин Рифкать Гомәровтан ишетеп калган идем.

Авылдан авылга кунакка йөрешүләр вакытында әлеге тел көрәштерүләр, зиһен һәм тапкырлык ярышлары ае-

руча калку күренгән. Элек заманнарда шулай итеп халык үзенең күңелен юаткан, сагынып сөйләрлек истәлекләр калдырган. Әминә апа Ситдыйкова Елховойга утырмага төшә. Аның сеңлесе Минбәян шунда кияүдә икән. Әминәнең Тукайныкы төсле күзенә ак төшкән һәм ярыйсы ук сизелеп тора икән инде. Табында утырганда Елховойлардан берәү төрттерә:

— Хәзер күп халык читкә китә, тәрәзәләрен кадаклыйлар да китәләр...

Әминә апа чәйне эчеп чынаягын каплый да, болай ди:

— Тәрәзәләрен алар Елховой хәерчеләрен күрмәс өчен кадаклый торганнардыр...

Әлеге читләтеп сөйләү, ягъни Эзоп теле, безнең авыллар тарафыннан чынлап та яратып кулланыла. Аның гамәлгә кереп китү сәбәбе әнә шул тормыш заррурияте, нужа аркасындадыр. Җиде ят халык арасында эшләп йә яшәп үз денеңне, асылыңны җуймау өчен дә кирәк булгандыр ул образлы тел... Чирмешәндә яшәүче Чумачка авылы кешесе Насыйх абзый Мөхәммәтҗанов (1938 елгы) бу турыда кызыклы гына мәгълүмат биргән иде. Аның сөйләвенчә: «Карешмәләр Бәркәтә аша узып урманга йөргән, аның кырларында, шулай ук Чумачкадан арендаланган җирләрдә иген иккәннәр. Бәркәтә халкы Шушма елгасын узганда аларга бәйләнеп йөдәткән, атларыгызның тоягы безнең күперебезне туздыра!» — дигәннәр. Шул заманда Кара Чишмәгә мәдрәсә бетереп бик булган, акыллы бер мулла килгән. Һәм нәкъ менә шул дин әһеле безнең бабайларны үткенлеккә, атап әйткәндә, Эзоп теленә өйрәткән, имеш. Шул хәзрәтнең сабагы белән «коралланып», Кара Чишмәләр бервакыт күршеләрен дә уздыра башлаган, ди. Инде Совет заманындагы бер вакыйганы язып үтим. Белгәнебезчә, бездә атларны яхшы тәрбиядә тотканнар, бик елгыр, көр атларыбыз күп булган. Беренче май (Чирмешән) районы судьясы үзенең хәлсез, арык атын алып килеп Кара Чишмәдән шәп кенә айгырга алыштырып китә. Калдырып киткән мескен атны көзгә хәтле ашаталар, симертәләр. Судьяның бик көр атта җилдерүен күргән прокурор да көнләшеп үзенең йолкыш атын Карешмәгә китерә. Һәркайсының атына безнең авыл халкы озак уйлап тормас борын үз исемен кушамат итеп тага: бер ат «Судья», берсе «Прокурор» булып китә. Көз җитә. Октябрь бәйрәменә аш үткәрелә иде бит. Колхоз олы мал — елкы йә сыер чалдыра. Менә беркөнне арканнар, зур пычаклар тоткан ирләр идарәгә килеп керә. Кайсын суябыз: «Судьяны»мы, «Прокурор»нымы? Идарә эчендәгеләр әлләни курыкмасалар да бер-берсенә карашып куйганнар, ди. Шул ук дәверләрдә район үзәгеннән Кара Чишмәгә «уполноймоч» бер ир кеше килеп төшә. Бик яман бәйләнә икән үзе, теге әйбер ник тегеләй дә, бу әйбер ник болай? Җыелышта да усал үгез сыман каш астыннан сөзеп кенә карап утыра икән. Авылдашлардан берәү моның ялгыз чагын чамалап кабинетка кергән. Вәкилнең «нәрсә кирәк?» дигән кырыс соравына каршы абзый:

— Мир үгезе ычкынган, бөтен дөньяның астын-өскә китереп, кем очрый шуны сөзеп йөри икән! —дигән.

— Не позволю! Бәйләп куярга кирәк аны! Немедленно! — дип кычкырган вәкил.

— Кичкә таба бәйләрбез дә әле без аны!

Хәйләкәр абзый шулай дигән дә ишек артына чыгып «мир үгезе»ннән көлгән, ди.

Безнекеләр Тумба авылына урман кисәргә баралар, Чумачкадан таза гына гәүдәле, сыңар күзле Әсхәт абзый да була. Аны әүвәл күргән Карешмә халкы үзара сөйләшә икән: «Карале, нинди зур ызба, тәрәзен ватканнар...» Совет заманнарында шифер формасында кабыргалап эшләнгән йомшак түбә ябу материалы кулланыла иде. Аны, битумнан төрле өстәмәләр кушып, Шөгердә җитештергәннәр, бимит дип



Авылдашыбыз – легендар баянчы, мәшһүр «Саз» ансамбленең җитәкчесе Рифкать Гомәров

йөрткәннәр. Чумачка авылында Туймәт егете белән Кара Чишмәнең бер ир кеше шабашкада эшлиләр. Инде эш бетеп килә — түбә ябалар икән. Болар янына ниндидер йомыш белән ике кеше килеп чыккан. Берсенең бите сәламәт, икенчесенеке шадра икән. Кара Чишмә кешесе болар янында ук Туймәт егетенә:

— Карале, янәшә ике ызба тора, берсенең башы тюль белән япкан, икенчесенеке бимит, — дип әйткән, ди.

Бу рәвешле яшерен сөйләшү борынгыдан килә. «Икенче план»га күчеп бу рәвешле аралашуны авылда «арт капкадан» дип атыйлар. Фольклорчы Рәшит Ягъфәров фикеренчә, балалар авыз иҗатындагы санамыш кебек кайбер жанрларда тарихи мәгълүмат сакланып калган. Алар өлкәннәрнең дошманнардан саклану максатында җиткерелгән «шифрлы» хәбәре булган. Әйтик, монысы:

Алатыр, мул атыр,
Тау ягыннан таң атыр,
Алабуга бигәнәк.
Чистай чигәнәк.
Татарский мирский
Ялтан, ялпак
Тити куян,
Үз юлыңнан бара тор…

Биредә Тау ягыннан гаскәр булып барабыз, Алабуга ягында бәкләр-морзалар яши, Чистайдагы гаскәр чигенергә ихтимал, татар дөньясына иминлек теләсәгез, үзегезчә эшли торыгыз дигән «депеша»ны күрәбез. Казан алынганнан соң урманнарда посып җан саклаган бабайларыбыз үзара шул рәвешле элемтә тотканнар булса кирәк. Соңрак әлеге поэтик үрнәкләрнең зарурияте калмагач, алар бала-чаганың уен элементына әверелгән. Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри бу хакта «Кырык бакча» әсәрендә язып калдырган: *«Дөньяда бар үткен кешеләр, һәрни сөйләсә шартлы билге вә читләтеп әйтү белән сөйләшерләр. Берәү ишетсә, ни сөйләшкәннәрен бер дә аңламас. Төртмәле вә яшерен сүз, вә мәзәк сөйләмәк — ушбу кабилдәндер».*

Ахыры бар ■

Хәтер-хатирә

Хөрмәтле «Безнең мирас» редакциясе!

Журналның 9 нчы санында (2015 ел) мин укучыларыбызның санын арттыру өчен һәркем тагын бер кешегә генә булса да — туган мәктәбенә, әти-әнисенә, әби-бабасына, күршесенә яздырып, декабрь аенда квитанциясен Яңа елга бүләк итеп җибәрсә, дип тәкъдим керткән идем «Безнең мирас» — затлы бүләк» дигән язмамда.

Үземнән башларга булдым. «Кемгә бүләк итәргә, бу кем өчен кызыклы, файдалы, кирәкле журнал, көтелмәгән бүләк булыр?» — дип озак уйладым. Туган көнемдә минем фотоальбомнар карап, әти-әнине, балачакны искә алып, туганнарны, дусларны, сабакташларны барлап утыра торган гадәтем бар. Көтмәгәндә генә арткы ягында: «Истәлек өчен. Мин Буа санаториенда. Вахитов мәктәбенең 4 нче һәм 2 нче класс укучылары.Төшелде 25/V 66 ел. Укытучы Бикмуллина Тәгъзимә», — дигән язуымны һәм ул чактагы имзамны күрдем. И-и-и, ул Тәгъзимә апаның дәресне оста итеп аңлатулары, сабырлыклары, күлмәкләренең килешлелеге... Әти-әнидән еракта, аларның җылысын сагынып яшәвебезне аңлаптыр инде, класс белән берәр җиргә барасы булсак, тезелгәндә гел безне (Актаныш районы Адай авылыннан Вәсилә Латыйпова исемле кыз да бар иде, нишләптер, фотода ул юк) үз янына алып, кулын иңбашларыбызга куеп торыр иде.

Әтинең мине санаторийга алып килгәч беренче соравы: «Татар мәктәбе бармы?» — булды. Мин авылда гел бишлегә генә укыгач, артта калырмын, дип уйладымы, әллә татар мәктәбендә укырга тиеш, дип аңлатуы булды микән.

Укытучыбыз Тәгъзимә апа Бикмуллина, икенче рәттә сулдан икенче – мин.

Мәктәп 1922 елның 24 июнендә ачыла. Бу рәсемдә – 60-70 еллардагы мәктәп бинасының күренеше

Почтада «Безнең мирас»ны Буа шәһәре өчен яздырырга дигәч, индекс сорадылар. Интернет аша телефонны табып, мәктәпкә шалтыраткач та соравыма матур татар сөйләме белән җавап бирделәр. Сөенеп куйдым, димәк, татар мәктәбе яши. Бервакыт буалылар белән очрашкач Тәгъзимә апа турында сорашкан идем. «Ул юк бугай инде», — дип, икеләнебрәк әйткәннәр иде. Бу хәбәр хак булмаса, мәрхәмәтле укытучыбыз, димәк, әле озак яшәячәк.

Без Буа балалар санаториенда 1966 елда 1 марттан 30 майга хәтле булдык. 60ка якын малай һәм кыз арасында татар авылларыннан, татарча укып-сөйләшүче без берничә бала гына идек: Вәсилә Латыйпова, Сания Ханова (Саба районы, Алан авылы, 7 кл.), Әнәс Гарипов (Балык бистәсе районы, 5 кл.), Илгиз Вафин (Әлки районы, 7 кл.). Азнакайның үзеннән бик әйбәт кыз Мөсәппиха Мәхмүтова (5 кл.) Луначарский исемендәге рус мәктәбендә укыса да гел безнең белән булды. Чуваш кызы Аня Корнилова татарча чиста сөйләшә, бик җайлы кыз иде.

Һава Шакировна һәм Гөлшат Хәкимовналарга — тәрбиячеләребезгә татар балаларын бер бүлмәгәрәк җыеп, безнең белән гел татарча сөйләшеп, ятар алдыннан йомшак кына тавышлары белән тыныч йокы теләп, юрганнарыбызны рәтләп чыгып китүләре өчен инде 50 ел буе күңелдә рәхмәт хисләре саклана.

Бүген искә алган өлкәннәрнең исән-имин яшәп йөрүчеләренә хөрмәт-сәлам, мәрхүмнәренә дога булып ирешсә иде хатым. 1982 елда Буада командировкада чакта санаторийны бик барып күрәсем килгән иде, инде ул күптән ябылды, диделәр. Кызганыч.

Ә «Безнең мирас» журналы Мулланур Вахитов исемендәге татар мәктәбенә узган гасырның 60 нчы елларыннан бер рәхмәт сүзе булып ирешсә иде. Вахитовлылар алга таба да журналның даими укучылары булып калыр, дип ышанам.

Наилә Вилданова,
Чаллы шәһәре ■

Таҗи Гыйззәт исемендәге тәүге премия

22 октябрьдә Әгерҗедә Таҗи Гыйззәт (1895-1955) исемендәге премиянең беренче лауреатларын бүләкләү тантанасы булды. Классик драматургыбызның тууына 120 ел тулу уңаеннан оештырылган әлеге күркәм чарада Казаннан да кунаклар катнашты. Алар арасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, драматург Д.Салихов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон, язучы-журналист Г.Гомәр, драматурглар Ю.Сафиуллин, Р.Сәгъди, Х.Ибраһим, А.Гаделшин, шагыйрь Р.Җамал, театр белгечләре Г.Арсланов, А.Габәши, музыкант Р.Халитов, Т.Гыйззәтнең оныгы Гүзәл ханым, әдипнең авылдашы Р.Гыйззәтуллин һ.б. бар иде. Тәүге премия Әгерҗе төбәгендә яшәп иҗат итүче өлкән каләмдәшләребез Габдулла Галиев белән Чыңгыз Мусинга бирелде.

Фоторепортаж белән www.beznenmiras.ru сайтыннан таныша аласыз.

Муллалар илендә

14 октябрь көнне редакциябезнең иҗат төркеме 775 еллык бай тарихы булган Мулла Иле авылында (Яшел Үзән) иҗади сәфәрдә булды. Әлеге сәфәребез Татарстанның атказанган укытучысы, Мәгариф отличнигы, төбәкне өйрәнүче галим, авыл имамы, шагыйрь Равил Сәйфетдиновның туган көненә (бу көнне аңа 77 яшь тулды) һәм мәктәптә оештырылган шигырь бәйрәменә туры килде.
Фото һәм видеорепортаж www.beznenmiras.ru сайтында тулырак тәкъдим ителә.

Л.Гобәйдуллин фотолары

Мулла Иле авылы булсын да,
Коммунистлар динле булмасын...
Мулла Иленең һәрбер коммунисты
Алмашырлык авыл мулласын.

Һади Такташ
(«Чаян», 1930)

АВЫЛ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

Мулла Иле авылы Яшел Үзән районында, Яшел Үзән шәһәреннән 33 км көньяктарак, Зөя елгасыннан 3 км читтә урнашкан. 2010 елда 780 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — крычылык, мөгезле эре терлек асрау. Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә бар. Мәчет — архитектура истәлеге (XIX йөзнең II яртысы). Казан ханлыгы чорында нигез салына. XVIII йөздә — XIX йөзнең I яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек,

Мулла Иләндәге тарихи мәчет. XIX йөзнең II яртысы

Зираттагы төрбә

Авыл имамы Р.Сәйфетдинов

Баһаветдин Вәисов

Гайнанетдин Вәисов

терлекчелек белән шөгыльләнә. XX йөз башында Мулла Иләндә 3 мәчет, 3 мәктәп, рус-татар земство мәктәбе, вак кредит учреждениесе, 2 җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2990 дисәтинә тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 елдан ТАССРның Зөя кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 елның 1 августыннан — Норлат, 1963 елның 1 февраленнән Яшел Үзән районында.

Халык саны: 1782 елда — 302 ир-ат; 1859 елда — 1246, 1897 елда — 1895, 1908 елда — 2443, 1920 елда — 2440, 1926 елда — 2159, 1938 елда — 2610, 1949 елда — 1819, 1958 елда — 1608, 1970 елда — 1670, 1979 елда — 1343, 1989 елда — 1129, 2002 елда 993 кеше. Мулла Иләндә җәмәгать-дин эшлеклеләре Баһаветдин Хәмзә улы Вәисов (чын фамилиясе — Хәмзин, 1810-1893), Газизҗан Баһаветдин улы Вәисов (1887-1937), Гайнанетдин Баһаветдин улы Вәисов (1878-1918) туган. Галим һәм шагыйрь Гомәр Саттаров — шушы авылдан.

«Минем шәҗәрәдә – Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсының йомгаклары

Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан «Безнең мирас» журналының иҗат төркеме тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев инициативасы белән «Минем шәҗәрәдә – Бөек Ватан сугышы еллары» дип исемләнгән конкурс оештырган иде. Иң яхшы эш тәкъдим иткән авторларны дипломнар һәм истәлекле бүләкләр көтә. Аларга лаек булучылар:

Таразова Әлфия Хәниф кызы, Пермь крае Барда районы Күчтәнти мәктәбе директоры (Хәниф Нәҗмехәмәт улы Тякин турындагы мәкаләсе өчен);

Минһаҗева Лилия Марат кызы, Мамадыш шәһәренең 1 нче мәктәбе укучысы («Яшел сандык серләре»);

Шәйхетдинов Азамат Айзат улы, Актаныш районы Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы («Дәү әбиемнең батырлыгы — оныклары өчен өлге»);

Закирова Гөлия Нургаяз кызы, Чистай шәһәренең 3 нче гомуми белем бирү гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы (Гайсин Галимов турындагы мәкаләсе өчен);

Закирова Асилә Илгиз кызы, Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназия укучысы («Уфалла арбасы»);

Мөхәммәтҗанова Айгөл Әнәс кызы, Алексеевск районы Урта Тигәнәле урта мәктәбенең укучысы (Чапчаков Тәлгат Вагиз улы турындагы мәкалә);

Садирова Илзирә Мөхәмәтгали кызы, Казан шәһәренең №153 балалар бакчасы тәрбиячесе («Бабам Гаяз»).

Калган барлык катнашучыларга да сертификатлар тапшырабыз. Диплом, китап һәм сертификатларны редакциягә килеп алырга мөмкин.

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

● Һәрбер гамәл (кирәк тән гамәле вә кирәк тел гамәле булсын, кирәк аз вә кирәк күп булсын) нияткә карап йөрүне белдерүдер. Ният бозык булса, гамәл дә бозык, ният төзек булса, гамәл дә төзек вә могтәбәр буладыр.

● Ниятнең урыны — күңелдер.

● Ният — күңел гамәле.

● Яхшы бер ният белән хәрам эшне кылырга ярамаган кебек, ният бозыклыкны сылтау итеп яхшы гамәлләрне калдырырга да мөмкин түгел.

● Издиваж[1] вакытында һәрбер ир яхшы вә итагатьле, үзенә ошый торган бер хатын алуны, һәрбер хатын вә кыз үзе барачак ир вә егетнең мәрхәмәтле вә мөлаем, үзләрен яхшы тәрбия кылырлык, җил-яңгыр тидермәслек булуын телидер.

● Иң әүвәлге суыклык вә илтифатсызлык сәбәпле ир берлә хатын аерылышып кую муафыйк түгел.

● Ауропада гаилә әхвале бозык булып, гафиф[2] галимнәр моны төзәтер өчен бөтен көчләре берлә тырышалар, диләр. Ләкин алар берлә безнең арабызда бу хосуста фәрыкъ[3] зур. Бездә гаилә әхвале бик яхшы эшләнгән, бу тугрыда булган канун, нигезләр Коръән вә Сөннәт тарафыннан ачык бәян ителгән.

● Тәкәбберлек, кеше хәлен тикшерү, яла ягу вә гайбәт сөйләү адәм углының төбе бозыклыктан киләдер.

● Инде бер кеше сездә булган (яки булмаган) бер гаеп берлә сезне гаепләп йөрсә, йөзегезгә каршы сөйләсә, сез анда булган гаепләр берлә аны сөйләмәгез, гамәленә күрә җәзасы, дип үч алу касдында[4] булмагыз, үзегезне пычратмагыз!

● Кеше сүгү вә халык берлә булышу — әхлаксызлык вә мәгънәсез адәмнәр эшедер. Мондый эш берлә, әлбәттә, шөгыльләнмә, вакыт заигъ итмә[5], үз кыйммәтеңне төшермә!

● Бер кеше хакында нинди генә булса да бертөрле мөгамәләдә булырга теләүче кеше, шул эшне иң элек үзенә салып карарга, әгәр дә үзе яратачак булса, кеше хакында да кылырга, вә әгәр дә үзе яратмаслык булса, теге кеше хакында да яраклы күрмәскә тиешле.

● Хәрамнан саклану, фарызларны өстән төшерү кадәр саваплы гамәл юктыр.

● «Юк, юк», — дип зарланып, сыкранып йөрүчеләр берәр әгъзаларына вә яки гаилә эчендәге кешеләргә каза килсә, шулвакытта үзләренең нигъмәт эчендә булып та, кадерен белмәгәннәрен икърар итәләр вә үзләренең шикаять кылып йөргәннәренә үкенәләр.

● Көлүдә сәламәтлек өчен файда барлык дәгъва ителсә дә, күп булып китсә килешми вә гакылсызлык галәмәте була башлыйдыр. ■

---

[1] Издиваж — өйләнү
[2] Гафиф - абруйлы
[3] Фәрыкъ - аерма
[4] Касды - нияте
[5] Заигъ итмә — әрәм итмә

«Җиз кыңгырау» спектаклендә. 1960 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Мәсгут Имашев

***

«Г.Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында минем, артист буларак, беренче ролем. Аяз Гыйләҗевнең «Җиз кыңгырау» спектакленнән бер күренеш: кыз — Татарстанның халык артисты Люция Фарсина, Мәүлә роленда — мин.

Аязның да бу тәүге сәхнә әсәре иде. Ни кызганыч, татар драматургиясендә яңа, кыю сүз буларак янгыраган бу спектакльне куярга рөхсәт иттеләр-итүен, вәләкин «югарыда» хупламадылар. Сәхнәдән тиз төште ул… »

***

«Г.Камал театрының Кәрим Тинчурин пьесасы буенча куелган «Зәңгәр шәл» спектакленнән баш геройлар Мәйсәрә белән Булат очрашуы күренеше. Мәйсәрә — Татарстанның халык артисты Рауза Хәйретдинова, Булат — мин, Мәсгут Имашев. Минем шөкер, Булатлы рольләрем миңа гел уңыш китерде!»

***

«Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаганда (1964) диплом



«Зәңгәр шәл» спектаклендә. 1962 ел

«Качкын» операсында. 1964

эшем — Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсында баш каһарман Булат роле булды.

Бу опера Муса Җәлил исемендәге театр сәхнәсендә консерваториянең чыгарылыш курсы студентлары көче белән театрның оркестры һәм хоры катнашында зур уңыш белән куелды. Шыгрым тулы зал бик күп тапкырлар алкышларга күмелде…

Ректор, композитор Нәҗип Җиһанов диплом алучы яшь җырчыларның чыгышыннан бик канәгать калды һәм театр артистлары тарафыннан куелачак шул ук операда җырларга янә мине чакырды. Ул көнне дә зал шыгрым тулы булып, спектакль зур уңыш казанды.

Нәҗип ага, мине Казанда калдырырга теләп, «обком»га (КПССның Татарстан өлкә комитеты) кадәр барып җитте. Әмма дә «обком»ның сүзе катгый: юллама белән Әлмәткә китеп бардым. Ике елга дип җибәргәннәр иде, алты ел эшләп кайттым. Хезмәтемнең, иҗатымның нәтиҗәсен күрәсем килде!»

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Ни ди, ишет, күп яу күргән батыр ир,
Дошманнардан өстен булган асыл ир:

«Гафил булып торма дошман янында,
Үзен алдат — тырыш тозак салырга.

Зәгыйфь димә, көчле, зур, диген дошман,
Таяклы дошманга тот тимер капкан».

Күтәр дус-иш йөген, сындырма күңлен,
Онытма мәгънәсен ошбу сүземнең:

Дустың дошман булса, хәтәр дошман ул,
Хәвеф астындадыр җаның һәм малың.

Белә андый дошман эчең-тышыңны,
Шуңа ансат эшләр явыз эшен ул.

Теләсә, малыңа кулын тидерер,
Теләсә, муйныңа элмәк кидерер.

Бел дусны үзеңне белгән кадәрле,
Югыйсә күп дуслык булыр хәтәрле.

«Дустым», дию ансат, дус булу кыен,
Дошманлашу ансат, килешү кыен.

Дошманың «дус» булса, җаныңны сакла:
Котылулар кыен булыр ул чакта.

Ике төрле затка каршы киртә кор;
Якынлашсаң афәт чыгар – көт тә тор.

Бере әләкләшә һәм яла яга,
Икенчесе икейөзле ялагай.

Эчкечене дә син дуска санама:
Вафасыз ул һәм тоз салыр ярaңа.

Риялы дуска да син бирмә күңел,
Тизүк дошман була ул, аннан түңел.

Ризалатыйм, дисәң дусны тиз генә,
Сәмән бирмә, эш ит яхшы сүз белән.

Булыйм, дисәң тыныч, имин тормышта,
Явыз булма, тик бул кайчан кырыс та.

«Үземә кол итим, – дисәң, – ятларны»,
Алтын тоттыр һәм тот ятның сакалын.

Ә читләтим, дисәң кайбер якынны,
Эре сөйләш, кыйбат куй үз хакыңны.

Озын гомер яшим, дисәң дөньяда,
Юмарт бул, сак бул һәм көймә юкка да.

Сөйкемле күрсәтим, дисәң үзеңне,
Чагылдырсын сүзең ихлас күңелле.

Кадер-хөрмәт күрим, дисәң һәрдаим,
Бүтәнгә дә хөрмәт күрсәт көн саен.

Булыйм, дисәң тыныч, имин тормышта,
Явыз булма, тик бул кайчан кырыс та.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

Кешенең кемлеген белмәкче булсаң, Сүзенә колак сал, эшенә күз сал.

Ия булыйм дисәң анык байлыкка,
Җыярсың мал, җилкенмәсәң артыкка.

Мактасыннар дисәң сине кешеләр,
Намуслы бул сүздә һәм дә эшеңдә.

Менә шундый була инде чын кеше,
Кешелеклелек чын инсан билгесе.

Кешенең кемлеген белмәкче булсаң,
Сүзенә колак сал, эшенә күз сал.

Ни яхшы әйткән бер бәетче – чәчән
(Сүзенә мәгънәне төгәл үлчәгән):

«Кеше аслын белмәк булсаң, шул чара:
Кыланышын, күңлен һәм сүзен кара.

Кыланышы — юньле, теле — ягымлы,
Асылзат икәне шуннан танулы.

Наданга сүз катма, и, ару затлы,
Йөз суыңны түгеп, сине пычратыр».

Ни дигән тормышны белгән бер кеше –
Җаһиллектән үзен йолган ир кеше.

«Тупаска катылма, юньле-ипле бул,
Талаш уты чыга утыннан[1], угыл.

Җаһил белән дә һич якын булма син,
Ачудан танышлык хакын бозмасын.

Күңел серләреңне ачма һәркемгә,
Ачтың исә сүзең – үзеңә имгәк

Булсын дисәң, егет, дуслык дәвамчан,
Эчкерсез бер дус бул, баш тарт тәмгыдан.

Әгәр үтсен, дисәң һәрвакыт сүзең,
Һәр сорауга туры сөйлә дөресен.

Әгәр йөзең якты балкысын, дисәң,
Туры юлдан качма, булырсың исән.

Үчләшмә дәүләткә – бел ярашуны, Юкса дәүләт агу итәр ашыңны.

Үзең гомерле һәм сүзең үтемле
Булсын, дисәң, кыскарт кул һәм телеңне.

«Абруемны саклыйм», дисәң, һичкайчан
Сүзеңдә ялгыш та сөйләмә яман.

Кайчан кайсы көчле дәүләт йөз бирсә,
Шуңа яраш, дустым, һич шикләнмичә.

Үчләшмә дәүләткә – бел ярашуны,
Юкса, дәүләт агу итәр ашыңны.

Нигезсез сүз әйтмә, сөйләмә арттан.
Эләкләшмә һәм дә яман сүз катма,

Яман сүз – ачы җил, ул бөрештерә,
Шуннан сине ятлар юньсез дип күрә.

Үзеңнән олыга телең озайтма,
Җавап биргән чакта эре сүз атма.

Олыны агала, абруең сакла.
Үзең дә җитәрсең шундый бер чакка.

[1] КБ телендә «утын» һәрвакыт «тупас, надан кеше» мәгънәсендә килә.

Үзеңнән олыга телең озайтма.
Җавап биргән чакта эре сүз катма.

Үз тиңнәрең белән булсын йөрешең,
Аралашуың һәм алыш-бирешең.

Кадерләгәннәрне син дә кадерлә.
Кадерсезләгәнгә якын да йөрмә.

Ул ничек кыланса, син дә шулай бул.
Сөчек сүз сөйләсә, син дә елмай, көл.

Изгелекле бул һәр юньле кешегә.
Усал булсаң, бул тик ишәк ишегә.

Ни шәп әйткән әдәп белгән бер кеше –
Илтөзәр кануннар биргән ир кеше[2]...

Шулай була, күр, чын ират[3] сөхбәте,
Дөрес сөйләшүнең шулдыр хикмәте.

Әйтеп бирдем инде, ишеттең үзең,
Күңелеңә беркет, озайтма сүзне.

Сиңа «сез» дисәләр, син дә «сез» диген,
Кызганма яхшы сүз: яхшы сүз тиген.

«Син», дигәнгә син дә «әй, син», дия бел,
Җавабыңда яңгы[4] биргән кыя бул».

2. КАРА ХАЛЫК БЕЛГӘН СӨХБӘТ ТУРЫНДА

Җаваплап Уйгырмыш әйтте: – Бу сүзең
Аңлашылды миңа, и, күңле төзем.

Моннан башка тагы бар сорауларым,
И, күреклем, яктырт миңа шуларны.

Бүген миңа тиеш шәһәр-авылга
Барып, халык белән аралашырга.

Алар белән ничек булырга кирәк?
Бу хакта да миңа бераз бир сөйләп.

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Ул сүзем
Кирәк булыр сиңа, и, холкы төзем.

Бик кирәкле чакта искә төшерден,
Менә шуның хакта мин әйтеп бирим.

Кара халыкның бар гадәте-заңы
Белем кимәленә яраша аның.

Тупас була кара халык гаммәсе:
Юсык-юрыкларны белми һәммәсе,

Ләкин аларсыз бер эш тә бармас, гәрчә,
Ипле сөйләш, ләкин булма аларча,

Кара халык холкы кап-кара була.
Аның корымына буялып куйма.

Изгелекле бул һәр юньле кешегә.
Усал булсаң, бул тик ишәк ишегә.

Кара гаммә башсыз, кылыгы кыңгыр,
Эше-кылмышлары үзенчә булыр.

Ашау хәстәредер бар белгәннәре,
Уйлап та карамас бүтән хәлләрне.

Әнә, гаммә халкын күзәтеп йөргән
Берәү, ишет, килгән нинди фикергә:

«Кара халыкның бар кайгысы – тамак,
Фикере юнәлгән гел шуңа табан».

Күп халаек тамак өчен үлделәр,
«Тамак тәмугка да кертә ул», — диләр.

Кара халык туйса, озая теле,
Бастырып тотмасаң, иркенлек тели.

Әхвәлен белеп тор аларның, кардәш,
Аларга биреп тор эчемлек һәм аш.

Телең йомшак булсын, бир сораганын,
Туры монда мәкаль: «бирүче – алыр».

[2] Ул «ир кешенең» нәрсәне шәп әйткәне төшеп калган.
[3] Ират — «чын ир-егет».
[4] Яңгы – «эхо, кайтаваз, яңгыравык» (шуннан — яңгырау).

Телеңне уйнатма, сүзеңне уйла:
Күп сүз сөземтәсе – җиме аз була.

Ни ди, ишет, үзен тота белгән ир.
Телен тыя белеп, күп белдергән ир:

«Күңелгә килгән һәр сүзне чыгарма,
«Ничек әйтергә»сен кирәк уйларга».

Бер галим бар иде. Аз сөйләде бик.
Картайгач, үкенде «күп сөйләдем», дип...

3. ГАЛӘВИЛӘР[5] БЕЛӘН АРАЛАШУ ХАКЫНДА

Яугирләрдән һәм бәк халкыннан тыш та
Лаеклы затлар бар, кардәш, катышсаң.

Пәйгамбәр токымы шуннан бер төре,
Аларны хөрмәт ит – булыр әҗере.

Аларны үзеңнән артык күреп тор,
Белешеп хәлләрен, ярдәм биреп тор.

Болар әһле-бәйттер, нәби затыннан,
Аларны сәүчебез[6] өчен сөй, туган.

Тыгылма, тыгылсаң алар эшенә,
Ярамас эшләре беленсә генә.

4. БЕЛКӘ-ГАЛИМНӘР БЕЛӘН АРАЛАШУ ТУРЫНДА

Тагын бер хөрмәтле төркем – галимнәр,
Алар юл яктырга халкына, илгә.

Аларны хөрмәт ит, ярат, кадерлә.
Өлеш ал аларның белемнәреннән.

Алар өйрәнеп һәм белеп аерган –
Кайсы юллар илтә уңга һәм сулга.

**Булмаса дөньяда киң белемлеләр,
Тырышсаң да уңмас иде игеннәр.**

**Галимнәр янында тел татлы булсын,
Ашап-эчкәндә дә йөз якты булсын.**

Алыр булсаң, әгәр, алардан белем,
Юмарт булсын кулың һәм татлы – телең.

Болар хакыйкать һәм диннең терәге,
Шәригать тамырын алар беләдер.

Булмаса дөньяда киң белемлеләр,
Тырышсаң да уңмас иде игеннәр.

Белеклеләр гыйльме – халыкка юла[7],
Юлалылар төнлә адашмас юлдан.

Галимнәр янында тел татлы булсын,
Ашап-эчкәндә дә йөз якты булсын.

Телеңне тый, саклан, бәхәскә кермә,
Юкса, дару итеп агу бирерләр.

Телләшмә һәм икмәк-тоздан калдырма,
Аларга хөрмәтләр күрсәт, кадерлә.

Гыйлемләрен от һәм тәнкыйтьли күрмә,
Фигыльләрен дә бик артык тикшермә.

Алардан ни кирәк сиңа? Тик гыйлем,
Өйрән хакыйкатькә ирешү юлын.

Болар көтү башы – иркәчләр[8] алар.
Куй көтүен башлап туры баралар,

Аларга кушылсаң уең яктырыр,
Ике дөньяда да юлың ак булыр.

Әйтелгәннән башка да бар төркемнәр,
Гыйлем җәһәтеннән төрле-төрлеләр.

Дәвамы бар ■

[5] Галәвиләр – хәзрәти Гали токымыннан булган интеллигенция.
[6] Сәүче – «пәйгамбәр, нәби».
[7] Юла, юлай – «факел, чырак»; нишләптер, бу борынгы кирәкле сүз татар әдәби теленә кереп нысыгмаган (Себер сөйләшләрендә кулланыла).
[8] Иркәч – сарык көтүен ияртеп йөри торган кәҗә тәкәсе.

КЫЙССАИ ТАҺИР ИЛӘ ЗӨҺРӘ

Көннәрдән беркөнне Зөһрә шул сарай чарлагында Таһирны исенә төшереп, күзләреннән яшь акмаган минутларында килгән-киткән, үткән-сүткән кешеләрне күзәтеп утырганда каршыдан зур бер кәрван килгәнен күрде. «Бу кәрван, бәлки, Таһир яшәгән якларга барадыр», – дип уйлады ул күңеленнән. Кәрван сарай алдына җитеп чарлагы алдыннан үтә башлады. Зөһрә сазын кулына алып, тәрәз канатларын ачып, кәрванга карап, бу шигырьне әйтте:

Дәртемә, дәрман итәр әллә шул кәрван микән?
Мин Таһирны алдырдым, бармы шул якка киткән?

Бу кәрван эчендә бер үсмер бар иде, шигырьгә гаять оста иде. Ул Зөһрә дәртен шунда ук аңлап алды, кулына сазын тотып, бу шигырь белән җавап кайтарды:

Сүземдә юктыр ялган, бездә табарсың дәрман,
Кәрванда күп юлаучы Мәрдин иленә барган.

Зөһрә кәрванчылардан Таһирга үзенең сәламен һәм исәнлек хәбәрен тапшыруларын үтенде. Ул кәрван, илдән-илгә күчә-күчә, Мәрдин шәһәренә барып җитте. Таһир яткан зиндан алдында бер гүзәл болын бар иде. Кәрван шул болынга килеп кунды. Чатырлар тектеләр. Кайсы утын, кайсысы су китереп, учаклар көйрәтеп җибәрде. Кемнәрдер аш пешерә башлады, икенче берәүләре думбра чиртеп ял

* Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында (№9, 2015).

итә иде. Хикмәти Хода, әлеге үсмернең чатыры Таһир яткан зиндан тәрәзәсе каршысына тугры килде. Төрмә тәрәзәсеннән моңлы җыр агыла иде:

Кәрваннар килә-китә, көн түгел, гомер үтә.
Мин Зөһрәмнән аерылдым, шул күңелем кимсетә.

Җыр Зөһрә әманәтен кәрванчы исенә төшерде. Ул, тәрәзгә килеп, тоткынга мөрәҗәгать белән бер шигырь әйтте:

Моңлы сазын сызучы, бикле тәрәз, ишегегез,
Зинһар, миңа әйтегез: ничек сезнең исемегез?
Таһир болай җавап кайтарды:
Минем исемем аһ та зар, бер ярыма интизар,
Нинди яхшы кешесең: сүзеңдә яр исе бар?

Егет шунда ук моның Таһир икәнен белеп, аңа Зөһрәнең әманәтен тапшырды:

Сөенчеләр бирегез, Таһир, аһ-зар итмәгез,
Юлыма очрап чарлактан сәлам әйтте Зөһрәгез, –

дип, очрашу, сөйләшү, Зөһрә үтенече турында тәфсилләп Таһирга сөйләп бирде. Таһир бу хәбәргә шулкадәр шатланды, Зөһрәнең үзен күреп сөйләшкәндәй булды.

Икенче көнне торып тәрәзгә күз салса, кәрваннан җилләр искән. Күчеп киткәннәр. Таһир һуштан язып егылырдай булды. Гүя аны Зөһрәсеннән мәңгегә аердылар. Җырлар, шигырьләр әйтеп, моңлы көйләр уйнап, күпме генә әүвәлгедәй юаныч табарга тырышып караса да, булмады, күңеле көннән-көнгә көйсезләнә барды. Үзенә урын табалмагандай булып калды. Байтак көннәр шул рәвештә интеккәннән соң чарасы калмады, беркөнне, тәһарәт алып, Хак Тәгаләгә зарыйлык кылып, бу мөнәҗәтне укыды:

Җиде ел бит торганга, таш зинданда калганга,
Инде сиңа ялварам, коткар диеп, Ходая!
Еглап сыгынган колга, тилмереп сузган кулга,
Чиксез рәхмәтең зурга өметем зур, Ходаем!..

Хак Тәбарәкә вә Тәгалә Таһирның интегүле теләкләрен кабул кылды. Ястү вакытында зиндан ишеге ачылып, бер сөйкемле, көләч карт килеп керде һәм сәлам бирде. Таһир, аягына торып, олы хөрмәт билгеләре күрсәтеп сәламен алды, әмма картның кем икәнен белми иде, танымады. Бу – Хозыр галәйһиссәлам иде. Ул Таһирга: «Углым, еглама һәм гамь чикмә, Ходай Тәгалә догаңны кабул кыйлды, бу зинданнан котылып сөйгәнең белән күрешерсең», – диде. Зинданнан чыккач, Хозыр галәйһиссәлам янында бер кара ат пәйда булды. Хозыр галәйһиссәлам Таһирга: «Хәзер менә шул атка мен, мәгъшукаң янына илтәм», – диде. Таһир, бу сүзләрне ишетеп, бик шатланды, Аллага шөкерләр итте, Хозырга рәхмәтләр укып, кулларын үпте. Хозыр галәйһиссәлам Таһирның аяк-кулына, муенына салынган богауларга таягы белән ишарәләгән иде, тимерләре, вак кисәкләргә телгәләнеп җиргә коелдылар. Ирек куанычыннан исергән Таһир, канатлангандай очып, ат өстенә кунды. Әмма шунда һәр көнге йоклау вакыты булгангамы, йокыга киткәндәй булды, күзләре йомылды. Бу төш кенә булып, тагын зинданда уянып китмәгәем, дип куркып, ул шунда ук күзләрен ачарга ашыкты һәм үзен... Зөһрә сарае алдында күрде. Хозыр галәйһиссәлам Таһирны аттан төшерде. Үзе дә, ат та шунда ук гаип булды. Таһир, Аллага шөкер итәргә, шул торган җирендә сәҗдәгә китте, йөзләрен туфракка сөртеп, күп шөкерләр кылды. Шуннан соң, күтәрелеп, Зөһрә сараена карады. Әйе, аның алдында Зөһрәҗанның сарае иде. Тәрәзәләр ябылган, пәрдәләр төшерелгән, ут-яктылык әсәре юк. Сарай йокыга талган. [...]

Зөһрә солтан ул кичтә апасы белән сарайда кунып калган иде. Ул төш күрде. Төшендә, гүзәл бер җирдә Таһир белән утырыш ясап сазлар чиртеп, җыр, шигырьләр әйтешеп утыралар, имеш. Төшеннән хозурланып, дулкынландыр-

гыч куаныч хисеннән Зөһрә уянып китте. Таһир авазын, саз моңнарын ишетеп исергәндәй булып, башта гаҗәпләнде: «Нишләп бу төшем уянгач та дәвам итә әле?» – дип хозурланып ятты. Әмма шунда ук ыргылып торып тәрәзәгә ташланды. Тәрәз каршысында берәү, дөрестән дә, дәртле саз чиртә һәм Таһир авазы белән шигырь әйтә иде. Башта ул аны танымады: череп телгәләнгән кием-башы керле, чәч-мыек-сакаллары кеше сискәндерерлек булып үскән. Күзенә текәлеп карагач кына Таһир икәнен таныды. Хәтсез-чамасыз куанды. Шунда ук алга планнар корып алды. Мең алтын салынган бер янчык алып килеп Таһирга чөйде дә: «И минем гашыйк ярым, фәлән җирдәге фәлән өйдә сиңа сөт анасы булган әниеңнең кардәш апасы яши. Хәзер шунда бар да, чәч-сакалларыңны тәртипкә китер, мунча кереп юын. Менә шул акчага яңа, затлы киемнәр алдырып киен. Мин әти шымчылары синең кайтканыңны искәрмәделәр микәнен тикшерермен дә кайчан очрашачагыбызны сиңа үзем хәбәр итәрмен», – диде. Таһир, акчаны алып, апасының өен эзләп китте. Тапты. Ишек какты. Апасы уянып ишек янына килде:

— Кем ул? Нинди йомышың бар? – дип сорады. Таһир үзенең кем икәнен атагач, ишеген ачты. Аны танып күкрәгенә кысты. Еглашып, сәламләшеп, исәнлек-саулык сораштылар. Апасы хезмәтчеләрен аякка күтәрде. Шунда ук чәй әзерләделәр. Мунча өлгерттеләр. Сакал-чәчләрен тәртипкә китереп, асыл киемнәр әзерләп, Таһирны мунчага озаттылар. Мунчадан соң ашъяулык янында, чәй эчә-эчә, Таһир башыннан кичкән хәлләрне апасына сөйләп бирде.

Икенче көнне Зөһрә солтан бер хат язып апасы аша Таһирга күндерде. Апасы хатны илтеп Таһир кулына тапшырды. Анда кичкә, ил аягы тынгач сарайга килерсең, дип язылган иде. Таһир: «Әлбәттә, барырмын. Бүлсә, әҗәл генә юлымны бүлә, мине туктата ала. Зөһрәҗанга сәлам тапшырыгыз», – диде. Ул көн Таһирга бер ел кебек озын булып күренде, кичне җиткерәлми интекте. Ахшам вакыты үтеп күз бәйләнгәч, ил аягы инде тына башлагандыр, дип Таһир Зөһрә сараена китте. Зөһрә көндез ефәк арканнан бер баскыч әзерләп куйган икән. Таһир сарай алдында күренгәч тә, тәрәзә төбендә аны көтеп утырган Зөһрә тәрәзәне ачып аңа шул баскычны төшерде һәм шул ефәк баскыч белән Таһирны гүя сараена тартып алды. Алар кочаклашып-еглашып күрештеләр. Апалары шунда ук табын әзерләп, табынга төрле наз-нигъмәтләр, гөл чәчәгеннән әзерләнгән затлы эчемлекләр куйды. Аларны табын янына чакырып, алтын касәгә салып, Таһирга шифалы гөл суы тәкъдим итте. Аны авыз итеп, Таһир да, икенче бер алтын касәне алып, үз чиратында, гөл суы сөзеп, Зөһрәгә сонды. Тәкәллеф-тартынулар арадан күтәрелеп, бер-берсенә назлы сүзләр сөйләшеп, үбешеп, җырлашып алар таң вакытынача кәеф-сафа кылып утырдылар. Таң атканда ефәк аркан баскыч белән тәрәзәдән төшереп Таһирны озатып кадылар. Кайткач, апасы Таһирдан очрашу хәлләрен сорашты. Таһирның да бу шатлык сәгатьләре турында кемгәдер сөйләп, кабат аларны күңеленнән кичерәсе бик килеп тора иде, илһамланып аны апасына сөйләп бирде. Апасының коты очты, бу хәлләрнең Таһирны тагын бәлаләр юлына китереп чыгару ихтималы турында уйлады ул. Таһирга ялварып: «И ике күз нурым, Таһирым, мондый очрашуларда зур хәтәр бар: алар сине тагын зинданга илтеп кертмәгәйләре. Дошманнарыгыз күп. Алар сезнең мондый бәхетле очрашуларыгызга тыныч кала алмаслар. Моннан соң, сарайга барсаң да, югары чыкма, тәрәз төбеннән генә сөйләш. Һәм таңгача тормасаң икән», – дип киңәшләр бирде. Әмма гашыйк күңелләргә берәүнең куркыну-шомлану нәсыйхәтләре тәэсир итә аламы соң?

Һәр көнне мәгъшукасы Зөһрә: «Караңгы төшкәч, кил», – дип чакыру хаты җибәрә. Таһир зарыгудан арып, караңгы кабу минутларын көтә һәм, кеше аягы бераз тынгач, Зөһрә сараена йөгерә иде. Ул Зөһрә тәрәзенә килеп:

Күңелемне нурга күмгән кояшым син, аем син,
Җирдә минем бар шатлыгым, назлы, иркә таем син, —
кебек шигырьләр әйтә. Зөһрә дә ефәк баскычын төшереп:
Уйнавың – сорнай икән, йөзең тулган ай икән,
Син булган җир бу дөньяда җәннәт, дияр җай икән, —
дигән кебек шигырьләр әйтеп каршы ала. Шуннан соң, күрешеп, исәнлек-саулык сорашып, гадәттәгечә табын коралар. Таңга кадәр бер-берсенә үзләренең сөю хисләрен сөйләп кочышалар, үбешәләр һәм шигырьләр әйтешәләр иде.

Көн артыннан көн үтә торды. Һәр кичтә Таһир, алтын сазын алып, Зөһрә сараена юнәлә. Җан Зөһрә, тәрәз канатларын ачып җибәреп, аны көтеп утыра торган була. Аның күләгәсе тәрәзә янында күренү белән:
Сыгылмалы билләрең, башта гыйшык җилләрең,
Син — егетләр солтанысың, юк килмәгән җирләрең, —
кебек сагыну шигырьләре әйтеп көтеп ала. Таһир аңа җавап кайтара:
Күрсәм гел гөл йөзеңне, аһу нәргис күзеңне,
Зөһрәм, оҗмах түрендәдәй сизәмен мин үземне, —
дип шигырь әйтә. Тагын аларның бергә үткәргән тиңсез бәхетле кичәләре башлана. Кайвакытта, дөньяның серләрен белергә теләпме, үз язмышларын аңларга тырышыпмы, бер-берсенә шигырь белән табышмаклар әйтешәләр, уйланып, ул табышмакка җаваплар юрыйлар.

Беркөнне Җан Зөһрә Таһирга:
Илаһыбыз – бар кылган, җан иясен пар кылган,
Ник дөньяда Сәмруг кошын үз ишенә зар кылган?
Таһир уйга тала. Ниһаять, бер карарга килеп, җавап кайтара:
Сәмруг кош күз дә салмый унсигез мең Галәмгә,
Ишен эзләп күз теккән тик Җир йөзенә – адәмгә...

Кыскасы, болар үзләрен, дөньяларын истән чыгарып, онытып гомерләренең бу исерткеч бәхетле минутларын кичерделәр. Әмма боларның очрашуларын күрүчеләр табылды. Алар хәбәрне соңгы яудагы «җиңүләре»ннән соң илнең хакыйкый хуҗасы булып калган Карабатырга җиткерделәр. Карабатыр шул кичтә үк килеп, ышеренеп, боларның очрашуларын күзәтте. Көнләшү, гарьләнүеннән йөрәге шартламый калса, Таһирдан үч алырга, дип кенә шартламагандыр. Икенче көнне хәлне ул түкми-чәчми ханга сөйләп бирде.
Тәкъсыйр, ханым, Галәмгә баш солтаныбыз!
Күп елларга имин булсын мал, җаныгыз.
Шәһәргә кайтмаска, дип ярлыйк кыйлган,
Кайткан ич теге шомлы дошманыгыз.

Гаҗәп: бер кол да санга сукмый хан хөкемен!
Зиндан, богау җиңмәгәнне тыяр кемең?
Кайткан Таһир, йөри Зөһрә сараена, –
Тәрәзәдән кереп шунда куна төнен...

Дәвамы бар

Текстны басмага
***Мәсгут Гайнетдин** әзерләде.* ■

Кыйссаны тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында укырга мөмкин.

СӘНӘКЧЕЛӘР

Зариф Мөэминов

(Булган хәлләргә нигезләнеп язылды)

Кара төннәр, кара төннәр,
Ник ачылмый бу көннәр?
Кара давыл, томан булып
Килде безгә сәнәкчеләр.

«Сәнәкчеләр» бәетеннән

Мең тугыз йөз егерменче еллар. Гражданнар сугышы аяусыз төс алды. Минзәлә өязенә кергән авылларда да тынычлык югалды — сәнәкчеләр фетнәсе башланды. Алар эшне белеп йөртәләр иде: иң элек Минзәлә шәһәренә тоташа торган телефон һәм телеграф элемтәләрен кисеп бетерделәр. Авыл коммунистларын һәм кызыл активистларны тәмам курку басты. Ирешкән хәбәрләргә караганда, коммунистлар урман-әрәмәләргә качалар икән, яшеренеп өлгермәгәннәрен рәхимсез рәвештә кыралар, йорт-милекләрен талап туздыралар, ди. Гаиләләрен дә аямыйлар икән.

Фетнә бу якка килеп җитмәгән иде әле. Март аена керү белән авылларда һәм волость үзәкләрендә эшләүче коммунистлар кисәк кенә төшенкелеккә бирелделәр. Фетнәне тиз арада бастырырлар, дигән өмет шәме көннән-көн сүрелә, тәмам сүнүгә бара иде. Яңарак кына партиягә керүчеләр диндар картларны да уздырып мәчеткә

йөри башладылар. Муллалардан фатиха алып калырга тырышалар, имеш, алар үтә дә динле кешеләр, яхшы бәндәләр, Ходай кушканга каршы барганнары юк, халыкка бернинди начарлыклары тимәгән. Алар, шул рәвешле, мәчет картларының, авыл җәмәгатенең үзләрен яклап калуына өмет итәләр иде. Имеш, сәнәкчеләр картларның сүзенә колак салып, боларны туздырмыйлар, үтермиләр булып чыга.

Халык арасында чыш-пыш көчәя генә бара. Кем шомланып, кем сөенеп, сәнәкчеләр килүен көтә. Фетнәчеләр кылганны күпертеп, берне биш итеп сөйләү гадәткә керде. Совет яклыларның көне дә, төне дә шомга әйләнде. Укытучылар да пошаманга төште. Сәнәкчеләр аларны да җәзалап, җаннарын алганчы кыйныйлар икән. Коммунистлар куркуларын тышка чыгармыйлар иде, ярлы һәм урта хәлле крәстияннәр исә борчылалар. Ә инде авылның байлары, дин әһелләре сәнәкчеләрнең килүен корбан бәйрәмен көткән кебек көтәләр иде.

«Сәнәкчеләр кемнәр соң алар, кайдан килеп чыкканнар?» — дигән сорауга төгәл, төпле җавап бирүче юк. Тик кайбер белдеклеләр:

— Зәки Вәлиди командасы икән ул сәнәкче дигәннәре. Аның гаскәрләре Русиядә булган барлык коммунистларны кырып бетереп киләләр икән, — диләр. Бу сүзгә караганда, димәк, сәнәкчеләр — зур көч, яуларда чыныккан регуляр армия булып чыга.

Кайберәүләр:

— Сәнәкчеләр — Зәй баяры Медведев яки Зайцев командасы икән, шул баяр фронттан качкан дезертирларны җыйнап алган да, үз урманы уртасына лагерь корган. Аларны ныклап коралландырган, солдат уены уйнаткан, хәзер инде коммунистларга каршы сугыш башлап җибәргән. Тиз көннәрдә безнең тирәгә килеп җитәчәк икән, — дип сөйлиләр. Җитмәсә, һәр авылдан солдат булырдай халыкны үз сафларына кушалар, ди. Корал, ат бирәләр икән, имеш...

Монысы дөрес булыр. Халык шаулаша, кем белән кем очрашса да, сүз шушы хакта.

— Килсеннәр, күрербез... Командирлары бармы? Сугыш киемнәре ничегрәк? Утлы кораллары шәпме? Чын гаскәригә охшап тормыйлар икән, җүләрләнеп, атка менеп, күсәк тотып кемнәр сугышка барыр?.. — дип сөйләнә бераз армия хәлләрен белүчеләр.

Байларга болай фикер йөртү ошамый иде. Каты каршы чыктылар.

— Ашыкмагыз, командирлары да килер. Киемен дә, коралын да бирерләр...

Авыл халкы сәнәкчеләрнең эш йөртү алымнарын да ишетеп беләләр иде инде. Авылга килеп керүгә, беренче приказлары шул: коммунистларны тотып алырга һәм юк итәргә! Аннан күрше авыллардагы коммунистларны ауларга җибәрәләр. Бу, чыннан да, зур афәт, көчле гарасат, моннан исән калулары икеле иде. Һәрхәлдә, сәнәкчеләр үткән авылда бу әмернең үтәлми калганы юк, диләр.

Авылның беренче коммунистларыннан булган Хәсән сәнәкчеләр килеп җиткәнче качу ягын чамалап бетермәде. Моның никадәр ялгыш булуын соңлап аңлады. Ул бичара хәлендә калган иде. Беренчедән, волость комитеты аңа милиция вазифасын үтәүне тапшырды, башкалар качканда, ул авылда тәртипне саклап калырга тиеш иде. Вазифа бирделәр, кулында бер коралы, таянырга кешесе юк. Икенчедән, күп тырышлыклар куеп, иске бер өйне сипләп, башка чыккан иде. Әле сәнәкчеләр тиз генә килеп җитмәс, дигән ышаныч көчле булганга, Хәсән дус-ишләрен җыеп, мәҗлес хәзерләде. Бу көн — унбишенче март, җомга иде. Мәҗлес кызып барганда, көн үзәгендә, авылга кара яу килеп тулды. Барысы да ат өстендә, кулларына сәнәкләр, чукмарлар, күсәкләр тоткан, карап торуга гапгади авыл крәстияннәре иде болар. Алар шулхәтле күп, авыл өстенә кара болыт ишелгәндәй булды. Менә сиңа көтелмәгән кодалар! Ул арада Хәсән коммунистның

өе камалышта калды. Өстәлдәге һәммә төр ашамлыкларны урамга алып чыгып ашарга тотындылар. Кайсы кисәге белән пар чыгып торган кайнар ит күтәргән, кайсы майлары агып торган бәлеш тоткан. Бидрәгә салып кайнар ит шулпасын алып чыктылар, кашык-фәлән юк, шулпага ипи манып кына сыптырталар. Әмма җәзалау эшен дә икенче чиратка калдырмадылар. Хәсәннең карт атасы белән әнисе карчыкны күсәк белән сугып карга ташладылар, чукмар белән хатынының башын ярдылар, ике сабый баласын типкәли-типкәли көрт астына күмеп куйдылар. Йортта нәрсә булса, барысын кырдылар, тәрәзәләре ике каты белән коелып төште. Өй эчендә буран уйнап тора иде.

Хәсән качып өлгерде. Лапаслар арасына ящеренеп кич җиткерде, аннан Калмыя буйлап күрше авылга йөгерде, таныш тол хатынның землянкасына кереп яшеренде. Моннан да килеп табарга мөмкиннәр иде. Кача-поса кире авылга кайтты, күршесенең салам өеме астына качты. Энесенә яшеренергә апасы ярдәм иткән иде, ул төн урталарында Хәсәнгә ашарга китереп китә иде. Салам астында Хәсән ун көн җан асрады, фетнәне бастыру өчен ныклы чара күргәннәре сизелми. Алар авылда хуҗа иделәр әле. Алай-болай бәрелеш булып, бер урында тар-мар ителсәләр, сәнәкчеләр фетнәсе икенче урыннан калкып чыга торды, Хәсәннең яшеренеп ятуына күршесе риза булмыйча тавыш чыгара башлагач, бер төнне башка урынга күчәргә, дигән карарга килде. Яшеренгән урыннан килеп чыгуы белән Хәсәнне тотып алдылар һәм чанага бәйләп салып, фетнәнең төп штабына — Бакалыга алып киттеләр. Бу көннәрдә сәнәкчеләр үзләренчә бераз тәртип белән эш йөртә башлаганнар иде. Самосуд ясау тыелды, коммунистмы, түгелме, тотылган һәр кешене башта штабка — Бакалыга китереп тикшерергә тиеш иделәр. Иң элек тоткынның чынлап та коммунист булу-булмавын ачыклап, тиешле беркетмәгә язарга кирәк, дип тәкрарлап тордылар. Шуннан соң гына хөкем чыгарыла, имеш. Ләкин чынбарлыкта штабка җибәрелгән коммунистларны йә юлда ук юк итәләр, яки штабта тоткыннардан беренче сорау алганнан соң, ябып кую урынына илткәндә, ягъни тикшерү эшләре төгәлләнгәнче үк тукмап үтерәләр. Бер сүз белән әйткәндә, Бакалыга илтү һәрчак үлем белән тәмамлана иде. Хәсәнне дә, сорау алу беткәнче, чиркәү ишегалдында тукмап үтерделәр.

Сәнәкчеләр штабында, чынын аңлапмы, аңлап бетермичәме, укый-яза белүче бер коммунистны писарь итеп тотканнар. Ул сәнәкчеләр кылганнарны барысын да тәртип белән язып барган. Кем ничек, кайчан, кемнәр тарафыннан үтерелгән — һәммәсен теркәп куйган. Алай гына да түгел, тегеләки бу коммунистның чыннан да үтерелгән булуын раслаткан булып, җанкыярларның имзаларын да алып калган. Тикшерүчеләргә бу мәгълүматлар нык ярдәм иткән. Гаеплеләр барысы да җәзага тартылып беткән. Сәнәкчеләр фетнәсендә һәр авылдан кешеләр күпләп катнашты, тик авыл халкы бер-берсен сатып, әләкләп әрәм итешмәү ягында тимер сыман нык торды. Ихаталарына кайтып егылган фетнәчеләрнең күбесе бикләнеп, өйләреннән чыкмый яттылар.

Уйлап карыйк, сәнәкчеләр восстаниесенә авыл крәстияннәре ни өчен шулай актив катнаштылар соң? Моның өчен сәбәпләр бар иде шул.

Беренчедән, совет законнары авылда өйрәнелгән гражданлык хокукларын кысты. Мәсәлән, өйләнешүчеләргә волость идарәсенә барып язылышу мәҗбүри итеп куелды. Элек никахны авыл муллалары метрикага теркәп алып баралар иде. Каядыр барып йөрисе дә юк. Шәригать кануны бозылуга күпләр каршы килде. «Мондый хәл Коръәнне аяк астына салып таптау, мөселманнарны көчләп ислам диненнән чыгару була», — дип сүз йөртүчеләр дә булды. Халыкның коммунистларга ачулары кабарды. Бу хатаны төзәттеләр — сәнәкчеләр таратылгач, ЗАГС бүлекләрен авыл советына күчерделәр.

Икенчедән, продразверстка дип халыкка тынгылык бирмәделәр. Булган бөтен икмәкне кырып-себереп алып чыгып китә тордылар. Элекке чорда хәлле кешеләр ярлыларга ашлыкны бурычка яки эш хакы өчен түләү итеп бирә иде, арткан икмәкне хөкүмәткә саталар иде. Хәзер артык, ягъни запас икмәк тоту тыелды. Хәлле кешеләр мохтаҗга әйләнде, авыл ярлыларына түгел, икмәкләре үзләренә дә җитми башлады. Үз хокукларын кайтару юлында алар ярлыларны советка каршы котырттылар.

Өченчедән, коммунистлар арасында да төрлесе бар иде. Кайбер коммунистлар үз интересларын алга куеп, халыкны куркыту, талау юлына бастылар. Эш башында утыручылар юк кына нәрсә өчен дә кешедән взятка алырга остарып, взятка капчыкларына әйләнде. Совет кануннары чыгып кына тора, беркем дә аларны дөрес файдалану юлын белми, белгәне күрсәтми. Тик торганнан ялгышлык эшләп, хөкемгә эләгүдән курку көчле иде халыкта. Взяткачылар шуннан файдаланып эш йөрттеләр. Коммунистларның ярлы халыкка, гомумән, һәркемгә ярдәм итүенә ышаныч бетте. Халыклар коммунистларга ерткыч палачларга караган кебек карыйлар иде.

Дүртенчедән, коммунистлар сыйнфый яктан да чуар иде. Укымышлы баяр малайларыннан алып, берәр шәбрәк урынга эләгү нияте белән коммунист булып киткән ачтамак, надан, булдыксыз бәндәләр дә җитәрлек иде. Халыкны киләчәктә ни көтә? Аңлатучы юк, максатларны белгән кеше юк. Хәллерәк хуҗалыкларны талау һәм куркыту киң җәелде, хәтта юк кына сәбәп өчен җир җимертеп йөргән эш кешесен урам уртасында атып китү дә була иде. Хосусый сәүдә тыелды, авыл хуҗалыгы продукциясен, шулай ук промтоварны да сатарга яки сатып алырга юл куелмады. Берәрсе ни дә булса сатса яки сатып алса, аның өенә обыск ясап, мөлкәтен тартып алалар, үзен төрмәгә озаталар иде. Моны авыл активы тиз һәм каршылыксыз башкарып чыга иде.

Авылда керосин да, тоз да юк иде. Яктырту өчен туңмай яндыралар, ризыкны тозсыз ашыйлар. Качып-посып йон, киндер эрләп, шуннан кием-салым майтарып кияләр иде. Кешеләр шул хәлгә җитте, үзе җитештергән азык-төлекне — икмәк, ит, сөт ише ризыкларны үз-үзләреннән урлап кына ашый башладылар. Мәсәлән, барлы-юклы запас икмәкләрен разверсткага алып бетермәсеннәр өчен, аны җиргә

казып күмәләр. Төнлә яшерен юллар белән генә барып алалар, яшертен генә базга төшеп, кул тегермәне белән тарталар. Сугымлык мал-туары булса, лапаста яки землянкада төнлә белән генә суялар, итләрен базга яки салам астына күмәләр. Шулай итеп һәркем караклык белән тормыш итүгә кереште.

Волисполком рәисе Дусманов элек указлы мулла булып, указын ташлап, коммунист булып китсә дә, халыкка начарлык кылмады. Әмма халык башка коммунистларның кыланганнарына шулкадәр ачулы иде, сәнәкчеләр аның тәүбә итүенә, ялыну-ялваруына карамастан, күсәкләр белән кыйнап, сәнәкләр белән кадап үтергәннәр. Яклаучы табылмаган. Дусманов качып котылу мөмкинлеге булса да, халык яклавына өмет итеп һәм сәнәкчеләрнең үзенә тимәячәкләренә ышанып, качмый калган булган.

Сәнәкчеләрнең тактика һәм тәртипләре нидән гыйбарәт иде соң? Үзенчәлекле тактика тоттылар алар. Бер авыл крәстияннәре икенче авылга, ягъни күршеләренә басып кереп, анда булган коммунистларны табып үтерәләр. Аннан шул авылдагы крәстияннәрне өченче бер авылга, коммунистлардан үч алырга куалап чыгарып бетерәләр дә, үзләре кире авылларына кайтып китәләр. Совет яклылар тарафыннан каршылык кылу көчлерәк булган җирләргә берничә авыл крәстияннәре җыйнаулашып баралар. Рәхимсезлекнең сәбәбе шул: аларга аңлатып торалар — сәнәкчеләр сафына тиздән кораллы солдатлар килеп кушыла. Крәстияннәрнең кирәге калмый, алар, авылларына кайтып, җир эшенә тотыначаклар, имеш. Калган эшне регуляр армия төгәлләячәк. Бераз гына түзегез, совет властеның көннәре санаулы гына, имеш. Фетнәдә ныклап катнашканнарга яңа хөкүмәт төяп байлыклар бирәчәк, имеш. Барысы да тилмереп Зәки Вәлидинең регуляр армиясен көтәләр. Тик Зәки Вәлиди дә, регуляр солдатлары да килми булып чыкты. Сәнәкчеләр арасында Кызыл Армиядән качып яки болай кайткан солдатлар да күп иде. Күпләренең кулларында мылтык, утлы корал. Фетнәчеләр кулында торган саен мылтыклар күбрәк күренә башлады. Чөнки бу яктагы авыллар аша гражданнар сугышы үтте, авыллар кат-кат кызыллар яки аклар кулына күчте. Шулчакта яшереп алып калынган припаслар, кылыч-мылтыклар, патроннар өскә чыкты.

Сәнәкчеләр фетнәсе зур җирләрне биләп алды. Минзәлә өязе бөтенләе белән, Бөгелмәнең күпчелек өлеше, Бәләбәйнең яртысы, Бөре һәм Уфа тирәләре ялкынга чорналды. Хәрби тактика чаткылары чагыла башлады. Халыкны да онытмады сәнәкчеләр — совет хөкүмәте халыктан көчләп җыеп, глубинкаларда саклаган икмәкне авылларга тараттылар, аерым йортларда икмәк пешертеп, яудагыларны азык белән тәэмин итү эше җайга салынды. Корал торган саен күбәя, каршылык итү көчәя барды.

Совет власте бу афәтне авырлык белән генә бастырды.

Егерме көн дәвам итте бу фетнә. Совет ягыннан хәрәкәт итү өчен империалистик сугышта пленда калган маҗар (венгр) солдатларыннан төзелгән отрядлар килеп җитте. Алар беркемне дә кызганып тормады. Турыдан-туры коммунистларны үтерүдә катнашучылар урында ук аттырылдылар, актив талаучылар Казанга җибәрелделәр. Ләкин аларның да күпләре юлда һәм Казанда кырылып беттеләр.

Чыннан да, бу фетнәне Зәй баяры кузгатып җибәргән булып чыкты. Зәй баяры хакында аны камауга баруда катнашкан кешеләр бик гаҗәп хикәяләр сөйләп йөрделәр. Сөйләүчеләр арасында коммунистлар да бар иде. Имеш, баярга залп белән атып та, аңа бер пуля да тимәгән. Баяр пуля бураны эчендә пар атын җиктергән, хатынын үз янына, кучерын ат башына утырткан да утарыннан давылдай чыгып чапкан. Отряд залп белән ата-ата куган. Тик аларга бер пуля да тимәгән. Баяр күздән югалган, шул китүдән яңадан кире кайтмаган, беркем дә аны яңадан күрмәгән. Гаҗәп түгел, ул чакларда границалар ачык иде бит...

ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛ БАШЫНДА
(«Сәнәкчеләр»)

Егерменче еллар башында, мартның унбишләрендә,
Каты куркыныч башланды кичатна кичләрендә.
«Сәнәкчеләр килә икән!» — дигән хәбәр таралды,
Контрларга, палачларга шунда канат яралды.
Кичатна көн кич булгач, разведчиклар киттеләр,
Җомга көнне сәнәкчеләр безгә килеп җиттеләр.
Ак сакаллы картларга да көчләп сәнәк тоттырып,
Урам буйлап карагруһ йөри тәмам котырып.
Авылдан авылга чабып приказ ташып йөриләр,
Йортлар саен: «Коммунистлар кайда?» — диеп сорыйлар.
Мөхәммәтҗан коммунистны тотып алып чыктылар,
Әхмәтгалиләр турында аны кадап ектылар.
Фәхриҗамал апа елый: «Мөхәммәтҗанкаем! — дип, —
Балаларым өелешеп ятим калдылар бит!» — дип.
Чылтыр-чылтыр тәрәзәләр уалып төштеләр карларга,
Коммунистларның йортларын тотындылар таларга.
Дошман халык, дезертирлар качып-посып ятканнар,
Кулларына сәнәк тотып бүген калкып чыкканнар.
Рәбига белән Кәрәмне укытучы булганга,
Яланаяк, шәрә тәннән камчылыйлар урамда.
Кычкыралар, сугалар, камчы белән туныйлар,
Укучы балалар, күреп, кан-яшь түгеп елыйлар.
Рәбига белән Кәрәмне таш амбарга яптылар,
Салкын көннең гайрәтендә ак боз булып каттылар.
Исмәгыйль карт, Сәрби карчык бузлап елап йөриләр,
«Коммунист улың кайда?» — дип мылтык төзәп сорыйлар.
Әтисе-әнисе картларны Хәсән мәрхүм, кызганып,
Яшеренгән җиреннән килеп чыкты сызганып.
Мылтыгыннан бишне атты вәхши сәнәкчеләргә,
Курка дошманнар, сирпелде, кая якын килергә.
Патроны беткәч, кыныннан тартып алды кылычын;
Батыр коммунист берүзе көрәшә — көчле лачын!
Хәсән коммунист тотылгач, «штаб»ка дип киттеләр,
Чанага бәйләп салдылар, Бакалыга илттеләр.
Сәнәкчеләр штабында хөкем итә җиде поп;
Тагын берничә мулла бар, яхшы кеше беркем юк.
Поплар хөкем иттеләр, Хәсәнне үтерттеләр,
Мылтык белән атмадылар, сәнәк белән төрттеләр.
Казанчыга сәнәкчеләр бер пулемёт корганнар,
Кызыл гаскәрләр килүен шунда көтеп торганнар.
Кызыллар ата башлагач, һәммәсе дә таралган,
Сәнәкчеләр «фронтында» өч поп, дүрт мулла калган.
Кулакларны тар-мар итеп кызыллар килеп җитте,
Кызыл гаскәр килеп кергәч, кулакларга көн бетте. ■

БӘРӘКӘТЛЕ ОРЕНБУРГ ТУФРАГЫ

Лирон Хәмидуллин

5

1908 елда бертуган Рәмиевләр Дәрдемәнд яшәгән йорт янәшәсендә (арткы урамда) иркен бина булдырып, шунда үз басмаханәләрен җиһазлауга керешәләр. Кирәк-яракларны, сыйфатлы буяуларны чит илләрдән кайтарталар. Шул заман матбугатында берәр төрле хәбәр күренгәндерме, юкмы — белмим, әмма, минем уйлавымча, баштарак ул басмаханәнең эшләрен җайга салу Кырым татары Нури Акчокраклыга йөкләнгән. Бераздан ул йөкне Ярулла Вәли җилкәсенә «аударганнар». Әлегә Ярулла Вәлинең кайчаннан ул басмаханәгә мөдир булганлыгын төгәл күрсәтүче язма очрамады. Ә аның 1910 елларда шул вазифаны башкаруы турында хәбәрләр күренгәләде. 1918 елның февралендә «Вакыт» басмаханәсе белән нәшриятын Совет хакимияте вәкилләренә тапшыру барышында Закир Рәмиев-Дәрдемәнд белән бергә Ярулла Вәли дә катнашканнар. Шул хакта истәлекләр бар.

Инде Нури Акчокраклы белән танышып үтик. XIX йөз ахырларында аның Петербургта Ильяс Бораганский басмаханәсендә (шулай ук Кырымда, Бакчасарайда туган шәхес) эшләгәнлеге мәгълүм. Бу кеше оештырган нәшрият белән басмаханәдә олугларыбызның бер дистәдән артыграк чамада китаплары басылып чыга: Фатих Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» Ризаэддин Фәхреддиннең «Мәгашәрәт адабе», Камил Мотыйгыйның ике китабы, казакъ әдәбияты классигы Абайның тәүге шигырь һәм поэмалар җыентыгы һ.б.

Аурупа илләре буйлап эшлекле сәяхәткә чыгып китәр алдыннан, 1899 елның март башында, Шакир Рәмиев һәм аның юлдашы, тәрҗемәчесе Фатих Кәрими берничә көн илнең башкаласы белән танышып йөриләр. Патша сараен саклаучы, патшаларның үзен, гаиләләрен саклап, озатып йөрүче мөселмен гаскәриләре ахуны Гатаулла Баязитов, Россия тимер юлларының көньяк һәм көнбатыш юнәлешләрендәге күпчелек вокзал буфет-рестораннарын тотучы сәүдәгәр Максудовлар белән очрашалар. (Хәтерләсәгез, 1912 елда Галимҗан Ибраһимов нәкъ шушы Максудовлар нәселенә караган берәүнең балаларын татарча укытырга дип Киев шәһәренә бара.) Башкаланың музей-китапханәләрендә, Фәннәр Академиясендә булалар. «4 март, якшәмбе көн, Петербургта матбага исламия имтиязы (тоту рөхсәте) алган

*Ахыры. Башы журналыбызның 10 нчы санында

Рәмиевләр матбагасы хезмәткәрләре. Утыралар (уңнан): Борһан Шәрәф, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, Ризаэддин Фәхреддин, Фатих Кәрими, Габдрахман Фәхреддин. Басып торалар: Ярулла Вәли, Госман Нури Акчокраклы, Рәкыйб Рәкыйби. Оренбург, 1909 ел

морза Бораганский илә көрәшергә бардык», — дип яза Фатих Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе» китабында. Басмаханә эшчәнлеге илә танышып йөргәндә әлеге Нури әфәнде белән дә очраша алар, ул иҗат иткән тарихи һәм җәмгыяви эчтәлекле китапларны да күздән кичерәләр. «Госман Нури Акчокраклызадә — Кырымның Бакчасарай бәлдәсеннән (шәһәреннән). Бу зат исламча вә урысчадан гүзәл хәбәрдар булып, гүзәл язмыш булдыгы «Бакчасарай чишмәсе», «Тәнкәҗан ханым» (Мамай хан кызы), «Мөләхаза» исемле әсәрләреннән мәгълүмдер», — дип бәян кыла автор.

Шушы кешене Оренбургка соңрак Шакир әфәнде үземе, әллә Фатихмы чакырган булырга тиеш. Аның килүе «Вакыт» басмаханәсе ачылышка туры килерелә. Шуңа чаклы Ярулла Вәлигә «Вакыт» һәм «Шура»га кагылышлы хуҗалык-финанс эшләрен үтәү, аннан тыш тагын яңа бурычлар да йөкләнгән була. Беркадәр соңрак «Вакыт» басмаханәсенең мөдире үк итеп куялар. Шул вазифаны үтәгәндә ул Зәйнәп Рәмиевага өйләнә. Әмма кайчан? Бу кадәресен, мөгаен, «Вакыт» битләреннән укып белергә мөмкиндер. 1914 елда аларның улы Баязид (Бөек Ватан сугышында һәлак була), 1918 елда кызлары Асия туа (1979 елда Уфада вафат). Зәйнәп Рәмиева да 1977 елда шул ук шәһәрдә, кызы кулында бакыйлыкка күчә.

6

Иң әүвәл Рәмиевләрнең «Вакыт» газетасында (1906-1918, февраль), соңрак шул исемдә ачылган «Вакыт» нәшрияты һәм басмаханәсе»ндә (1909-1918, февраль), «Шура» журналында (1908-1918) эшләгән шәхесләрнең кайберләрен телгә алып китик. Мәгълүм ки, бу басмаларны ачучы һәм үз хисапларына тотучы бертуган Шакир вә Закир Рәмиевләр үз даирәсенә хөр

фикерле, укымышлы шәхесләрне якынайтырга тырышкан. Татарстан Дәүләт архивының хәзерге Кремль урамында урнашкан төп бинасында әлеге басмаларга кагылышлы бай бер фонд бар. Ул фондка беренчеләрдән мөрәҗәгать итүчеләр арасында мин фәкыйрегез һәм фотограф Зөфәр Бәширов табар. Бирегә тупланган иллегә якын хат һәм утыз-кырыклап төрле рәсми кәгазьне яисә аларның күчермәләрен 1971 елда Закирә Шәрәфме, варисларымы тапшырган, ахры. Зөфәр Бәширов белән бергә «Дәрдемәнд» альбомын чыгарырга әзерләнгәндә (ул туксанынчы еллар башында ук нәшрият планына кертелгән иде, илдә башланган үзгәрешләр, башбаштаклык нәтиҗәсендә ун елга соңлап дөнья күрде) шул фондтан төшереп алынган кайбер документларны кулландык. Соңрак та ошбу фотоматериалларның байтак өлеше «Бертуган Рәмиевләр» (2002), «Дәрдемәнд. Агарган кыл» (1999), «Фатих Кәрими» (2000) һ.б. китапларда урын алды. Шушы ук фондта теркәлгән бер документта Рәмиевләр басмаханәсенең 1908 елның ахырларында ук эшли башлаганлыгы турында да мәгълүмат бар, декабрьдә бирεдә Ризаэддин Фәхреддиновның дини эчтәлекеле «Гакыйдә» (ышану) исемле китабы басылып чыга.

Әбрар Кәримуллиның «Рәмиевләр басмаханәсенең төп хуҗасы Фатих Кәрими» дигән сүзләрендә өлешчә хаклык та юк түгел. Бу фондтагы кәгазьләр белән танышкач, шул фикергә киләсең. Рәмиевләр матбагасының һәр тармагында диярлек төп эш башкаручылар — аның кешеләре яки туганнары. Рәмиевләр хезмәткәрләр сайлауга аңа тулы ирек биргән. «Вакыт» газетасы хезмәткәрләренең губернатор канцеляриясе тарафыннан расланган исемлегендә баш мөхәррирнең беренче урынбасары итеп Ризаэддин Фәхреддинне күрәбез. Ваграк хезмәт үтәүчеләр исемлегендә Фатих мәхдүмнең энесе Камил дә, туганнан туганы Риза хәзрәтнең уллары да теркәлгән.

Дөрес, Рәмиевләр Ризаэддин Фәхреддинне Уфада мөфтияттә эшләгән чагыннан ук белгәннәр, шул хакта истәлекләр дә сакланган. Казый вазифасын башкарганда ул берничә мәртәбә Оренбургта да булып-булып киткәләгән, шәһәр зыялыларыннан Рәмиевләр, Хөсәеневләр белән якыннан аралашкан. Туксанынчы елларда ук Оренбург янәшәсендәге Каргалыга багышлап һәм авылның беренче рәсми исемен истә тотып «Сәгыйд» исемле китабын да язып бастырган. Дин, гыйлем, тәрбия өлкәсенә кагылышлы ике дистәгә якын китап язган хәзрәтне Оренбургка күченергә бертуган Рәмиевләр үзләре кодалаган — 1906 елның җәй урталарында Оренбургка килгәч тә, аның ишле гаиләсен матбугат хезмәткәрләре өчен дип төзелгән һәм Шакир Рәмиев йортына янәшә булган йортка урнаштырганнар. Өч бүлектән торган бер катлы бу өйнең ике өлешендә Риза хәзрәт гаиләсе, тагын берсендә төрле вакытта башка мөхәррирләр яшәгән: Ярулла Вәли, Борһан Шәрәф, Шәриф Камал, Кәбир Бәкер, һ.б. Матбагага эшкә билгеләнүчеләр турында губернатор канцеляриясенә юлланган документларның кайберләрендә шулай «живёт на улице Эссенской в доме Рамиевых» дигән сүзләр теркәлгән.

1908 ел башыннан Ризаэддин Фәхреддин «Шура» мәҗмугасы мөхәррире итеп билгеләнә. Аның эш бүлмәсе дә шушы ук өйнең элекке «эш кабинеты»нда урнаша. Ә «Вакыт»ның икенче мөхәррире вазифасын үтәү аның улы Габдерахманга йөкләнә.

1908 елда Казанда, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә сәяси шау-шу чыгып, мәдрәсә башлыгы Галимҗан Баруди Вологда губернасына, башка мөгаллимнәр кайсы-кая сөргенгә җибәрелә. Патша заманында, гадәттә, гаебе зуррак

булганнарны шулай төньяк тарафка, гаепләре кечерәк саналганнарны туган якларына озата торган булганнар. Шул ук елларда, шул ук Казанда Гаяз Исхакый төркеменә карата да хөкем карары чыгарыла. Гаяз әфәндене ераккарак олактыралар, ә аның төркеменнән кайберәүләргә фәкать «Казанда яшәргә рөхсәт ителми» җәзасы гына бирелә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бәйле вакыйгада да «яшь хәлфә һәм журналист» Борһан Шәрәф тә Казанда яшәү хокукыннан мәхрүм ителә. Ләкин ул башка кайберәүләр кебек туган төбәгенә — Сембер губернасына кайтырга теләми. Казан матбагачылары Шәрәфләр дә энеләренә җылырак, төшемлерәк урын сайлагандыр, күрәсең, Рәмиевләр белән элемтәгә кереп, аны «Вакыт» газетасына эшкә урнаштыралар. Тиз генә арада ул баш мөхәррирнең беренче урынбасары (икенче мөхәррир) урындыгын яулый. Фатих Кәриминең сеңлесе Закирәгә өйләнә. Ә Габдрахман Фәхретдин шундый ук вазифаны үтәргә «Шура»га, «әтисе куенына» күчерелә һәм биредә алты ел чамасы эшли. Бер-ике мәртәбә, атасы айлапатналап читкә китеп торган арада, баш мөхәррир вазифасын да башкара. 1916 елда аны хәрби хезмәткә алалар. Аннан соң «Шура»га элек Казанда, «Әл-ислах» газетасында эшләп киткән, хәзер Петербургтагы «Нур» газетасы хезмәткәре булган Кәбир Бәкерне чакырталар. Еш кына безнең матбугатта аның фамилиясен «Бәкерев» дип язалар. Югарыда телгә алынган архив фондындагы документларда ул «родом из бывших казаков Оренбургского казачьего войска Бакиров» рәвешендә теркәлгән.

Язучы Зариф Бәшири 1908-1910 еллар аралыгында Оренбургта яши, Кәримовлар матбагасында корректор (әдәби хезмәткәр) булып эшли. Элегрәк тә «Вакыт», «Шура» битләрендә шигырьләре, башка төр язмалары басылып килгәнлектән, хәзер бу басмалар белән элемтәсе тагын да ныгый төшә. Берара ул «Шура»да әдәби хезмәткәр вазифасын да үти. Әдипнең байтак еллар үткәннән соң Рәмиевләр матбагасына биргән бәһасенә күз төшерик: «Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләрен, культуралы яшәүләрен күз уңында тота… Ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә зур жалованье бирә иде. Мәскәү, Петербургларда … чыга торган урыс газеталарының редакторлары аена 70-80 сумнан артык жалованье алмаганда, «Вакыт» редакторы Фатих Кәримев белән «Шура» редакторы Риза казыйга аена 130ар сум жалованье бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованьесы» дип йөртәләр иде».

1907 елда Рәмиевләрнең Габдулла Тукайны «Вакыт» газетасына эшкә чакырыга теләүләре, әдәби хезмәткәр вазифасы өчен аена 40 сум вәгъдә итүләре билгеле. Бу чорда шундый ук эш башкаручыларның хезмәт хакы 25 сумнан артмаган. Риза казый үз истәлекләрендә Уфада мөфтияттә эшләгәндә елына 800 сум алганлыгын яза. Димәк, Оренбургка күчеп килгәч 1,5 тапкыр күбрәк күләмдә акча ала башлаган. 1370 фондтагы документта бераздан мөхәррирләргә тиешле хезмәт хакының 180 сумга, тагын бераздан 225 сумга җитүе, 1917 елның март ае башыннан янә 50 сумга артуы күрсәтелә. Шәриф Камал белән Кәбир Бәкер элек 120шәр сум алган булсалар, 1917 елда аларга «Закир әфәнде әмере белән» 180шәр сумлык хезмәт хакы билгеләнә. «Вакыт» газетасы чыга башлаганнан бирле анда хуҗалык һәм финанслар өчен җаваплы булган Ярулла Вәли дә 1917 елга чаклы 180 сум алып эшли. Аңа тагын 70 сум өстәлә. Исемлектә теркәлгән барлык унбиш кешенең дә элекке һәм яңа хезмәт хаклары күрсәтелгән бу таблица «Фатих Кәрими» китабының 179 нчы битендә дә урнаштырылган.

7

Ярулла Вәли шәхесенә әйләнеп кайтыйк. Аны да Рәмиевләр даирәсенә Фатих Кәрими «тартып китергән». Узган гасыр башларыннан бирле аралашкан, иҗатташлар буларак дуслашкан алар. Дөрес, аңарчы, ягъни 1906 елның февраленә кадәр, Ярулла Самара губернасының Бозаулык шәһәрендә гомер кичергән. (1934 ел урталарыннан Бозаулык өязе биләмәсе Оренбург өлкәсенә кушыла.) Исмәгыйль Рәмиевнең алдарак искә алып кителгән белешмәлегендә*: «Ярулла Вәлиулла улы Вәлиев Бозаулык каласында сәүдәгәр гаиләсендә туа, берара үзе дә сәүдә эше белән шөгыльләнә, шул ук вакытта хикәяләр, драмалар язып та бастыра (әсәрләр исемлеге китерелә — Л.Х). 1906-1917 елларда «Вакыт» газетасы редакциясендә эшли», — диелгән. Бу кыска мәкалә: «Ачлык кушты» драмасы аны әдип итеп таныта, драма озак еллар сәхнәдән төшми», — дигән сүзләрдә тәмамлана. Автор кулланган «1917 ел» датасы бу очракта дөрес үк түгел, чөнки газета 1918 елның февраль урталарында гына ябыла.

Фатих Кәрими «Кырымга сәяхәт» әсәрендә, 1903 елның апреленә караган өлешендә, Бозаулык станциясе вокзалындагы 20 минутлык бер очрашуны болайрак тасвир итә: анда танышларымнан шәриктәшем Галиәсгәр Гафуров белән сәүдәгәр Ярулла әфәнде Вәлиев бар иде. Оренбургтан китәр алдыннан аларга хәбәр иткән идем. Бозаулык вокзалында алар мине каршы алды, «буфетка кереп каһвә эчкән арада күрештек, сөйләштек. Боларның икесе дә ачык фикерле вә хәмиятле (ышанычлы) затлар. Сүзебез, табигый, халкымызның мәгариф вә һөнәр җәһәтендә бик киредә булмаган «Тәрҗеман»ның 20 еллыгына мөнәсәбәтле иде… Ярулла әфәнденең «Мәңгелек мәсҗед», «Күз яше» исемнәрендә язылып таралган ике рисаләсе (китабы) бардыр. Бик ачык вә хуш лисан (тел) белән язылган бу рисаләләре — үземезнең милли мәгыйшәтемездәндер». Ягъни, үзебезнең татар тормышыннан алынган вакыйгаларга нигезләнеп язылган кызыклы әсәр, ди. Һәм озакламыйча ул шушы «ачык фикерле, ышанычлы», шул ук вакытта эшмәкәрлек кәсебен дә үзләштергән сәүдәгәрне, Оренбургка чакырып китереп (әлбәттә, Рәмиевләр белән киңәшләшкәннән соң), «Вакыт» һәм ике елдан чыга башлаячак «Шура» матбагаларының коменданты итеп билгеләячәк.

1926 елда И.Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты. 1905-1925» исемле китабы да басылып чыккан. Аның «Әдәби сүзлек» һәм шушы җыентыгына таяныпмы, бүгенгә чаклы көндәлек матбугатыбызда Ярулла Вәлине «Бозаулык сәүдәгәре» буларак кына искә алу дәвам итә. Чынында ул икенче җирдә туган, югыйсә: «Вакыт» газетасы идарәсенә эшкә алу документында аның «Сембер губернасы Буа өязе Рангун волосте Бикмураз авылында 1879 елда туган»лыгы теркәлгән. Димәк, ул матбагачы Шәрәфләрнең дә, язучы Шакир Мөхәммәдевнең дә якташы!

Оренбург каласы 1919 елның кышында гына Совет хакимиятенә тәмам буйсындырыла. Ярулла һәм Зәйнәп Вәлиевләр 1918-1919 еллардагы вакыйгалардан соң да Закир Рәмиев-Дәрдемәнд йортында яшәүләрен дәвам итәләр. Җитмешенче еллар җиткәч, Равил Бохараев ачлык чорында (1921) Дәрдемәнд гаиләсенә бирелгән азык-төлек купоннарын алып кайтып, Татарстан Дәүләт музеена тапшыра. Ул заманда Закир белән Мәхүбҗамал, Искәндәр белән Шәрифзадә, Оренбургтан вакытлыча китеп тору сәбәпле, әлеге «карточкаларны» тота алмаган-

* Бу турыда сүз мәкаләнең башында, ягъни журналыбызның 10 нчы санында барды. — *Редакция.*



М. В. Д.

ОРЕНБУРГСКАГО ГУБЕРНАТОРА КАНЦЕЛЯРІЯ

13 Декабря 1907 г.

№ 3894

Оренбургъ.

СВИДѢТЕЛЬСТВО

Дано на основаніи VII Отд. п. I ВЫСОЧАЙШЕ утвержденнаго 24 ноября 1905 года закона о повременныхъ изданіяхъ, проживающимъ въ г. Оренбургѣ, Орскимъ купцамъ Мухамедъ-Шакиру и Мухамедъ-Закиру Мухамедъ-Садыковичамъ Рамѣевымъ въ томъ, что разрѣшено издавать въ г. Оренбургѣ двухнедѣльное повременное изданіе на татарскомъ языкѣ подъ названіемъ „Шуро" (Совѣтъ) по слѣдующей программѣ:

1) Краткіе отчеты изъ иностранной и отечественной политической жизни.

2) Смѣсь.

3) Объявленія.

4) Рисунки.

Отвѣтственнымъ редакторомъ изданія будетъ состоять крестьянинъ Самарской губерніи Реза Эддинъ Фахретдиновъ. Подписная цѣна въ годъ четыре рубля, а какъ приложеніе къ газетѣ „Вактъ" три рубля. Печататься изданіе будетъ въ типографіи „Товарищества печатнаго дѣла Карімовъ, Хусаиновъ и К-о въ Оренбургѣ. Гербовымъ сборомъ оплачено.

Губернаторъ

Управляющій Канцеляріей

Рәмиевләргә «Шура» журналын нәшер итүгә рөхсәт бирү таныкламасы

нар. Алар киткәч тә, төп йортта калган дүрт кешелек Вәлиевләр гаиләсенә бу купоннарны куллану, шәһәрдән китеп торучылар исеменнән ризык юнәтү мөмкин дә булмагандыр. Дөресрәге, килешмәгәндер. Шуңа күрә алар тотылмыйча Зәйнәп апаның кәгазьләре арасында илле ел чамасы тик яткан да инде. Равил Уфага барырга җыенгач, миннән Зәйнәп апаның адресын һәм телефонын алган иде. Уфадан кайткач та ул иң элек минем эш бүлмәмә килде. Көмеш йөгертелгән, «З.Р.» хәрефләре (Дәрдемәнднең исем-фамилиясенең баш хәрефләре) эре итеп заводта ук сапларына бастырылган бер аш кашыгы, чәнечке белән бергә шушы купоннар төргәген күрсәтеп: «Боларны нишләтик икән? Зәйнәп апаның аларны музейга тапшыртасы килә», — дип киңәш-табыш итте. Минем бүлмәдән үк без музей хезмәткәре Дания Баһаутдиновага шылтыраттык. Шул рәвешле ул «ачлык купоннары» музейга эләкте һәм соңрак «Дәрдемәнд ачтан үлгән», дигән уйдырма хәбәр таралуга сәбәпче булды. Көмеш йөгертелгән шундый ук вензельле (басма тамгалы) кашык, чәнечке, аш табыны пычаклары Дәрдемәнднең Мәскәүдәге оныгы

Бәширдә дә (алты пар иде бугай), Уфада яшәүче оныгы Равилдә дә саклана.

Зәйнәп апаның Уфадагы соңгы күршесе (Ленин урамы, 2 йорт адресы буенча) белән бер сөйләшеп утырган идек. Ул Казанда Габдулла Тукайга куелган беренче һәйкәлнең скульпторы Садрый Ахунның сеңлесе (исемен онытканмын, ләкин кайсыдыр блокнотымда ул исем теркәлгән) иде. Зәйнәп апаның бакыйлыкка күчүен белмичә, аларга дип килгән чагым иде. Шунда бу күрше апа миңа: «Зәйнәп үләре алдыннан анасыннан калган көмеш самавырны Башкортстан Дәүләт музеена тапшырмакчы иде. Гөнаһ шомлыгына, үзе бүлнистә чакта Асиясе аны урлатты. Соңгы вакытларда Асиянең бер дә хәтере юк иде, шул чире аны анасы үлгәч тә гүргә дә алып китте. Асиянең балалары да шул чир белән интегә, айлап-айлап бүлнистә яталар. Менә хәзер дә икәүләшеп шунда әле. Хәл белергә барган күршеләрне дә таныр-танымас хәлдә яталар», — дип сөйләп бирде.

1920 елның апрелендә Оренбург Казакъ (ул вакытта «Кыргыз» дип атаганнар) автономияле мохтариятенең башкаласы итеп билгеләнә. Казакъ кардәшләрнең җитәкчеләре, Рәмиев, Хөсәенев кебекләрнең мәдәният, мәгариф өлкәләрендә кылган уңай эшләрен истә тотып булса кирәк, бу байларның гаиләләренә карата тискәре чаралар кылмый, йорт-җирләрен тартып алмый. 1925 елның июлендә башкала Кызыл Урдага күчерелгәч кысрыклаулар башлана инде. Вәлиевләрнең дүрт кешелек гаиләсе дә тиздән урамга куып чыгарыла. Йорт җиһазлары барысы да үз урынында кала. Бәшир Рәмиев сөйләвенчә, 1926 елда бу гаилә Уфага, Ризаэддин мөфти канаты астына барып сыена. Риза хәзрәт Яруллага мөфтияткә исәп-хисап эшләрен башкаручы итеп кабул итә. Мөфтият бинасының икенче катында аларга яшәү өчен бер бүлмә билгели. 1927 елның җәендә тугыз яшьлек Бәшир беренче мәртәбә аларда кунак була, шуннан соң ул каникул вакытларында ел саен диярлек Баймактан Уфага кунакка барырга гадәтләнә.

Бер-ике елдан соң Ярулла Вәли гаиләсе мөфтият утарыннан ерак булмаган Цюрупа урамыннан бер кечерәк йорт сатып ала, эш урынын да үзгәртә. Ә илдәге түнтәрелешләргә чаклы Алманиядә укып кайткан инженер Искәндәр Рәмиевне (Бәширнең әтисен) утызынчы еллар уртасында Уфага, «Башкирзолото» трестына эшкә билгеләгәч, «Ярулла кияү» дә шул трестка эшкә күчә.

Ләкин бу ике туганны («буржуй баласы» белән «буржуй кияве»!) алда кара язмыш сагалап торган икән. Ярулла Вәли 1937 елның җәендә советка дошман кеше буларак кулга алына һәм шул елның ноябрь ахырларында төрмәдә юк ителә. Искәндәрне 1938 елда кулга алалар, 1943 елның 3 апрелендә ул Томск шәһәре тирәсендәге лагерьларның берсендә вафат була.

Гасыр башында Рәмиевләр матбагасында эшләгән, Дәрдемәнд даирәсенә кергән кайбер башка шәхесләрнең тормышы да утызынчы еллар тегермәнендә «тартыла». Фатих Кәрими 1937 елның 4 августында Мәскәүдә кулга алына. Бер ай да берничә көн үтмәстән шунда юкка чыгарыла. Гадәттә, зур бандитларның да алай ашыктырып гомерен өзмиләр. Аларның да күренеп торган гаепләрен дәлилләү өчен айлар, кайвакыт еллар дәвамында тикшерү оештырыла. Сеңлесе Закирә Шәрәф хәбәр итүенчә, әдипне кулга алырга килгән солдатлар, урам тәрәзәләре төбенә ике йөк машинасы куеп, аның гомере буена җыйган-туплаган бай китапханәсен, кулъязмаларын, архивын да төяп алып китәләр. Татар милләтенең тарихына барып бәйләнгән бу хәзинә, бу байлык шул рәвешле эзсез югала. 1937 елда ил җитәкчеләре кылган кара гамәлләр, бер уйласаң, Явыз Иван заманында кылынган кабахәтлекләрдән бик ерак тормый.

1912 елның 15 мартында Шакир Рәмиевне соңгы юлга озату күренеше. Уңда матур капкалы йорт – Шакир бай гаиләсенеке; сулда – матбугат хезмәткәрләре өчен махсус төзелгән йорт; аның ике секциясендә Ризаэддин Фәхреддин, өченче секциясендә «Вакыт», «Шура» хезмәткәрләре яши

Байтак гомер Фатих каенаганың да, Ризаэддин хәзрәтнең дә уң кулы вазифасын үтәп, татар мәдәнияте, әдәбияты үсеше, һәм, әлбәттә инде, Рәмиевләр матбагасы дәрәҗәсен күтәрү өчен чын күңелдән, ихластан эшләп йөргән Борһан Шәрәфнең дә язмышы шулай төгәлләнә. Ләкин аңа төрмә тормышын озаграк татып, озаграк җәфа чигеп, якты дөньядан соңрак, 1942 елда китәргә яза. Аның агалары, Тукайлар, Әмирханнар, Камалларның иҗат җимешен дистә елдан артык халыкка җиткереп торган Казан матбагачылары Шәрәфләрнең тормышы да энеләре язмышын кабатлый: Шәһретдине 1938 елда, Гыйльметдине бераз соңрак — 1942дә юк ителә.

Бу даирәдән үз үлемнәре белән гүргә кергән затлар күп түгел. Оренбургтан киткәч тә унбиш ел бик катлаулы шартларда дин башлыгы булган, мөфти вазифасын үтәгән Ризаэддин хәзрәт 1936 елда Уфада; Дәрдемәнд күңелен йомшартырдай әсәрләр язган, шул сәбәпле хезмәт хакыннан тыш алтын сәгать, алтын каләм кебек кыйммәтле бүләкләр алуга да ирешкәләгән Шәриф Камал Казанда 1942дә; тынгысыз җанлы, әмма исәп-хисап өлкәсендә дә, сәясәткә кагылышлы мәсьәләләрдә дә беркадәр саклык, саранлык күрсәтә белгән «Тимершаһ кияү» Мәскәүдә 1947 елда вафат булалар. Мөгаен, аларның барысына да — якты дөнья белән үзләренең җылы түшәкләрендә хушлашучыларына да, рәхимсез җәллад газапларын кичеп үлгәннәренә дә Аллаһ Тәгалә оҗмах ишекләрен ачык иткәндер. Үз милләтенең рухи үсешенә, алга китешенә хәл кадәри өлеш керткән зат ич алар! Гадәтенчә, сабыр гына атлап, гаүдәсен төз тотып, ул оҗмах капкаларыннан иң беренче булып фикердәшләрен әйдәп Дәрдемәнд үзе үткәндер, әлбәттә. ■

Кайтаваз

Алтынга бакыр ябышмый

Марсель Галиев

«Муса Җәлилнең яңа табылган шигырьләре», дип куймаска иде! Сүзем – «Безнең мирас» журналының быелгы 8 нче санында Рәзин Нуруллинның «Акка кара төшсә, югалмый» дигән мәкаләсе һәм шуңа өстәп бирелгән алты шигырь уңаеннан.

Муса Җәлилнең «Шталаг» лагеренда әсир булуы турында истәлек тактасы

Бөекләр тирәсендә ышкылып алулар тарихта күп булган, булды һәм булачак. Һәрберсенә ваемсыз ышанып, чаң сукканчы бөртекләп тикшерү, ачыклау кирәк. Ырынбур өлкәсендә туып үскән, шуннан сугышка китеп фашистлар концлагерена эләккән Гобәйдулла Салиховның чормага яшерелгән дәфтәрендә, имеш, Муса Җәлил шигырьләре табылган. Салихов каһарман шагыйребез белән таныш булган, лагерьда берничә шигырен үз дәфтәренә күчереп алган, имеш.

Сорау-шик туа: берничә тел белгән, шул исәптән алман телен дә, Салихов нишләп соң әле Муса Җәлил шигырьләрен латин шрифты белән башкортчага аударып күчерә, моңа нинди мохтаҗлык булды икән? Ярый, монысы ул кадәрле үк мөһим түгел, дип карыйк. Салихов үзенең язмасында болай ди: *«...1943 елның февраль аенда Седлец (дөресе: Седльце – М.Г.) шәһәрендәге лагерьда башкисәрләр Муса Җәлилне һәм тагын бер кешене кулга алалар (фамилиясен хәтерләмим)... капка сакчылары күзәтүендә, көне буе гимнастеркадан гына тоттылар. Көн салкын иде... Сикергәләп җылынырга тырыштылар, арып, карга егылдылар».*

«Чеп-чи ялган бит бу, җәмәгать!» – дип сөрән салганчы, башта, иренмичә, чыганакларга мөрәҗәгать итик. Җәлилчеләргә гомерен багышлаган, йөзләрчә документлар тапкан, йөзләрчә шаһитлар белән очрашкан-сөйләшкән, хат алышкан, хәтта Муса Җәлил утырган төрмәләрдә дә булган хөрмәтле язучыбыз Рафаэль Мостафин язмаларына тулаем ышанырга хакыбыз бармы? Бик бар! Мин фәкать аның язмалары аша күзәтү ясарга алынам: Муса Җәлил Седльце лагеренда беркайчан да әсирлектә булмаган! Седльцеда икенче шагыйребез – Краковтан күчерелгән Абдулла Алишның аз гына вакыт яшәп алуы билгеле. 1943 елның 13 гыйнварында аны Вустрау крепостена китерәләр, шунда ул Муса Җәлил белән күрешә. Димәк, Салихов әйткән

Вустрау. «Идел-Урал» ансамбле легионерлар алдында чыгыш ясый

Абдулла Алиш (арткы рәттә, баскан) туганнары белән. 1931 ел

вакытта Муса Җәлил Вустрауда була әле, гимнастёркадан түгел, ә штатский киемнән йөри. (Аны Демблин крепостеннан монда күчерәләр.)

1943 елның 13 гыйнварында Абдулла Алишны Берлинга — «Идел-Урал» газетасына эшкә алалар, ә март аенда Муса Җәлил дә «Гомәров-Җәлил» исеменә паспорт алып, Берлинга килә, татар комитетының культура-агарту эшләре буенча җаваплы эш башкара башлый.

Шулай да... Муса Җәлилгә бер-ике көнен Седльце лагеренда үткәрергә туры килә. Берлин адвокаты Генрих Унгляубе җитәкчелегендә 1943 елның 28 мартыннан алып 15 апреленә кадәр Шәфи Алмас, Гариф Солтан, Сабит Кунафин һәм Муса Җәлил концлагерьларны өйрәнү сәяхәтенә чыгалар. Седльцеда тукталып, һәркем үзенә кирәкле өлкәне тикшерә. Муса Җәлил әдәби-музыкаль кичә оештыра, үзенең шигырьләрен укый. Бу сәяхәтнең Унгляубе тарафыннан бөртекләп язылган отчёты Алманиядәге архивта исән-имин сакланган.

Муса Җәлилне 1943 елның 12 августында Едлино лагеренда кулга алалар. Ул кәчтүм-чалбардан, күлмәк-галстуктан, башына эшләпә кигән була — һәрхәлдә, гимнастёркадан түгел! Кулга алыну белән аны Варшавага — «Тавис кошы» дигән төрмәгә алып китәләр. Аннан — Берлинга!

Шулай итеп, олы бер сорау туа: Салихов иптәш сурәтләгән карлы февраль аенда кулга алынган кеше нинди

Муса Җәлил булды микән? Аңардан күчереп алынган шигырьләр кемнеке иде микән? Әллә соң әсирләр арасында үзен Гомәров яки Муса Җәлил дип йөрүче берәр мут кеше булганмы? Бик мөмкин.

Салихов дәфтәреннән алып бастырылган шигырьләр нинди дәрәҗәдә соң? Җәлил иҗатын өйрәнүче доцент Йосыпованың «чыннан да бу шигырьләр Муса Җәлил стилендә язылган диюе иҗек саны буенча гына хөкем чыгаруга охшый.

Телебезнең кан тибешен, һәр сүзнең аһәңен, исен-төсен, бер-берсенә тәңгәл килеп үрелешен тойган иҗат кешесе өчен бу шигырьләрнең егәре Муса Җәлилгә һич тә туры килмәгәнлеге бернинди дә шик тудырмый. Хәтта «анык микән?» дигән сорау кую — үзе бер гөнаһ шикелле. Урыны белән ритмик яктан гафу ителмәслек дәрәҗәдә чатан, зәгыйфь рифмаларга корылган, эчтәлек ягыннан да бөтенләй ят лирик герой хисләре белдерелгән бу язмаларны анализларга әдәбият белгечләрен этеп кертеп җибәрмик тагын, шушы алты данә альбом шигыреннән чыга алмыйча азапланырлар...

Менә кайбер юлларны гына мисалга китерик: *«Гомерем дусты, яшьли сөйгән ярым, улларымның гүзәл анасы», «Ник югалдың инде, сөйгән дустым, тормыш таңы сызылып атканда, әткәй, әнкәй, диеп иркә күздән улларыбыз күзгә бакканда»*.

Ике улын калдырып сугышка киткән Абдулла Алиш язганмы әллә бу юлларны, дип уйлап куям. Ул җәһәттән Рафаэль Мостафин мондый фикер әйтә: «Моабит дәфтәрләре матбугатта бастырылып, бөтен дөньяга шаулаган чакта, яңа табылган һәр шигырьне Муса Җәлилнеке булырга тиеш, дип карау тенденциясе сизелә иде. Ләкин әсирлектә Җәлилдән тыш язучы һәм журналистлар Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәй, Рәхим Саттар, Әхмәт Симаев, укытучы Гайнан Кормаш һ.б. да шигырь язган. Алардан тыш, әсирлек шартларында тулып ташыган күңелләрен бушату өчен, безгә билгеле булмаган талантлы кешеләр дә шигырь язу белән шөгыльләнгән. Мәсьәлә тагын шуның белән катлаулана: Җәлил белән бергә булган шагыйрьләрнең күбесе аның иҗаты йогынтысында булган: теләсәләр-теләмәсәләр дә аңа охшатып язарга тырышканнар. Шуңа күрә шигырьләрне стиль ягыннан гына тикшерү аларның авторын төгәл итеп ачыкларга мөмкинлек бирми...»

Муса Җәлил үзенең каһарманлыгы, палач балтасы астында язылган шигырьләре белән бөтен совет халкына танылган бердәнбер шагыйрь. Андый көчле рухлы иҗат бик күп милләт вәкилләрен таң калдыра. Ул үзенең үлмәс иҗаты белән символга әверелде. Аны үз бөеклегендә таныйк, саклыйк без аны. Аннан-моннан табылган шигырьләр белән бимазаламыйк, чөнки андый язмаларга шагыйрь мохтаҗ түгел, ул аны үстерми дә, баетмый да. Әгәр инде югалган дәфтәре табылса... шунда инде үз кулы белән язылган, моңа кадәр басылмаган шигыре дөньяга чыкса... менә шундый очракта гына шау кузгатырга ярыйдыр.

Ә болай... Җәлил күләгәсенә сыенырга теләүче кәсепчеләр һаман табылып торырга мөмкин. Исем шигырьне күтәрми, ә шигырь исемне күтәрә. Моңа гыйбрәтле бер мисал китерик. Узган гасырның алтмышынчы елларында Башкортстанда яшәп, каләм тибрәтергә яраткан Фәнил Арсаев атлы кеше булган. Казанда бик тә басыласы килеп, «Совет әдәбияты» журналына туктаусыз шигырьләр юллап торган бу. Басмыйлар да басмыйлар икән. Аптырагач, ул бер туплам шигырен танылган әдип Сәйфи Кудаш исемен куеп җибәргән. Озак та үтми, мул гына урын биреп журналның күренекле битләрендә дөнья күргән бит!

«Әһә, Сәйфи Кудаш дигәч, бастырып чыгардыгызмы?!» — дип көлгән ди үзешчән каләмче. ■

МӨДӘМИЛ ӘХМӘТОВНЫҢ ЯЗМА МИРАСЫ

Ләбиб Лерон



Сүнгән көннәр һаман арта тора,
Кими бара алдагылары.
Туктатасы иде бу елларны,
Тышаулыйсы иде шуларны!
Яшисе дә гел яшисе килә! —
Яшәү ямьлегә бу бер дәлил.
Беләсеңме шуны, сизәсеңме,
Тоясыңмы икән, Мөдәмил?
Зөлфәт

Мөдәмил Әхмәтовның хатыны Венера ханым, ире вафатыннан соң күп вакыт үтмәстән, аның иҗади мирасын барлап-туплап, Мөслимнең миһербанлы, игелекле ирегете Илгиз Зәки улы Исламовның матди ярдәме белән аерым китап итеп («Кайту», тезмә һәм чәчмә әсәрләр. — Казан: «Ихлас» нәшрияты. — 2015. — 220 б.) бастырып чыгарган. Рәхмәт аларга!

Кем ул Мөдәмил Әхмәтов?

Мөдәмил Әхмәтов (1950-2014) — журналист, Мөслим матбугат үзәге җитәкчесе, җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь һәм прозаик. Шагыйрьлегенә бер дәлил:

Юллар — озын...
Ярсу белән генә
Үтеп булмас кебек үрләрне.
Түземлеген атның үрләр белә,
Ел-гомерләр сыный ирләрне!..

Галим Марсель Бакиров, Зөлфәт, Наис Гамбәр, Фоат Садриев, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Рөстәм Зарипов, Әхмәт Дусайлы, Тәлгат Нәҗмиев кебек әһле каләмнәр белән даими очрашып, аралашып яшәгән Мөдәмилнең шигырь яисә хикәя язуына бер дә гаҗәпләнәсе юк.

Менә аның якташы, киң кырлы талант иясе Мөҗәһит Әхмәтҗановка багышланган шигыреннән бер өзек:

Кем җырлады икән беренче кат,
Ниләр телгәләде икән җанын?..
Уйладымы икән,
Яшәр, диеп,
Гасырларны узып «Карурман»ы?

Кадерләде микән
Исән чакта —
Моңын откан ыру-кабиләсе?..
Каберләрне кирәк кадерләргә —
Яшәешнең изге кагыйдәсе!..

Җиде бүлек-сәхифәдән торган китапта Мөдәмил Әхмәтовның йөзгә якын шигыре белән нибары җиде кечкенә хикәясе (икесе — җитди, бишесе шаян рухта язылган) урын алган. Нибары, дидем... Мөдәмилнең язганнары әле тагы булырга тиеш. Алай дисәң, әгәр андыйлар булган булса, Венера ханым Әхмәтова аларны китапка урнаштырмыйча калмас иде. Күрәсең, язылмыйча калгандыр (ә бәлки язылган булып та, авторның үзенә ошамау сәбәпле, утка яисә чүп кәрҗиненә ыргытылгандыр?!). Бик ихтимал. Язганнары булырга тиеш, диюем дә нигезсез

Мөдәмил Әхмәтов хатыны Венера ханым белән янәшә. 1986 ел

Якташлар: сулдан уңга – Фоат Садриев, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Мөдәмил Әхмәтов һәм Марсель Бакиров

Мәшһүр шагыйрь дусты Зөлфәт янәшәсендә. 2007 ел

түгел кебек: Мөдәмил абый кайчандыр безгә — радиожурналист Нәсим Акмал белән мин бахырыгызга — үзенең эш бүлмәсендә гәпләшеп утырганда ике-өч кыйсса сөйләгән иде. Боларны (хикәя өчен менә дигән сюжетлар иде алар) яздыгызмы, дигән соравыбызга, ул зур ышаныч белән: «Язылмаган, әмма язачакмын!» — дигән иде. Ни кызганыч, Мөдәмил Әхмәтов әлеге искитмәле кыйссаларын ак кәгазь битләренә төшерергә өлгермәгән, күрәсең...

Язмышында ачысын-төчесен шактый күргән, гомерендә күпне кичергән Мөдәмил Әхмәтовның шигъри мирасына килсәк, алар арасында күңелләрне кузгатырлыклары шактый. Укыйк без ул шигырьләрне, шагыйрьне, аның җан халәтен аңларга тырышып карыйк:

Без озакка диеп килгән идек...
Капкаларны кемдер куйган ачып...
Тормыш — матур!..
Ләкин кемгә кирәк
Үлем белән яшәү бәхәсләшеп...

Мөдәмил Гыйлемҗан улы Әхмәтовны якыннары, якташлары 2014 елның 3 маенда мәңгелеккә озатты. Мирас булып аның язганнары — якты иҗаты калды...

КҮЗГӘ СЫЙМЫЙ КҮКНЕҢ ЗӘҢГӘРЛЕГЕ

Мөдәмил Әхмәтов

ДАЛА ЧАКЫРА

Ялгыз йолдызларны күзләп,
Сыкрап йөрер чакмыни?!
Тормыш — бәйге. Без — бәйгедә:
Әйдә, дуслар, ат меник!

Йөрәкләре сүрелгән, дип
Сөйләмәсен ятлар да.
Җил уласын,
Тузан тузсын —
Әйдә меник атларга!

Өзәңгеләр тутыкмасын,
Ут чыгарсын дагалар.
Карт чапкыннар юк инде, дип
Моңаймасын далалар…

Мәйдан тоткан нәселдән без —
Ник яшәргә җай гына?!
Ир-егетне кем гаепләр,
Аты үлсә бәйгедә!..

Илне иңли язгы җилләр —
Сыкрап йөрер чакмыни?!
Кемнәр бөркет нәселеннән,
Кемнәр егет — ат меник!..

САГЫНУ

Көз хушлашмый гына китеп бара,
Камылларга сарылып сагыш кала,
Күзгә сыймый күкнең зәңгәрлеге:
Тәгәри дә тама, тәгәри дә тама…

Ак болытлар — ак канатлар төсле!
Шундый тынлык…
Чиртсәң, чатнар төсле!
Керфек очындагы зәңгәр тынлык
Өзелде дә төште, өзелде дә төште…
Зәп-зәңгәр күл, башын игән камыш…
Шундый тып-тын булыр икән сагыш!
Яфрак төшкән йөргән эзләреңә —
Шундый таныш алар,
шундый таныш…

Көз хушлашмый гына китеп бара,
Каеннарга сарылып сагыш кала.
Күз яшьләрен текәп зәңгәр күккә,
Соң яралган яран гөле яна.
Иң кадерле сүзне әйтү өчен
Безгә бары мизгел җитми кала…

МОҢ ЭЗЛӘГӘН МӘЛЕМ

Әллә урладылар,
Әллә үзе китте…
Буп-буш калды сәхнә
Һәм музыка
Бетте.

Залны тетрәндерде
Әле генә, әле…
Тетрәнгән җанымның
Моң эзләгән мәле.

Тәрәзләрне бәреп,
Чыкты урамга ул…
Хәтта давылны да
Сизми калды авыл.

Моңны урладылар…
Җанда — бушлык.
Залда басып торам,
Үпкә-нәфрәтләрне
Бергә кушып… ■

ХУШЛАШЫРГА АШЫКТЫ...

Алмаз Хәмзин

Мәңге кыр казларын
озатып торгандай
Син моңсу, күзеңдә тулган ай.
Көзләрне күзләмә,
айларга карама —
Моң булып күз нурың тарала...

...Сагышлы көз айлары. Сагышны көчәйтеп җыр агыла... Нинди җыр бу? Ишетелгәне юк... Рафаэль Сәхәбиев җырлый... Болай да күңелемә салган сагыш менә-менә тулып сулкылдый башлар сыман. Күзләремдә мөлдерәмә яшь. Туктатыгыз!.. Ә ул көчәя генә...

Назлым, син еракта,
шуңамы соң зарлы,
Шулчактан ялгызрак чак бармы?!
Моңайма шул кадәр,
кайгырма, көенмә,
Ә тормыш — ялкынлы өермә!..

Әйе, тормыш — ялкынлы өермә. Кем язган бу җырның сүзләрен? Минем кебек сагышлыларны юату өченме? Хисләрен уртаклашыр кеше эзләпме, хәсрәтен уртаклашамы ул? Сөйгәнен югалтканмы?

Арада биек тау,
җиталмыйм мин сиңа,
Күңелләр моңлана, юксына...
Тик гомер диңгезен
без бергә кичәрбез,
Йомшак җил-наз булып исәрбез!

Әлеге җыр минем күңелемдә мәңгелеккә уелып калды. Бу җырның сүзләрен язган егет шагыйрь Фәннур Сафин булып чыкты. Музыкасын Рөстәм Яхин язган икән. Кайсысы бөек бу җырда? Яхинмы, Сафинмы? Әйтә алмыйм, аермыйм... Икесе дә!

Фәннур белән танышу соңрак булып чыкты. Мин аның шигырьләренә язылган күп җырларны өйрәндем:

Хушлаштың да китеп бардың,
Аерылу авыр бит!..
Күзләреңнең нурын
Йөрәгемдә саклыйм,
Тукта, дустым, сабыр ит!

Афәрин, Риф Гатауллин, син дә көен матур язгансың!

Аларның «Бир кулыңны, гүзәлем», — дигән җырын тыңлаган тамашачы да алкышларга күмә иде үземне:

Моңа кадәр, сылу, кайда булдың,
Әллә инде качып айда тордың?
Бир кулыңны, бергә китик әле,
Бер бәхетне ике итик әле!
Йолдызлардан гына төштең мәллә?
Шундый самими син, шундый садә.

Күңелләрне эретерлек шигыренә Бату Мулюков язган җырны да бик яратып җырладым мин:

Җырлар өчен җырларым бар,
Сөйләр өчен серем бар.



-2-

Ниятчәйләр иткә генә иде,
Илне-җирне җәйга салып
Барыйк дигән идем бергәләп.
Аллассызлар икән бу дексезләр,
Канны сауды, җанны алды
Кара ялган белән хыянәт.

*

(Соңгы)
Күрәчәкләр булып очык әле
Туган-үскән изге илгә,
Булмас монда сиңа-миңа рәт.
Бер гөнаһсыз изге җаныбызны,
Илсез-телсез бер корт кебек,
Ашар монда кара хыянәт!



Фәннур Сафин. Шагыйрь. 1980. Кәгазь, каләм. Эрот Зарипов рәсеме

Син генә тик аңламыйсың,
Әллә инде күңелең тар,
Әллә авыр кайгың бар?

Илһам Шакиров репертуарына кергән «Ялгыз көймә»не дә Илһамчарак итеп җырлап йөрдем әле мин:

Берни сорама, тор тын гына,
Күземә кара ярым.
Күзләрдән дә белеп була
Күңелдә ниләр барын.
Ялгыз көймә бөтерелә
Һәм чайкала диңгездә,
Зур дулкыннар күтәрелә
Күңелемдә минем дә!

Озакламый без аның белән дуслашып киттек. Ул үзенең иҗат кичәләрен уздырырга уйлап, минем аның күп җырларын башкарганымны белгәч, туган төбәге Минзәлә якларында концертлар куеп йөрдек. Заллар тамашачы белән шыгрым тулы иде. Алкышлар, чәчәкләр!.. Ул чаклар Фәннурның иң бәхетле тормыш мизгелләре булгандыр…

Еллар үтә торды… Минем телевидениедә редактор булып эшләп йөргән вакытлар. «Азат Мәргән» телевизион фильмын төшереп йөрибез. Фильмның эчтәлеген тулыландыру өчен «Хыянәт» турында җыр кирәк. Шул турыда шигырен язып бирмәс микән, дип Фәннурга мөрәҗәгать иттем. Үтенечемне озак тотмады — өч көндә язып та китерде. «Хыянәт» дигәннең исемен «Бәет» дип куйган ул. Дөресен әйтәм, эчтәлеген укыгач, күңелемне авыр хисләр биләп алды. Ничек шушы, нигездә, шигырьләре яшьлек романтикасы белән сугарылган булып, үз замандашларының күңел кичерешләре, туган җир, табигать турында лирик уйланулар рәвешендә кабул ителә торган шагыйрь менә шулай да яза алды икән?

Мин аның яшерен хәсрәтләрен күзгатканмын ахры, дип уйлап куйдым шулчакта. Фәннурның мондый шигырь язарлык тормыш яралары бар микәнни, сызлана түгелме соң шагыйрь йөрәге, ни өчен, нигә, юкка биргәнмен ахрысы мондый заказны, дип хафаландым. Хәер, үзе алды бит, киреләнмәде, ялындырмады. Күрәсең, эченә җыелган ачы моң-зарны шушы «бәет» аша булса да чагылдырасы, әйтеп калдырасы, белдерәсе килгәндер…

Шуннан соң озак яши алмады Фәннур, ялгыз яшәгән фатирында кинәт вафат булды.

Менә аның «Бәет»е — беркайда да басылмаган, үз куллары белән миңа тапшырган шагыйрь Фәннур кульязмасы.

БӘЕТ

Туган ягын, ярын яратканнар! —
Бәхетлеләр, бәхетсезләр!
Сөйлим сезгә бүген шул хакта:
Әрсез мәкер йөри тирәгездә,
Ул хыянәт булып сезне
Йоттырмакчы канлы учактан!

Кем күрмәгән аны — авырлыкны,
Кем кайгылар кичермәгән.
Онытыла алар, йөрәкләрдә
Кара канлы яра булып
Тик хыянәт кала, дусларым.

Изгелекне яклап утка кердем,
Яндым-көйдем, исән калдым,
Шул буламы инде җинаять?!
Ялгыз башы урман иңләмәгәч,
Җаны-тәне хак булмагач,
Утка сала икән хыянәт.

Яратмаган эшең, кешең булса,
Астыртын ут якма җиргә,
Үз сүзеңне бөтен миргә әйт.
Дөреслекнең, юкса, канын эчә,
Базлар казый, җанын ашый
Кара эчле вәхши хыянәт.

Ниятькәйләр ипле генә иде,
Илне-җирне җайга салып
Барыйк, дигән идем бергәләп.
Алласызлар икән бу денсезләр,
Канны сауды, җанны алды
Кара ялган белән хыянәт.

Күгәрченнәр булып очыйк әле
Туган-үскән изге илгә.
Булмас монда сиңа-миңа рәт —
Бер гөнаһсыз изге җаныбызны,
Илсез-телсез бер корт кебек
Ашар монда кара хыянәт! ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

ЗӘБИРИ (Чистапули) (Зәбиров Хәбибрахман Габделвәли улы, 1880 (1881?)-1942), репрессияләнгән һәм вафатыннан соң акланган күренекле татар мәгърифәтчесе, язучы, педагог, дәреслекләр авторы, матбагачы. 1908дә Оренбургтан Казанга күченгән Зәбири Тукай хезмәттәшлек иткән «Тәрбия» журналының фактик мөхәррире була, 1908-1916 елларда «Сабах» нәшриятында, 1916-1921 еллар аралыгында И.Н.Харитонов типографиясендә хезмәт итә, аннан соңгы эшчәнлеге дә төрле дәүләт нәшриятларында бара. Габдулла Тукай апасы Газизә Госмановага 1908 елның 7 мартында язган хатында Зәбиринe иптәше сыйфатында атап уза. Аларның якыннан аралашуы хакында истәлекләрдә дә саклана. Мәҗит Гафуриның Петербургта чыгучы «Ил» газетасында басылган «Тукай Уфада» язмасында (1914) шундый юллар бар: «Тукайның яткан җире гадәттән тыш эссе, бик тиз тәэсир итә торган сурәттә бөркү иде. Бүлмәдә байтак утырдык. Кергән-киткән булмады. Бары Х.Зәбири бәгъзән эштән бушаган вакытында кереп, төрле сүзләр әйтеп, көлдереп чыга иде. Тукай бәгъзән берәр генә мисрагълы шигырь яки Коръәннән берәр аять укып куя иде». Гафури мәкаләсе белән янәшәдә Зәбиринең аныкына аваздаш әчтәлектәге «Габдулла әфәнденең Уфадан Петербургка баруы» исемле истәлеге дөнья күрә.

Реалистик иҗат методларына өстенлек биргән Тукай Зәбири иҗатын күзәтеп барган, дип уйларга кирәк. Үз чорында аның мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган «Гыйлем вә җәһел, яхуд Нури әфәнде илә Мөхәммәтҗан карт» исемле хикәясе, унга якын юмористик мәзәге, «Төшенү, яки Указ бәласе» исемле комедиясе әдәби җәмәгатьчелектә яхшы билгеле була. Бу әсәрләрнең язылу алымнары белән Тукайның иҗат итү ысуллары арасында охшашлык ярылып ята. Зәбиринең телгә алынган комедиясе «Сәйяр» труппасы тарафыннан Тукай исән чакта, 1907 елда куела, басылу вакыты һәм урыны исә 1906 ел, Җаек каласында нәшер ителүче «Әл-гаср әл-җәдид» журналы. Зәбири һәм Тукай дәреслекләр төзегәндә үзара киңәшләшеп, бер карашта торып эш йөрткәннәр. Зәбири, белгәнебезчә — «Мәктәп балаларына юлдаш, яки Рәсемле әлифба» (1907) исемле беренче татар әлифбасы, башлангыч мәктәп өчен язылган физика, этика, тарих дәреслекләре авторы.

Р.Ф. Харрасова

Әсәр.: Зәбири Х. Габдулла әфәнденең Уфадан Петербургка баруы // Ил. 1914. 2 апрель саны; Зәбири Х. Тукай турында истәлекләр // СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалының кулъязмалар фонды, п. № 11, Б.32-33.

Әдәб.: Габдулла Тукай. Хатлар. Апасы Газизә Госмановага // Әсәрләр. Том 5. Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902-1913). К. 1986. Б.84; Гафури М. Габдулла Тукай Уфада // Ил. 1914. 2 апрель саны; Ибраһимова Ф.И., Милли укымышлыларыбызның берсе Хәбибрахман Зәбири // Фәнни гомерем мизгелләре: мәкаләләр, истәлекләр, иҗат портретлары. Казан. 2012. Б.36; Исламов Р. Бөек шагыйрьнең тарихи сәфәрләре эзеннән // Кызыл Таң, 2014 ел, 9 июль.

САЛИХ АБЫЙ СӘЙДӘШЕВ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Нурихан Фәттах

Шушы көннәрдә Башкортстаннан Нуриханның апасының кызлары килеп төште. Икесе дә пенсия яшендә. Казанны, аның тарихи урыннарын күрәсе килә, диделәр. Ярый торган эш. Беренче көнне экскурсия автобусы белән Болгарга барып кайттылар.

Арып-талып, ләкин бик канәгать булып кайтканнар. Икенче көнгә шактый тыгыз программа төзедек. Иртән иртүк концертлар залына киттек. Анда хәйрия концерты иде. Мин белгәнемне сөйлим, күрсәтәм, бераз горурланып, «Салих Сәйдәшев исемендәге» дип сөйлим. Урамда барганда сорый берсе:

– Руфина апа, безнең картыйның исеме (минем каенанам була инде) ничек иде? – ди.

– Салиха, – дидем.

– Онытмасам ярар иде, хәер биргәндә сорыйлар бит: исеме, кем кызы булуы...

– Онытсаң, искә төшерүе бик җиңел бит, Салих Сәйдәшевне генә истә тотасы, – дим.

– Руфина апа, иртәдән бирле Сәйдәшев тә Сәйдәшев дисез, кем соң ул Сәйдәшев? – димәсенме.

Авып китә яздым.

– Ничек, ишеткәнегез дә юкмыни? – дим.

– Ю-у-ук, – диләр.

Утырыплар еларсың. С.Сәйдәшев музеена кердек. Сөйләделәр, аңлаттылар. Бераз музыкасы да ишетелде...

Ярар, күңелсез нәрсәләрне бер читкә куеп, бөек композитор Салих Сәйдәшевнең тууына 115 ел тулуын истә тотып, Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахның кечкенә истәлегенә тукталыйк. Монысы да үзенә күрә тарих бит...

Руфина Фәттахова

Моннан утыз еллар чамасы элек, Казан университетын тәмамлагач, мин Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә эшли башладым. Шунда беренче мәртәбә мин Салих абый Сәйдәшевне күрдем.

Бу болай булды. Ул вакытларда берәр төрле эш белән нәшриятка язучылар, композиторлар килә торган иде. Беркөнне безгә Салих абый Сәйдәшев килде. Аның янында кемнәрдер бар иде. Ул «кемнәрдер» кемнәр булгандыр — хәзер инде хәтерләмим. Ләкин Салих абыйны мин хәтерлим. Бик нык хәтерлим.

Мин эшләп утырган бүлмәдә тагын бер-ике кеше бар иде. Керүчеләр безнең һәркайсыбыз белән исәнләшеп

чыктылар. Шунда Салих абый минем белән дә исәнләште. Зурлап, кул биреп исәнләште. Мин каушап калдым, хәтта кызардым да бугай әле. Мин кем инде аңа? Исемсез, дәрәҗәсез, күренексез бер яшь редактор. Алар — зурлар, олылар. Яшьләре буенча да, исемнәре-дәрәҗәләре буенча да. Мин көне буена шушы очрашу-күрешү турында уйлап йөрдем.

Икенче мәртәбә, икенче бер килүендә Салих абый тагын минем белән кул биреп исәнләште. Монысында да ул беренче булып үзе кул бирде. Мин тагын каушадым, уңайсызландым. Ул чакта мин үземне мондый зур хөрмәткә, әлбәттә, лаек түгел, дип исәпләдем.

Салих абый исән чакта мин аның



белән якыннан аралашу, дуслашу бәхетенә ирешә алмадым. Әйтелгәнчә, безнең яшь аралары да зур иде, эшебез, профессиябез дә төрлерәк иде. Аннан соң озакламый ул вафат булды.

Ләкин аның белән беренче очрашу-күрешү минем күз алдында мәңгегә уелып калды. Мин әле дә аның кулын сузып, күрешеп торучы итеп, җанлы итеп күргән кебек булам. Мин әле дә аның зәңгәр, аның ягымлы — эчкерсез карашын һәм йомшак кул җылысын тойган кебек булам.

Аның дәртле, көчле музыкасын тыңлаганда келт итеп күңелгә менә шушы очрашу килә. Кайчандыр Салих Сәйдәшев тудырган сихри моң дулкыннары кече күңелле, кешелекле һәм бөек рухлы даһи композиторның кайнар йөрәк тибеше бирелә. Шулвакыт мин үземдә иҗат дәрте туганлыгын аңлыйм. Шулвакыт минем дә бөек талант тудырган, үстергән халкыма Салих абый Сәйдәшев кебек үк тугрылыклы хезмәт итәсем килә.

19 ноябрь, 1980 ел

СӘЕТ БЕЛӘН БИКӘ

Рәдиф Сәгъди

**Миңа аларны күреп, аралашып калырга насыйп булды.
Күчмә театрда (хәзерге К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында) яшь артист саналган чагым. Гармунда уйный белүемне сәбәп итеп, драматург Сәет ага Шәкүровның «Саф күңелгә тап төшми» драмасындагы Мулланур ролен миңа тапшырдылар.**

Спектакльнең премьерасына Сәет ага хатыны Бикә ханым белән бергә килде. Икесе дә Бөек Ватан сугышында утны-суны кичкән, бик күп орден-медальгә лаек булган шәхес. Сәет ага сабыр холыклы иде. Бикә апа тынгысыз җан булып исемдә калды.

Сәет Габделхәй улы Шәкүров 1917 елның 14 декабрендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында дөньяга килгән. Бикә апа исә Мамадыш районының Ишки авылыннан. Ул (Шакирова Бикә Шакир кызы) 1923 елның 15 декабрендә туган.

1934-1938 елларда Сәет Шәкүров театр техникумында укый. Аны уңышлы тәмамлагач, Татар дәүләт академия театрының колхоз-совхоз филиалында һәм бераз соңрак Минзәлә колхоз-совхоз театрында артист булып эшли. Сугыш вакытында, 1942 елда, ул Ленинград хәрби ветеринария училищесында укый һәм аны тәмамлауга, фронтның алгы сызыгына җибәрелә. 1943-1944 елларда Иранда 15 нче кавалеристлар корпусында хезмәт итә. Ә инде 1944 елдан ул 3 нче Белоруссия фронтының 184 нче дивизиясе сугышчысы булып, олы җиңүгә хәтле гел алгы сызыкта була, Кенисбергны штурмлаганда бик каты яралана, контузия ала. Германия капитуляция ясагач, Сәет Шәкүров Көнчыгышта Япониягә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, шунда янә каты яралана. Сугышчан батырлыклары өчен бихисап орден һәм медаль белән бүләкләнә. 1946 елда гына ул туган ягына кайту бәхетенә ирешә.

Сәет абый белән Бикә апаны язмыш

Рәсемдә (сулдан уңга): икенче – Сәет Шәкүров, Бикә Шәкүрова, Һ.Солтанов һ.б. 1989 ел

гел бер тирәдә йөртә. Бикә Шакирова Казан театр училищесының өченче курсын тәмамлагач, заводка эшкә урнаша. Сугыш башлануга, үзе теләп, фронтка китә. Ничәмә-ничә совет солдатын ут эченнән алып чыгарга туры килә аңа. 27 солдатны чын мәгънәсендә үлемнән йолып калганы өчен Бикә Шакирова Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Колхоз-совхоз театрында эшләгән чакта Бикә үзенең булачак ире Сәетне очрата. Аларның гаилә тормышы күпләрнеке шикелле башта шома гына бармый. Бикә апаның тырышлыгы, үҗәтлеге, таләпчәнлеге, иренә карата булган зур ышанычы аркасында Сәет ага акрынлап савыга, тернәкләнә. Тора-бара ул әдәби әсәрләр иҗат итә башлый. Аның һәр язганын Бикә апа машинкада бастыра. Ике кыз бала тәрбияләргә дә өлгерә уңган хатын.

Сәет Шәкүровның бер-бер артлы «Зөһрә йолдыз», «Уракчы кыз», «Соры елан», «Туган туфрак», «Тол хатыннар» дигән пьесалары басыла, сәхнәләштерелә.

Язмамның алгы өлешендә «Саф күңелгә тап төшми» спектакле турында әйтеп узган идем…

Премьера тәмам. Халык басып кул чаба. Тамашачының шулай ихлас яратып алкышлавы күңелләргә сөенеч, дәрт өсти. Безнең белән бергә Сәет ага да, Бикә апа да бәхетле мизгелләр кичерә… Сәет ага спектакльдә катнашкан барлык артистларга кызыл тышлы китабын бүләк итә.

Миңа тапшырылган китапка, култамгасын салып, Сәет ага болай дип язган иде: «Мулланурны шәп уйнадың, энекәш, гармунда да булдырасың икән, иҗатың озын гомерле булсын!»

«Саф күңелгә тап төшми» спектакле белән без Советлар Союзының татарлар яшәгән бөтен төбәкләрендә дә булдык шикелле. Сәет ага Шәкүровның патриотик рухта язылган бу әсәре сугыш чорындагы кешеләр язмышын чагылдырып елатты да, көлдертте дә. Ихлас һәм тыйнак уенызбыз белән ике фронтовикны куандырып яшәтә алганыбыз өчен мин бүген дә үземне бик бәхетле хис итәм, алар белән аралашып яшәгән чорны күңелемдә кадерле ядкяр итеп саклыйм. ■

Татарстанның X еллыгы исемендәге мәдәният сараеның татар хоры. Җитәкчесе – Габдулла Халитов. 1945 ел

МОҢ ИЯСЕ

Камил Саттаров,
режиссёр, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Татар халкының беренче профессиональ баянчысы, халкыбызның музыка сәнгате үсешенә искиткеч зур хезмәт куйган Габдулла Гәрәй улы Халитовка 2015 елның гыйнвар аенда 100 яшь тулган булыр иде.

Габдулла Гәрәй улы Халитов 1915 елның 15 гыйнварында кустарь гаиләсендә туа. Аны җырлап туган, дип әйтергә була. Әнисенең истәлекләренә караганда, ул бишектә чакта ук җырга охшаган моңнар чыгарып ята. Габдулла кечкенәдән кулына гармун ала һәм аның серләренә бик тиз төшенә. Моңа беренче сәбәп — гаиләсенең музыкага, җырга һәвәс булуы булса, икенчедән, 1917 елларда ук үзешчән сәнгать өлкәсендә бик актив эшләр башкарган туганы Сафа Ситковский була. 1919-1920 елларда порох заводында үткәрелә торган митинглар, җыелышлар үзешчән сәнгатьтә катнашучыларның концертлары һәм спектакльләре белән уздырыла, шуңа күрә алар бәйрәм төсен ала. Бу чараларны уздыруда Сафа Ситковский, Кәрим Хәйруллин, Гәрәй Хәсәновлар зур роль уйнаган. 1920 елның февралендә оештырылган концертларның берсендә 6 яшьлек

Габдулла Халитовның да катнашуы билгеле.

Казан шәһәре Елга аръягы районы Эшчеләр мәдәният йортында концерт бара. Үзешчән сәнгать әгъзалары таза гәүдәле егетләр, сылу кызлар — Шаһит Мансуров, Гариф Бохараев, Кәрим Хәйруллин, Җамали Саинов, Мәрфуга Гайнуллина һәм башка талантлар җыр-бию, сатира-юмор номерларын башкара.

Концертны Сафа Ситковский алып бара. Чираттагы концертларның берсендә ул болай дип белдерә:

— Хөрмәтле тамашачылар! Хәзер сезнең алга безнең иң «өлкән» уенчыбыз чыга. Карагыз аны, күлә күрмәгез, аның күңеле бик тә нечкә — елап җибәрүе бар.

«Өлкән» уенчы сәхнәгә чыга, ләкин тамашачыларның конферансье сүзен тотарга көчләре җитми: дәррәү көлеп җибәрәләр һәм алкышлар яудыралар. Нечкә күңелле «өлкән» уенчы исә боларның берсенә дә игътибар итми — тальян гармунында «Галиябану», «Алсу» көйләрен сыздыра гына. Зал алкышларга күмелә. Шулай итеп Габдулла Халитовның беренче чыгышы уңышлы үтә.

Халык арасында Габдулладан башка да гармунчылар җитәрлек була. Ләкин Габдулла Халитов алар каршында үзенә генә хас алымнар белән өстенлек яулый. Аның кулында саратов гармуны да чыңлый, төймәлесе дә, төймәсезе дә, бакалысы да, бакасызы да аның кулында биеп кенә тора. Яшь Габдулланың тынгысыз йөрәген кулында булган гармун телләре генә баса алмый. Ул туктаусыз эзләнә, кыллы оркестр чыгышларын тыңлый. Музыкаль спектакльләрне карап, шунда уйнаган көйләрне үзе дә күбесен югары дәрәҗәдә уйнарга өйрәнә.

Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарёв, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи кебек халкыбызның атаклы музыка осталары белән таныша һәм аларның әсәрләрен күңелдән ятлый. Бу композиторларның көйләрен чәчми-түкми, барлык үзенчәлекләре белән башкара алуга ирешә.

Чыннан да «Наёмщик» музыкаль спектакленең кереш музыкасы аның башкаруында оркестрның уйнавын хәтерләтә. Ләкин һаман да эзләнү тукталмый, күңелгә барыбер нәрсәдер җитми кебек. Ул гармун осталары белән киңәшергә була. Аңа оста мастерлар: «Син баян белән дуслаш», — диләр. Шулай итеп Габдулла Халитов кулына баян ала. Менә инде бу башка эш. Кайбер теләкләрне моның белән үтәп булырдай күренә. Бала чагында уйнаган орган тавышлары Габдулла колагына сеңеп калган, ул баянны һәм аның тавышын шул органга охшатып куйгалый. Ләкин ишетелгән көйләрне һәм искиткеч моңнарны үзәкләргә үтәрдәй сәләтле башкаруда нәрсәдер тоткарлык бирә.

Озакламый моның сере ачыла. Кулны бәйләп торган нәрсә — Габдуллада музыка грамотасы булмавы икән. Колак белән генә ишетеп, күңелдән уйнау гына җитми икән шул.

1940 елда үткәрелгән үзешчән талантлар смотрында беренчелекне яулый. Аңа Татарстан филармониясенең Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшкә керергә тәкъдим ясыйлар. Нәтиҗәдә Габдулла Халитовка башлангыч музыка белеме алырга беренче буларак мөмкинлек ачыла. Берничә ел эчендә ул музыка белеме алып татар халкының беренче профессиональ баянчысы булып танылa. Габдулла Халитов үзе генә оста баянчы булып калмый. Үзенә генә хас булган методика, музыка осталыгына башкаларны да өйрәтә башлый. 1945 елда аның кул астында Мөхтәр Әхмәдиев, 1947 елда Фәйзи Садыйков, 1949 елда Рифгать Лотфиннар өйрәнеп, оста уйнаучы баянчылар рәтенә керәләр. Республика күчмә театрының баянчысы Сафьян Ибраһимов, Казан шәһәре Пионерлар сараеның музыканты Тәлгать Вәлиев тә Габдулла абыйдан баянда уйнау

Габдулла Халитовка (уңнан икенче) – 60 яшь. 1975 елның гыйнвары

серләренә өйрәнеп, тормышка путёвка алалар. Ул елларда күп кенә клуб, кызыл почмак, мәдәният сарайларында аның өйрәнчекләре эшләде. Габдулла абый дистәләрчә егетләрне, кызларны, гомумән музыка белеменә сусаучыларны зур сабырлык белән музыка дөньясына алып керде.

Татарстанның төрле районнарыннан, шәһәрләреннән аңа киңәш сорап хатлар яздылар, канәгатьләндерерлек җаваплар да алалар иде.

Габдулла Халитовның театрларда куелган спектакльләрнең музыкаль бизәлешен үстерү өлкәсендә хезмәтләре дә мактауга лаек. Казан шәһәренең Татарстанның X еллыгы, М.С.Урицкий исемендәге мәдәният сарайларының Халык театрлары тарафыннан сәхнәләштерелгән спектакльләренә иң кимендә 30 ел буенча музыка язды, көйләрне эшкәртте. Спектакльләрнең музыкаль бизәлешен үстерүдә һәм камилләштерүдә аның роле гаять зур булды. Мәсәлән, ул Гамир Насрыйның «Туган авылым», Юныс Әминевнең «Язылмаган законнар», «Тамырлар», Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры», Чыңгыз Айтматовның «Талчыбыктай гүзәлем», Касыйм Шамилнең «Тар тыкрыкта», Шәриф Хөсәеновның «Чулпан», Куандык Шангыйтбаевның «Кияүләр», Николай Анкиловның «Солдат хатыны», Әнгам Атнабаевның «Ана хөкеме» һәм башка бик күп спектакльләргә тирән эчтәлекле, спектакльләрнең төп фикерләрен ачарга ярдәм иткән һәм тамашачы бик яратып кабул итә торган музыкаль бизәлешләр иҗат итте.

Тагын шуны искәртеп китәргә кирәк, Габдулла абый спетакльләргә музыкаль бизәлеш өстендә генә эшләү түгел, Халык театрлары сәхнәләштергән спектакльләрдә уйнарга ярата иде. Ул үзенең гаилә әгъзаларына да «театр җене»н йоктырды. Кайбер спектакльләрдә алар тормыш иптәше Мәрьям апа, малайлары Азат, Марат белән уйнаган чаклары да була иде. Бу гаилә ансамбле матур-матур образлар

«Ана хөкеме» спектакленнән соң. Казан телевидениесендә. 1975 ел

иҗат итте, дипломнар һәм мактау грамоталары белән бүләкләнде.

1957 елда Татарстанның Х еллыгы исемендәге мәдәният сараеның үзешчән коллективы Мәскәү шәһәрендә үткәрелгән әдәбият һәм сәнгать декадасында прфессиональ сәнгать осталары белән беррәттән катнашты. Ул анда Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен күрсәтергә тиеш иде. Менә бу декада спектакленә әзерлек барган чорларда Габдулла Халитовның хезмәте аеруча зур булды. Күп көч кую әрәмгә китмәде. Мәдәният сараеның татар театр коллективы тарафыннан сәхнәләштерелгән «Башмагым» спектакле Мәскәүдә уздырылган декадада зур бәягә лаек булды.

Габдулла Халитов Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә профессиональ музыкант булып эшләү вакытында да үзешчән сәнгать коллективларыннан ераклашмады, алар белән эшләү өчен вакытын табарга тырышты, хор коллективларын яңа әсәрләр белән баетты, аларга үсәр өчен профессиональ юнәлеш юлларын күрсәтеп бирде. Мәсәлән, Габдулла Халитов җитәкләгән Татарстанның Х еллыгы исемендәге мәдәният сараеның татар хоры 1945 елда илебез буенча үткәрелә торган Бөтенсоюз конкурсына Мәскәү шәһәренә барып беренче урынны яулап кайтты.

Габдулла Гәрәй улы Халитов табигатьтән бирелгән күпкырлы талант иясе иде. Атаклы композитор Салих Сәйдәшев үзе язган яңа әсәрләрен иң беренче булып Габдулла Халитовка уйнарга бирә, игътибар белән аны тыңлаганнан соң, язган әсәрләренә төзәтмәләр кертә. Халкыбызның танылган композиторлары белән дуслашу аның үзенә дә җыр көйләре язып карарга дәрт бирә. Ул язган җырларны профессиональ һәм үзешчән җырчылар яратып башкарды. Габдулла абый белән 30 елдан артык бергә эшләү насыйп булды. Ул тыйнак, белемле, тәрбияле, ярдәмчел, бик тугры дус һәм бик яхшы остаз булып күңелемдә калды.

Кеше китә, ә аның зур хезмәте, талант җимешләре кала. ■

АЧ СЕРЕҢНЕ, ИЛАҺИЯТ!..

Рашат Низами

Әгәр Аллаһ булмаса, аны уйлап табарга кирәгер иде.
Вольтер

Коръәндә сүзнең килеп чыгышы турындагы сүрә яки фикерләрне очратканым булмады минем. Гәрчә «Әнгам» (терлек) сүрәсе, «Тәүбә» сүрәсе, «Нух» сүрәсе, хәтта «Нәмел» (кырмыска) сүрәсе һәм башкалар – барлыгы 114 сүрә бар...

Библия (Инҗил) исә: «Иң әүвәле сүз булган...» — дип аңлата. Бу җөмлә мине тәмам әсир итте. Чөнки ул минем «Галәмдә Сүз планетасы булган» дигән фаразыма шактый туры килә. Ә инде җөмләнең дәвамын укыгач, күңелдә күп кенә сораулар, икеләнү-шикләнүләр туды. Әйе, «Бу сүз — Аллаһ», диелгән иде аның дәвамы.

Мин гомер буе сүзләр мириадасының эволюцион яралышын исбатларга омтылып яшәдем ләбаса! Юк, минем һич кенә дә диннәргә, Аллаһка тел-теш тидерергә уйлаганым булмады. Сүзгә, аның килеп чыгышына карата үз фикерем оешкан икән, бу хакта язып чыгарга да, шәт, хакым бардыр.

Диннәрнең начары юк (тәре яуларын искә алмаганда). Безнең ислам да, башка традицион диннәр кебек үк, элек-электән кешеләргә диндарлык рухын сеңдерә һәм якыннарга булган хөрмәтнең, әхлакның мәңгелек кыйммәтләрен ирештерә. Әлеге кыйммәтләр төрле милләтләр һәм башка халык вәкилләре белән уртак тел табарга, бер-берсен аңларга ярдәм иткән.

Үзебезнең Коръәнгә, аның сүрә һәм аятьләренә игътибар итик әле. Сез анда бер-бер начарлык яисә тәкъвадан тайпылу сүзләре табарсыз микән?.. Киресенчә, Коръәннең барлык битләре гуманизм һәм яхшылык, яктылык нурлары белән сугарылган. Ислам дине безгә мөселман өммәтендәгеләрнең күңеленә фәкать яхшылык орлыклары чәчәр өчен дөньяга килгән. Аерым алганда, ул безне гадел һәм шәфкатьле булырга, урлашмаска, көнләшмәскә, гайбәт сөйләмәскә, байлыкка табынмаска, кешеләрне һәм якыннарыңны түбәнсетмәскә, хәмер эчмәскә, күңел сафлыгына, тагын-тагын әнә шундый бик күп уңай сыйфатларга ия булырга өнди һәм чакыра.

Англиянең Бирмингем китапханәсендә табылган «Коръән» битләре. Чама белән 568-645 нче елларда (ислам барлыкка килгәндә) язылган, дип фаразлана

Шуңа күрә дә сакалбай Маркснының: «Дин — халык өчен әфьюн ул», — дигән сүзләре белән һичничек килешеп булмый. Бу — хата фикер. Хәтерлим: без мәктәптә укыганда коридорның бер почмагындагы плакатка шушы җөмлә эре хәрефләр белән язып куелган иде. Без ул чакта бу сүзләрнең асыл мәгънәсенә төшенерлек дәрәҗәдә түгел идек, билгеле.

Инде алдагы фикер сөрешен дәвам итсәк, «Сүзме беренче булган, әллә Аллаһмы?» дигән сорауның тууы бик табигый.

Бу уңайдан үзеннән-үзе «тавыкмы, әллә йомыркамы беренче туган?» дигән теге яманаты чыккан гыйбарә искә төшә. Дөньяда мәңгелек бәхәс бара, әмма... әлеге четерекле сораугa ни галимнәрдән, ни динчеләрдән берәүнең дә җавап бирә алганы юк әле.

Аллаһка ышану яки ышанмау бик борынгыдан, элек-электән килә. Динчеләр катгыян, догма рәвешендә Аллаһ бар, дип аңлата. Иллюзионистларның, фокусчыларның, хәтта вулканнарның да серенә төшенеп була. Ә менә кешелек аңында могҗиза рәвешендә яшәп килгән Аллаһның серенә төшенү һич мөмкин түгелдер. Чөнки дин тәгълиматы аңлатуынча, ул кеше кыяфәтендә түгел, аны күрергә бернинди күзнең көче-колачы җитмәс, ул абсолют яшәешкә ия, шунлыктан һәрдаим бар, булачактыр...

Бабам Низаметдин авылыбыз мулласы иде. Әбием Гайшәбикә, абыстай булмаса да, дини китапларны үзендә саклаган һәм укыган, дип уйлыйм. Аның болай дип әйткәннәре хәтеремдә: «Бу дөньядагы барлык нәрсәләрне Ходай Тәгалә яраткан. Ходай үзе уңда да, сулда да түгел, аста да, өстә дә түгел, ул тирә-юньгә, һәр тарафка бөртекләп, күзгә күренмәслек булып чәчелгән...»

(Хәзер уйлыйм: авылда яшәп ятса да, минем әби үзенә күрә бер философ булган ич!)

Бөек акыл ияләреннән Әфләтүн, Сократ, Әбүгалисина, Ньютон, Гегель Аллаһның барлыгына ышанганнар — язылган-әйткән уй-фикерләре шуны раслый. Ләкин фантаст язучы Адлер Тимергалин аңлатканча, «галимнәрнең фәнни тикшеренүләре аларның иманы һәм ышануларыннан аерым яши», ягъни фәнни шөгыльләрендә дин йогынтысы чагылмый...

Материалистлар исә Аллаһның барлыгын танымый. «Дөньяның башы һәм ахыры юк», дип үзләренең гипотеза һәм фаразларын алга сөрәләр. Аларның үз аршыны. Фән «дөньяның Аллаһ тарафыннан яратылуын» кабул итәргә теләми. Кыскасы, ике якның ызгышларсыз, тын гына барган көрәше-тартышы бүгенгәчә дәвам итә.

Аллаһка ышану яки ышанмау һәркемнең үзеннән, шәхси карашыннан тора, диярлек. Мохитнең, тәрбиянең һәм социаль-иҗтимагый фикерләр ташкынының йогынтысы да юк түгел. Совет заманында Ишмөхәммәтов кебек уртакул һәм өстәгеләр җырын җырлаучы галимнәр тырышып-тырышып Тукайдан атеист ясарга керештеләр... Үзгәртеп кору җилләре исә башлагач кына «бәләкәй Апуш»ның тыелган күп кенә шигырьләренә юл ачылды:

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллаһка!

Шагыйрьләрнең дә төрлесе бар. Илһамланудан үзен күккә чөеп, үзенең гайрәтен күрсәтергә теләптер, «Мин» дигән шигырендә Сәгыйть Рәмиев әнә нинди дәһри юлларга хәтле «барып» җитә:

...«Мин!» дидисәм,
Миңа зур бер көч керә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә!

Мәҗит Гафури үзенең бер шигырендә «Юктырсың ла, Алла!» дип аның барлыгын шик астына алмакчы була. Эчтәлек белән тулаем танышканнан соң аңлашыла: әдипнең канкойгыч сугышларга, тормыштагы гаделсезлекләргә кискен протест белдерүе бу...

Тагын бер гаҗәп мисал — буддачылар, гомумән, Аллаһны танымый икән!

Берничә ел элек дөньякүләм танылган язучы һәм философ Чыңгыз Айтматовның Норвегиядә язылган «Таулар авышканда» («Когда падают горы») дигән романын укып чыккан идем. Андагы баш герой, журналист Арсен Саман үзенең бер мәкаләсендә менә ниләр яза. Мәгънәсе бозылмасын, төгәл бирелсен дип, аны оригинал телендә бирәм: «Слово выпасает Бога на небесах, Слово доит молоко Вселенной и кормит нас тем молоком из рода в род, из века в век. И потому за пределами Слова нет ни Бога, ни Вселенной и нет в мире силы, превосходящей силу Слова, и нет в мире пламени, превосходящего жаром пламя и мощь Слова».

Мин бу сүзләрне сокланып, көнләшеп, гаҗәпләнеп һәм шатланып укыдым! Көнләшеп дигәнем — «бу кадәр дә колачлы,

образлы, фәлсәфи тирәнлек, нәфис тел белән яза алыр идем микән?» сорауга бәйле рәвештә, билгеле. Шатланып дигәнем — биредәге төп фикер, әлеге дә баягы, минем «Галәмдә Сүз планетасы булган» дигән фаразыма тәңгәл килә диярлек. Мактану дип кабул итмәсәгез иде: әмма татар канлы өлкән әдипнең әлеге фикере (теория дияргә дә була) татар канлы оныгы фикере белән мәгънәсе ягыннан якынча туры килә икән — ничек шатланмыйсың, ди! Моны үзеңнең татар булуың белән ихластан горурлану дип тә аңларга кирәк.

Журналист Арсен мәкаләсеннән өзек, дидек. Ә дөресрәге, Айтматов үзенең бу персонажын өлешчә резонёр сыйфатында файдаланган. Ягъни роман авторы үз фикерләрен, әйтергә теләгән сүзләрен укучыга аның аша җиткерә... Әдәбият тарихында моның мисалларын күпләп табарга мөмкин. Бу — отышлы алым. Әгәр персонаж аша түгел, автор үз теле белән әйтеп-сөйләп бирсә, әлеге сүзләрнең асыл мәгънәсе ничектер бүтәнчәрәк кабул ителер иде.

«Буддачылар, гомумән, Аллаһны танымый...»

Минем үземә студент чаклардан ук инде пантеистлар тәгълиматы якын. Алар өчен барча табигать — үзе Аллаһ. Аларның принцибы буенча, «дөньяда бар булган бөтен нәрсә — Аллаһ үзе». Димәк, Җир, Кояш, Галәм — могҗизага тиң илаһи күренеш, ә галиҗәнап Вакыт өчен — кичә, бүген, иртәгә дигән төшенчәләр юк...

Дин тәгълиматы өйрәткәнчә, әгәр Аллаһ бөтенесен эшли ала икән, нигә ул сугыш һәм кан коюларга юл куя, кешеләргә — үзенең газиз балаларына Җир тетрәүләр, су басулар, җимергеч өермәләр юллый?.. Бу сорауларга төпле җавап бирүче әүлия заты бар икән, күрсәтегез миңа ул кешене...

Язмыш, тәкъдир, ләүхелмәхфүз тактасы, дибез. Бу серле-тылсымлы тактага очраклы (!) хәлләр дә теркәләме? Әгәр чынлап та бар икән, ләүхелмәхфүз тактасын кирәк кадәренчә гуманистик рухта язып-үзгәртеп булмый микән? Бик текә, четерекле сораулар. Җавапларын шәхсән үземнең табып бетергәнем юк әле... ■

Кызыл Байрак авылы

Кызыл Байрак авылы (Югары Ослан) район үзәгеннән 35 км көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буенда, Идел елгасының уң ягында урнашкан.

Авылга 1920 елларда нигез салына. 1926 елда — 120, 1943 елда — 203, 1958 елда — 330, 1970 елда — 276, 1979 елда — 220, 1989 елда — 170, 2000 елда — 144, 2002 елда 120 кеше яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. Авылда мәчет, башлангыч мәктәп, китапханә һәм клуб бар. Кызыл Байракка су юлы аша да барып була. Авылда ел саен август аенда мәшһүребез С.Сәйдәшевкә багышланган әдәби-музыкаль чара уза.

1920-40 елларда биредә (Ш.Әхмәров йортында) Салих Сәйдәшев яши (җәйге чорда). Шиһап Әхмәров (1882-1966, педагог, журналист, нәшир) өендә Шәриф Камал, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Галимҗан Ибраһимов, Мөхетдин Корбангалиев кебек күренекле шәхесләребезнең дә яшәп алганлыгы мәгълүм.



Яңа мәчет

1990 елда Татарстан хөкүмәте карары белән Кызыл Байрак авылында С.Сәйдәшевкә мемориаль ачыла.

АВЫЛГА БӘЙЛЕ КЫЗЫКЛЫ ФОТОМӘГЪЛҮМАТ

Рамазан аена керер алдыннан (2008 елның 1 сентябренә кадәр), Кызыл Байракта Рөстәм Әхмәров үз умарталыгындагы бер ояда кортлар балавыз белән «язган» «Аллаһ» сүзен күреп ала. Тагы да кызыгы шунда: язу бал җыя торган кәрәздә түгел, ә бәлки кортлар беркайчан да «бал савытлары» ясамый торган диафрагмада барлыкка килгән. Бәхетенә күрә, авыл имамы Т.Ибраһимов та әлеге могҗизаның шаһиты була.

Әлеге могҗизаи рам хәзерге вакытта Рөстәм Үзбәк улы Әхмәровта саклана. Үз вакытында әлеге «табигый шамаил» белән «Татрстан-Яңа гасыр» каналы да кызыксына һәм, шул хакта сюжет төшереп, аны Рамазан ае көннәренең берсендә (14 сентябрь, 2008 ел) «7 көн» тапшыруында күрсәтә. ■

Хикмәтле язу

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

МУСА ПӘЙГАМБӘР – Коръәни һәм библияви шәхес. Яңа эрага кадәр 1570 елларда туган, дип фараз ителә. Ул Бәни-Исраилдан, ягъни Ягъкуб пәйгамбәр нәселеннән булган. Атасының исеме – *Гыймран*. Шуңа күрә ислами чыганакларда ул *Муса Гыймрани* дип тә телгә алына. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә Тәүрат («Тора») китабын иңдергән. Урысча Библиядә – *Моисей*. Борынгы гыйбрани телдә – *Моше*. Муса исеме инглизләрдә – *Мозес*. Алманнарда – *Мозе*, французда – *Моиз*, итальяннарда – *Мозе*, грекларда – *Мозес*.

Коръәндә сөйләнгәнчә, Мисыр патшасы залим *Фиргавен* яһүди ир балаларны үтерә торган булган. Мусаның әнисе Аллаһ әмере белән бишектәге баласын суга ташлый. Баланы Фиргавеннең хатыны Асия табып тәрбиягә ала, ә имезергә Мусаның үз әнисенә *(Йухабиз яки Иохаведа)* бирә. Яшь чагында Муса бер яһүд кешесенең мисырлы белән сугышына катнашып китеп, мисырлыны үтерә һәм *Мәдйанга* качып китәргә мәҗбүр була. Моның өчен Аллаһ Тәгалә Мисырга һәртөрле бәла-казалар җибәрә. Берничә елдан соң Муса кире Мисырга кайтырга чыга һәм юлында аңа бер утлы куакта (Библия мифологиясендә – утлы, ләкин янып бетми торган күгән агачы (терновник), «неопалимая купина») Аллаһ күренә. Аллаһы Мусаны үзенең илчесе, дип игълан итә, аңа Фиргавенне һәм Мисыр халкын бер аллалыкка күндерергә боера. Мусаның ярдәмчесе итеп аның туганы *Һарун* билгеләнә. Мисырга кайткач, Муса пәйгамбәр халыкка вәгазь укый башлый, үзенә Аллаһ биргән тылсым көчен күрсәтә. Шуннан соң Мусаның ватандашларын һәм Аллаһка иман китергән кешеләрне аяусыз төстә эзәрлекли башлыйлар. Фиргавеннең киреләнүе аркасында илгә коточкыч бәла-казалар ябырыла (барысы унау): 1) Нил елгасы суларының канга әверелүе; 2) гөберле бакалар ябырылу; 3) дөньяны черки басу; 4) эт чебеннәре басу, мал-туарны мур кыру, адәмнәрнең һәм терлекләрнең эренле шеш белән авыруы, боз аралаш ут яву; 8) саранча ябырылу; 9) дөм караңгылык басу; 10) Мисыр гаиләләрендә беренче балаларның, мал-туар арасында беренче үрчемнең кырылуы. Урысча чыганакларда болар *«десять казней египетских»* дип атала. Муса пәйгамбәр үз халкын

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Мисырдан алып чыгып китә. Фиргавен Мусаны куалый килә, ләкин аның гаскәрен Кызыл диңгез сулары йота (ә моңа кадәр диңгез суы, чигенеп, Мусаны һәм аның халкын коры җирдән үткәреп җибәргән була — *Исраил балаларының судан коры чыгуы* дигән сүз шуңардан калган). Синай (Тиһ) чүлендә адашып йөргәндә, Муса үз халкын тылсым көче белән ашата һәм эчертә (7:160; бу аятьтә Муса пәйгамбәр таягы белән ташка суккач, күктән *хәлвә* яки *мән* — манный ярма һәм сәлва — бүдәнәләр иңүе турында сөйләнә (татар телендә «күктән манный боткасы яву» гыйбарәсе бар, аннары Минзәлә сөйләшендә *әлбә* — манный боткасы); «Тәфсир Ногмани»да *ширбәт* вә *кош* ите иңдерелә), ләкин Муса Синай тавына китеп кабат Аллаһ белән очрашкан арада адәмнәре Аллаһтан ваз кичеп, бер самири ясап биргән алтын үгезбозау потына табына башлыйлар. Муса халыкны яңадан хак юлга күндерүгә ирешсә дә, аларны изге җиргә аяк басарга мәҗбүр итә алмаган, чөнки халык ул җирдә яшәүче әзмәверләрдән курыккан (7:149; 20:92 — 95).

Кайбер чыганакларда Муса пәйгамбәрнең Шөгаиб пәйгамбәр кызы Сафурага өйләнгәнлеге турында сөйләнә.

Мөселманнар Муса пәйгамбәрне Мөхәммәднең элгәре буларак хөрмәт итәләр. Ислами риваятьләрдә аның кулы күз камаштыргыч нур чыгарган, дип сөйләнелә (Муса үзенең кара тутлы кулын куенына тыгып алгач, аның кар шикелле ап-ак булганын күреп, Мисыр фиргавене тәмам куркуга төшкән). *Ак кул* яки *Муса пәйгамбәр кулы,* дигән гыйбарә бар. Риваятькә караганда, Муса сабый чагында авызына утлы күмер капкан булган һәм шуның аркасында сакау сөйләшкән, имеш. Кайбер чыганакларда «мөселман» сүзе Муса пәйгамбәр исеменнән килеп чыккан, дип күрсәтелә, ләкин дәлилләре миңа мәгълүм түгел.

Исламда *мусавилар* (болары — *яһүдләр*) соңга таба Муса пәйгамбәрнең васыятьләреннән читләшкәннәр, дип карала.

МУСА ТАЯГЫ — Әдәбиятта башкача *гаса* яки *карышкы* дип тә атала. Риваятьләргә караганда, бу таякны башта Адәм галәйһиссәлам оҗмах агачыннан кисеп ясаган һәм җәннәттән сөрелгәндә үзе белән алган, имеш. Адәм пәйгамбәрнең вафатыннан соң таяк аныңварисларына күчә килеп, Шөгаиб пәйгамбәр кулына кергән. Муса пәйгамбәр Шөгаиб пәйгамбәргә көтүче булып яллангач, ул аңа шушы таякны тоттыра һәм: «Фәлән үзәнлеккә көтүне алып барма, анда аждаһа яши, ул аждаһадан берәү дә котыла алмый», — дип кисәтә. Ләкин Муса көткән сарыклар качып киткәннәр, ничек кенә тырышмасын, ул аларны куып кайтара алмаган. Тәмам хәлдән тайгач, Муса җиргә ятып йоклаган, ә таягын үз янына куйган. Шулвакыт теге аждаһа оясыннан чыккан да сарыкларга ташланган. Аллаһ Тәгалә таякка аждаһага әйләнергә һәм явыз аждаһаны өзгәләп ташларга боерган. Таяк бөтенесен җиренә җиткереп үтәгән. Уянып китсә, Муса үзенең сарыклары исәнимин икәнен, ә таягының кан эчендә йөзгәнен күрә. Ул бу хәлләрне кайтып Шөгаибкә сөйли, Шөгаиб исә, халыкны җыеп килеп, Аллаһка корбан китерә.

Ашыйсы килгәндә Муса пәйгамбәр таягын җиргә ташлагач, шунда ук төрле-төрле җимешләре булган агач үсеп чыккан. Су кирәк булса, Муса пәйгамбәр таягы белән кыяга кагылуга, аннан су сиптереп ага башлаган. Юл йөргәндә таягы Муса пәйгамбәргә атны алмаштырган, төнге караңгыда таяк аңа юлны яктырткан, хәтта елга аша салынган күпергә дә әйләнгән. Таягы ярдәмендә Муса пәйгамбәр күктән хәлвә/ әлбә яудырган, дип сөйлиләр. ■



ШАМАИЛ

(ТР Милли музее фондларыннан)

ТР Милли музеенда XIX йөз ахыры-XX йөз башында басылган шамаилләрнең коллекциясе саклана.

Шамаил – Ислам диненең изге урыннары сурәтләнгән яки гарәп язуы белән матур итеп догалар, аятьләр, хәдисләр, нәсыйхәтләр язылган дивар картинасы. XIX йөз ахырына кадәр алар барысы да кулъязмада булып, кәгазьгә, пыялага, тукымага, керамикага ясалган.

Шамаилләр мөселманлыкны раслау, йорт-җирне җен-шайтаннан, хәвеф-хәтәрдән саклау вазыйфаларын үтәгән.

Гүзәлия Җәләлева *әзерләде.* ■

И ҖЫР ГЫНАМ, ҖЫРЫМ...

Георгий Ибушев

Ерактан, бик ерактан акрын гына бер җыр агыла. Аһ, бу нинди йөрәк өзгеч моң?!

Кайда ишеткәнем бар соң әле минем бу җырны? Нишләп әле ул минем җанымны шулай өтеп ала? Ул каядыр чакыра, дәшә, ымлый.

Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.

Күңелем сихерләнеп, моң агылган тарафка йөгерәм. Ул – якында... Бәгырьләремне телгәли, елыйсыны китерә... Елыйм, рәхәтләнеп үксеп-үксеп елыйм.

Һәр күзәнәгемне сихри наз иркәли, йөрәккә җылы нур коя. Бөтен күкрәкне тутырып, тирән итеп сулыш алам да: «Син кем, син кем?» – дип өзгәләнеп кычкырып, уянып китәм.

Карале, күзләремнән һаман яшь ага.
Безнең ил – уйнар, көләр җир, –

дип җырлаган матур йомшак тавыш бөтен Ястык урамын, югары очны чорнап алган. Яшьле күзләремне учларым белән угалап алам да, ниндидер бер булачак могҗизаны кабул итеп алырга әзер булган кебек, шушы моңлы агымга ияреп китеп барам.

Әй, язмыш, рәхмәт сиңа бу төнең өчен! Рәхмәт сиңа дүрт тәрәзле, җилкапкалы, салам түбәле өең, шул өйнең, әтинең иске тунына күмеп йоклаткан өйалдысы өчен!

Рәхмәт сиңа! Шыгырдап торган нык бүрәнәләрдән салынган зиннәтле өй эчендә, мамык юрганнарга чумып ятсам, миңа бу сихри аһәң кагыла алган булыр идемени? Мин аны ишетеп, төшләнеп, үксеп уяныр идемме? Юк, җыр, төнге

тынлык аша болын-тугайларга китеп таралып эрер яки кемнедер, башканы сайлап кагылып, назлап үтәр иде. Җыр, шушы төнне син мине иркәләп, ап-ак канатларың өстендә тибрәтеп, нәни җаныма, үзем дә аңлап бетерә алмаслык чиста моң салып, кире кайтардың. Халкым аһәңенә төрелгән көенчә, мин ул төндә беренче мәртәбә елата торган көч барлыкны, ул бетмәс көчнең йөрәк аша чыгып, яңадан кешеләргә сафлык, моң булып, аларны чистартырга, елатырга, авыр чакта көч бирергә әйләнеп кайтуын аңладым. Бу, җыр, син идең, син...

Безнең ил – сандугач сайрар җир...

Бөтен тирә-якны яңгыратып, шушы җырны аңлап, аны тагын да матуррак, тулырак итәргә теләгәндәй, чынлап та, сандугачлар сайрый иде. Мин үземне Ходай күктән иңдергән кодрәт астында калгандай хис иттем. Бакчадагы юкәләрдән хуш ис тарала, талгын җилдә аларның яфраклары, лепер-лепер килеп, «тыңла, тыңла», дип әйтәләр сыман иде. Мин тыңладым. Бу җыр әйтерсең лә моң ташып торган күңелдән генә чыгып калмый, бәлки, төнге күктән, Киек Каз Юлыннан күңелләргә, болын-тугайларга, урман-кулләргә җылы нурдай сирпелә иде.

Рәхмәт сиңа, язмыш, син миңа шушы төнне җыр бүләк иттең. Ул гади җыр түгел, ә бәлки, якты йолдыз сыман төнне яктырта алырлык нурлы җыр иде. Күпме еллар узса да, ул җыр мине һаман үзе белән яктылыкка, матурлыкка, чисталыкка әйдәп, ап-ак нурлы канатлары өстендә алып бара. Әллә нинди мин ишетмәгән, белмәгән, бары җаным белән сиземли, тоя торган җыр дулкыннары аша ерак үткәннәргә алып чыгып җанны тетрәндерерлек борынгы җырлар белән таныштыра. Шушы җырлардан әсәрләнеп китеп, шушы моң назыннан айнып өлгергәнче, болыннарга сыймастай булып җәелгән, тибрәнеп, дулкынланып торган җырын бoҗра түгәрәк уеннар эченә китереп төшерә. Миңа балачагымнан таныш, кадерле булган Раштуа, Нардуган, Олы көн, Торойсын кебек керәшен бәйрәмнәрендә йөртә, гаҗәеп матур җырдан гына торган керәшен туйларында шушы җырларның камиллегенә, гүзәллегенә сокландырып елата. Нинди асыл җырулар җырланыла бу бәйрәмнәрдә, туйларда. Нәкъ менә шунда җырланылган җырлар туганлыкның кадерен белергә, туган җирнең бөеклеген аңларга ярдәм итә. Шушы бөек могҗиза, җырның көче, сере нәрсәдә соң?

Җыр – әниләрнең безне дөньяга китергәндә кычкырган изге тавышы ул.

Җыр – таңнарның алсулыгы, чыкларның җемелдәве ул.

Җыр – сабыйларның көлүе, төркем-төркем күперенеп килгән ап-ак болытларның агымы ул.

Җыр – «сөям» дигән серле пышылдау, иреннәрнең иреннәргә кагылгандагы назы ул.

Җыр – җылы дулкын булып игеннәргә сарылган рәшә чыңы, чишмәләрнең челтерәве ул.

Җыр – серле төндә йолдызлар булып коелган керсез карларның аклыгы. Киек Каз Юлларыннан иңгән яктылык ул.

Җыр – минем, синең ярсып типкән йөрәк тибеше, халыкларны азатлыкка чакырып дәшкән көчле аваз ул.

Җыр – ятимнәрнең күз яше, тормышта адашканнарның, чит җирләрдә юксынганнарның сагышы ул.

Җыр – халыкларны халык иткән, аларны берләштергән, һәрберсенең үзенә генә хас төсмере ул.

Җыр – язгы җылы яңгыр астында хуш ис бөркегән сирень, шомыртларның шавы, кеше җанының бетмәс-төкәнмәс матурлыкка, чисталыкка, кешелеклеккә, изгелеккә ия булырга тиеш икәнлеген дәлилләүче бөек рух ул.

Җыр – берни белән дә чагыштырып булмаслык, кешеләргә бәһасез җан авазы итеп Ходайдан иңгән изге моң ул!

Әгәр дә мин өздереп, җыр менә шушы инде ул, дисәм, килешеп, ризалашып бетмәүчеләр дә аз булмас иде. Чөнки

җырны аңлаган, яраткан һәр кешенең җыр турында үз фикере, үз сүзе бар һәм бу бик дөрес тә, чөнки җыр бит ул – тере нәрсә, җан моңы. Шуңа күрә аны һәр җан үзенчә аңлый, үзенчә кабул итә.

Җыр ничек туа соң? Мин композитор түгел, ләкин, сиземләвем буенча, чын җыр бик тә бәхетле чакта яки өзелеп юксынганда, нәрсәдәндер кинәт кенә күңел нечкәреп, ташып киткән чакта туадыр. Җыр болай гына бер сәбәпсез тумыйдыр ул.

Җыр – кеше фикерен матур, нечкә итеп җиткерүче иң гүзәл, иң югары нокта ул. Без тормышта бер-беребез белән гади сөйләм телендә аңлашабыз. Күтәренке, саф хисләребезне шигъри юлларга күчерәбез. Ә инде шигъри тел белән дә аңлатып булмаган нечкәлекне бары тик җыр гына күңелләргә җиткерә ала. Шигырьдәге сүз ничек кенә көчле булмасын, ул әле матур, мәгънәле сүз генә. Әгәр дә шушы көчле сүзгә талантлы көй кушылса, җыр барлыкка килә. Җырның тәэсир итү көче сүзнекенә караганда күпкә көчлерәк аның. Телнең терәге һәм бизәге – җыр. Җыр барда тел, халык бар. Олы җырны башкарырлык җырчыбыз, аңларлык халкыбыз калмаса, ап-ак канатлы җыр бездән китәр. Ә милләт моңсыз, җырсыз яши алмый. Ләкин безнең җыр сәнгатебез гел моңлы, елак җырлардан гына торырга тиеш түгел, моңга гына салынып сагышланып ятсак, без бөтенләй йомшап, җебеп бетәрбез. Безнең җырларыбыз моң, сагыш белән бергә, күтәренке рухлы, тирән эчтәлекле һәм яңгырашлы булырга тиеш. Андый җырлар күбрәк булса, без үзебез дә җаныбыз белән чистарынып, яктырып, сафланып китәрбез. Менә ни өчен җырга бары тик күңел ачу өчен генә тудырылган нәрсә итеп карарга ярамый. Җырны аңлау өчен югары уку йортын тәмамлау кирәкми, ул безгә тумыштан бирелгән. Шуны тоя, ишетә белү генә зарур. Тыңла да җый: каеннар шавыннан, тургайлар җырыннан, кечкенә энҗедән, болын гөленнән – бары да җыр бит. Каеннарга сөеп, гөлләргә назлап карарга өйрән. Каенга бары тик буласы утын, болын гөлләренә, яшел хәтфәсенә печән итеп кенә караудан узмасак, күңел ничек гүзәллеккә омтыла алсын ди?! Матурлыкны тойган күңел генә яхшыдан начарны аера белә. Ә яхшы җыр безне олы музыка дөньясына алып чыгар, опера, симфония, балет белән таныштырыр. Бу өлкәдә белгечләр булмасак та, зур сәнгатькә җан белән кагылып алу бәхет түгелмени?! Почмактагы чаршау читеннән генә карап, «Сәнгатьнең бу төре безгә кирәкме, юкмы», – дип ятсак, «Безгә мөнәҗәттән башка берни дә кирәк түгел», – дип әйтүчеләр дә табылыр. Ә зур сәнгать ул — диңгез кебек! Шул диңгезгә курыкмыйча керсәк, башка халыкларның да күңел хәзинәсе белән танышырбыз. Күңелдә сакланып калган бишек җыры безне моң дәрьясына алып керсә, зур сәнгать дөньясына да юл ачылыр.

Ап-ак канатларыңны җилпеп-җилпеп оч, күңелләргә өмет, ышаныч бир, җыр! Безгә, кешеләргә, бәхет, тугрылык, сөю, матурлык турында җырла! Матурлыкка, чисталыкка сусаган җан шушы серле дөньяга тартылып торсын.

Олы җыр – сер дә әле ул. Беркайчан да ачылып бетмәячәк татлы сер. Җырның тагын бер бөек көче – аның серлелегендә. Менә шушы серлелек башкаручы йөрәге аша узып, таныш, бик тә таныш җырга да яңа яңгыраш, яңа бизәкләр өстәп, таң калдыра, кешедә ләззәтләнү, рәхмәт хисе тудыра.

Рәхмәт сиңа, җыр, рәхмәт! Синең телеңне, әйтер сүзеңне аңлый алу зур бәхет ул. Бәхет ул – яраткан эшеңдә, сәнгатьтә горурланып, чиста намус белән кеше күзенә карый алуда, үзеңне кеше итеп тоюда һәм күңелеңдә син йөрткән олы җырда.

Авторның искиткеч матур тел белән язылган әлеге эссе-уйлануын сайтыбыздан — www.beznenmiras.ru тулысынча укый аласыз.



БЕЗНЕҢ ИЛ

Илеңнән еракта чит җирдә
Бик авыр, дусларым, күңелгә.
Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.
Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы.

Таңнарын сагындым, ай, җилен,
Агышын, шаулавын Иделнең.
Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.
Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы.

Түзмәдем: ашкындым, талпындым –
Моңнары чакырды халкымның.
Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.
Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы.

Автордан: *Бу җыр 1985 елда туды. Аның нигезендә керәшеннәрнең «Безнең ил» исемле җыры ята. Минем шушы җырга таянып, киң диапазонлы, иркен яңгырашлы җыр тудырасым килде. Ике-өч ай тырышканнан соң минә шушы «Безнең ил» җыры иҗат ителде.* ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның ноябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Казанда мөселман хәстәханәсе

Ошбу ел эчендә булындыкмыз немец сугышы гомуми ватан сугышыдыр. Бу сугышның мәшәкатен вә агырлыкын гомуми ватан халкы каю диндә булсалар да гали әл иштирак[1] күтәрмәк, вә һәркаюсы иттифакъ илә хөкүмәткә булышмак, вә ватанны сакларга тырышучы гаскәрләргә ярдәм итешмәк лязимдер. Бу лөзүм [кирәклек] ялгыз мөрәүвәт [егетлек] лөзүме генә түгел, шәргый лөзүм, сәяси лөзүм, әдәби вә иҗтимагый лөзүм вә бурычтыр. Ошбу лөзүм вә бурычны Казан халкы яхшы аңлап, һәркаю иганә шөгъбәләренә [бүлекләренә] кушылулары өстенә, үзләре тарафыннан махсус бер хәсәтәханә ачып егерме мең сум кадәр хәраҗат [чыгымнар] илә бер ел кадәр дәвам иттерделәр. Һиммәтле байларымыз, гайрәтле егетләремез, һиммәтле ханымнарымыз иҗтиһадлары илә хәстәханә яхшы рәвештә аякка басты, яхшы рәвештә дәвам итте. Мәзкүр егерме мең сум кадәр парә [акча] октябрь башында тәмам булды. Октябрь башыннан бирле хәстәханә яңа хисапка идарә ителә. Шимди мөселманнар өчен тиешле вазифа: алдымыздагы сәнә өчен тиешле хәреҗлек [чыгымлык] кирәк кадәр мәсариф [акча] хәзерләмәктер. Бу хәстәханә биш-ун адәм бурычы түгел, анларның гына муеннарына төшкән вазифа түгел, бәлки гомуми мөселманнарның, хосусән [бигрәк тә] Казан вә әтрафында булган мөселманнарның шәргый вә сәяси, вә әдәби вазифаларыдыр.

Без мөселманнарның янә бер елга кирәк булган егерме биш мең сум кадәр акчаны юнәтерлек, юнәтүдә булган мәшәкать вә хезмәтләрне күтәрерлек хәлебез вә кешебез бар. Һәркем үз намусын саклап, мондый мәсьәләләрдә кыска хисапламыйча, алдын вә артын уйлап, яхшы иҗтиһад итмәк тиеш. Үзенең вә милләт әүляденең [улының] оятка калмакыннан разый булмаенча, мондый гына аз-маз агырлыкны күтәрешмәк тиештер.

Якын көннәрдә ошбу хәстәханәмез өчен комитетымызның мөнасиб [тиеш] күргән рәвешенчә иганә тупланачак. Һәркаю мөселман икътидарынча [булдыра алганча] ярдәм итешергә, агыраймаенча хезмәт иткән, эш артыннан йөргән затларның кадерләрен белеп, кирәгенчә ярдәм итүләре бабында хәер хаһ [теләктәш], ләкин җитди сурәттә тәүсыя [киңәш] итәм.

Мөселман хәстәханәсенең комитеты рәисе мелла Галимҗан Мөхәммәтҗан әл-Баруди.

Кояш. — 1915. — №834. — 1 нояб.

6 нчы номерлы вагон

Алма базарыннан (Печән базары каршындагы станция янында) шәһәр театры артына кадәр йөри торган 6 нчы номерлы трамвай вагоны, хәзер инде шул ук алма базарыннан китеп, Арча кырына бара вә шушы ике арада йөри башлаган.

Кояш. — 1915. — №839. — 8 нояб.

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Гали әл-иштирак — бөек булган уртак гамәл.

Мәктәп комиссиясендә

Шәһәрнең мәктәпләр комиссиясенең соңгы мәҗлесендә түбәндәге карарлар кабул ителгән[2]: 1) Мөселманча вә русча укытыла торган 3 нче мәктәпкә параллель сыйныф ачарга вә бу сыйныф өчен инспектордан мөгаллим күргәзүен сорарга; 2) Александровский һөнәр шурасына шәһәрдән вәкил итеп С.В.Шмилёв белән Габделхәмид Апанаевны сайларга һәм Габделхәмид Апанаевка мөселманнарга балаларын һөнәр мәктәбендә укытырга тиешлеге фикерен мөселманнар арасына таратуны вә балаларын шушы мәктәпкә бирергә димләүне тапшырган; 3) Шәһәрнең мәктәпләргә мәркәз мөтәвәллилек[3] әгъзалыгына М.Н.Пинегин белән Габдулла Йосыф углы Апанаевны, наиб [урынбасар] итеп Садри Максудовны сайлауны мәслихәт санаган.

Кояш. — 1915. — №840. — 9 нояб.

Идарәи бәйтия

Кызлар мәктәбенең һәрберсенең программасында идарәи бәйтия[4] фәне булса да, бу фәннән кулга тотып укытырлык юньле бер китап булмаганлыктан, мөгаллимәләргә бик зур кыенлыкларга төшәргә тугры киләдер иде. Менә «Сөембикә» идарәсе мөгаллимәләрнең бу китапка ихтыяҗларының зурлыгын сизгәч, бу бабтагы мөтәхассыйсларның [белгечләрнең] әсәрләреннән интихаб белән [сайлап алып], берничә мөгаллим вә мөгаллимәләрдән махсус заказ биреп эшләттерде. Бу китапны алып укыган ханым йорт идарә итүдә һичбер кыенлык күрмәячәктер. Бу китапта тора торган өйнең һавасы, корылыгы, юешлеге, пакьлеге, ягу нәрсәләре, өйне яктырту, җылыту, өйне җиһазлау, җыештыру, кәнлек, айлык, еллык җыештыру, йокы бүлмәсе, балалар бүлмәсе, кабинет, кунак бүлмәсе, зал, мебель сайлау, ашханәне карау, ашханәдә кирәк савытлар, кирәкләр, аларны тазарту, җәйге киемне кышка, кышныкын ничек җәйгә сакларга, йогышлы авырулардан саклану чаралары, кинәт авырган кешегә ярдәм итү, өй аптекасы вә башкалардан ачык кына итеп мәгълүмат биреләдер.

Кояш. — 1915. — №841. — 10 нояб.

Татарча театр

Җомга көн «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан уйналган татарча театр яхшы гына күңелле үтте. Миһманнар [кунаклар] күп иде. Уйнаучылар, кыскача гына әйткәндә, тырышып, берегеп уйнадылар. Тавышы зәгыйфьләнгәннән, соңгы уйнауларында тавышы ишетелмәү сәбәпле, миһманнарны ялыктыргалаган Кариевның тавышы бу юлы яхшы ук төзәлгән иде, хәтта бүтән уйнаучылар тавышыннан да ачыграк ишетелеп торды. Сүз арасында шуны да әйтергә тугры килә ки, Большой театр кеби биек бинада уйнаганда, сыкрану вә сызлану урыннарында уйнаучыларның тавышны кысулары бик үк мәслихәт түгел икән. Хәзерге уенда Шәфика туташның сыкрануларда истигъмаль [кулланган] иткән аһәңен шул җөмләдән санарга мөмкиндер. Бүтән урыннар гомумән шома гына үтте.

Кояш. — 1915. — №845. — 15 нояб.

---

[2] Бирелә 6 пункт булып, шуларның татарларга нисбәтлеләрен генә тәкъдим итәбез.
[3] Мөтәвәлли — мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кеше.
[4] Идарәи бәйтия — йорт эшләрен башкару.

Көлке куа килә...

Шаман (Шамил Маннап)

«КИРӘКМӘС ШУЛ!..»

Бер юбилеенда Сибгат Хәкимгә Казан мехчылары бик әйбәт, бик затлы бүрек бүләк итә. Моны башына ук кидереп куялар.

Юбилей кичәсенең концерт өлеше башлана. Әдипне җырчылар, шагыйрьнең үзе әйтмешли, «үз җыры белән сыйлый» башлыйлар. Алып баручы чираттагы җырның исемен әйтә: «Башка берни дә кирәкми...»

Шулвакыт залдан Нәби Дәүлинең карлыгулы-томат тавышы яңгырап ишетелә:

— Кирәкмәс тә шул! Шундый шәп бүрек бирсәләр, минем дә башыма берни кирәкмәс иде!..

Гөргөри (Гәрәй Рәхим)

Ә СИН КИЛДЕҢ...

Миргазиян Юныска

Без гади авыл малае...
Зур дөньяга күтәрелдек
Без абзар артларыннан.
Ә син килдең ераклардан,
Ак канатлы корабларда —
Занзибар якларыннан.

Сәяхәтләрдән кайттың да
Син каләм алдың кулга.
Сәнгатьтә дә, әдип, шул ук
Миргазян булып кал син
Тик миргә зыян булма!

З.Хәйруллин шаржы

Фәнзаман Баттал

Фәнзаман Баттал

БУЛМАДЫ!..

«Әйбәт булыгыз, балалар,
Үсегез тәүфыйк җыеп.
Яшәгез бер-берегезне
Яман эшләрдән тыеп»...

Шулайлар, диеп үстердем,
Бирдем гел яхшы үгет.
Өметләндем: «Һәркайсы да
Булыр вәйт дигән егет!»

...Әй эчәләр, сугышалар,
Куналар айныткычта.

Эшләмиләр, урлашалар,
Талыйлар, җае чыкса.

Ысбулычлар, сабакылар! —
Өметемне кистеләр.
Кеше итәргә тырыштым —
Үзем булып үстеләр.

2002

Морат Дусай (Марат Закир)

ЛИМИТ

Шагыйрь Зиннур Мансуров — аз сөйләп, күп эш башкаручы шәхес.

Бервакыт аңа язучылар җыенында рәислек итәргә туры килә. Теләсә дә, теләмәсә дә, рәис байтак кына тел тибрәтергә мәҗбүр була.

Бу җыеннан соң Зиннур әфәнде өендә бер атна чамасы сөйләшмичә йөри.

— Ни булды сиңа, этисе? — дип сорый икән аннан хатыны Роза ханым.

— Бер көндә бер айлык сүз сарыф итеп карале башта! — дигән аңа шагыйрь.

Зөлфәт

И.Хантимеров шаржлары

Афзал Шамов

Риза Ишморат

АФЗАЛ ШАМОВКА

Сүзләр сирәк төшә, юкса
Каләм төшмәгән кулдан —
Хәтта ки Афзал Шамов та
Язган заманнар булган!

РИЗА ИШМОРАТКА

Заман әйтә: «Пьеса сюжетларын
Гел минемчә шулай иш, брат!»
Заман әйтсә, дөрес әйтә инде,
Нишләсен соң Риза Ишморат...

Туфан Миңнуллин

ГИМН

Татарчасы бик чамалы обком секретаре Мөҗәһит Фәтхиевич Вәлиев «Моңлы бер җыр» спектаклен карарга килде. Ахырына хәтле утырды. Спектакльдән соң аның фикере белән кызыксындык.

— Что за песню поют они? — дип, җәлилчеләр бергә җыелып җырлаган җырның исемен сорады.

— Татар халык көе «Сибелә чәчәк», — дидек.

— Вот уж не думал, что народная песня звучит как партийный гимн, — дип шаккатты Мөҗәһит Фәтхиевич.

Тәлгат Нәҗмиев

СӨЕНЕЧ УРТАКЛАШУ

Мөслим редакциясенең бер хезмәткәре һич көтмәгәндә эш бүлмәсеннән каләмкяр Рөстәм Зарипов белән мөхәррир-журналист Мөдәмил Әхмәтов каршына атылып чыккан да, эчендәге шатлыгын уртаклашырга ниятләптер инде, болай дип тезеп киткән:

— Күрче, Мөдәмил, минем сеңлем кияүгә чыкты бит. Фотолары шундый матур! Бер генә карап ал инде.

Мөдәмил бер күзен кысып кына караган да:

— Исән-сау барып кайтсын инде! — дип елмаеп куйган.

Салих Сәйдәшев турында мәзәкләр

Рабит Батулла

ӘЙТЕРГӘ СҮЗ КАЛМАГАЧ

Бервакыт Салих Сәйдәшевкә, артистлар җитмәү сәбәпле, роль бирәләр. Салих ага, рольне ятлап, спектакльгә килә. Сәхнәгә кереп сүзләрен әйтеп бетерә дә кайтып китә. Театр баскычыннан төшеп барганда, моңа режиссёр Кәрим Тинчурин очрый:

— Кая барасың, Салих? — ди режиссёр.

— Өйгә! — ди Сәйдәш.

— Синең сәхнәгә чыгып сүз әйтәсең бар бит әле! — ди Тинчурин.

— Мин сәхнәгә чыктым, сүзләремне әйттем! — ди Салих.

— Тагын өч тапкыр чыгасың бар бит әле, — дигәч, Сәйдәш:

— Бер чыккач, мин барысын да әйтеп бетердем инде, әйтергә сүзем калмады! — дигән ди.

***Мәрзия Миңлебаева** сөйләгәннән.*
1983, май

РОЯЛЬ АСТЫНДА

Яңгыр яуса, Сәйдәш фатирында коры урын калмый: түбәдән үткән яңгыр бөтен дөньясын баса икән. Йокларга коры урын таба алмагач, Сәйдәш рояле астына кереп йоклый ди. Шулай рояль астында йоклап ятканын күргәч, дуслары Сәйдәштән:

— Син нишләп рояль астында йоклыйсың? — дип сораганнар.

— Рояльнең өстендә йокламам бит инде! — дигән Сәйдәш.

***Гыйбадулла Хәбиб** сөйләгәннән.*
1983 ел, 25 август

СӘЙДӘШ ТАРАГЫ

Сәйдәшнең чәче матур булып күпереп тора торган була. Шулай да ул һәрвакыт:

— Җегетләр, тарак онытылган, берәрегездә тарак юкмы? — дигән була да үзе кешедән тарак алмый икән:

— Һәй, гафу итегез, үз тарагым табылды, — дип биш бармагы белән чәчен сыпырып җибәрә икән.

***Гыйбадулла Хәбиб** сөйләгәннән.*
1983 ел, 25 август

ӨЧ ШАРТ

Сәгыйть Кашапов атлы бер адәмне күргәч, Салих Сәйдәш:

— Нигә кашың җимерек? Әллә авырыйсыңмы? — дип сораган.

— Авырмыйм ла, — дигән Сәгыйть, — хатын әрли. Иртән гауга, кич гауга. Саласың, ди.

— Сәгыйть, синең яшь балаң бармы әле?

— Бар.

— Җылакмы?

— Җылак.

— Алайса, син хатыныңа чи усак утыны алып кайтып аудар!

— Нигә?

— Хатынны өч нәрсә картайта: исерек ир, җылак бала, чи утын! Картайган хатын күп сөйләшә алмый ул!

***Нияз Акмал** сөйләгәннән.*
1988 ел, 2 июнь ■

Мирасворд

... Дәүли

Элмәк кидерү өчен аркылы агач

Борынгы төрки халык

... Сафиуллин (баянчы, композитор)

Алтын Урда шәһәре

Ыргыту, ташлау

Себерне яулаган казак атаманы

Алтын Урда чоры шагыйре

... - клуб

Самара өлкәсендәге татар авылы

Шандор ... (мажар шагыйре)

Россия автомобиле

... Бәшири

... Бәширов

Борынгы Рим армиясендә ярдәмче атлы гаскәр

Корычагач

... Гыйләжев

Җеп эрләү җайланмасы

Һәрвакыт, гел (иск.)

Эре бөртекле әйберләрне төеп ваклау өчен махсус савыт

Актер ... Фазылҗан

Бер дә, һич тә (иск.)

«Татар ...» (Рәфикъ Юныс китабы)

Хөсәен ... (тарихчы, филолог, мөгаллим)

... Шәриф

Борынгы грек математигы

Агач чиләк (диал.)

Өч мачталы, җилкәнле борынгы хәрби кораб

1906 елда Уральскида чыккан татар журналы

... Фукс

1907-1908 елларда Казанда чыккан газета

Совет автомобиле

... Гафури

Р.Киплингның «Джунгли китабы»ндагы бүре

Фәйзелхак ... (тарихчы, дин галиме)

Габдулла Тукай шигыре

Татар ханлыкларында олыс, өлкә идарәчеләре титулы

Оркестрга кушылып бер генә кеше җырлый торган әсәр

Пистолет

«Таңбатыр», «Үги кыз»

Рәис Габдулла төзеде.

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: кашбау, Фет, Халиди, үги, Иден, Гак, Буа, алпак, иена, Күк, Окс, Күлтәси, Әмир, «Ниса», лама, Кояш, беләзек, алафа, Ивик, дрил, арыну, «Ка», ал, Раиф.

Өстән аска: какча, Галәү, лира, ясавыл, Такташ, фин, Сафа, күәс, Лука, килеш, кси, ибтидаи, инде, дегет, Мутин, Әлмәндәр, басма, ту, Ким, Еники, агора, фал.

Бертуган Шакир һәм Закир (Дәрдемәнд) Рәмиевлар даими матди ярдәм күрсәтеп торган «Хөсәения» мәдрәсәсе һәм мәчете бинасы. Оренбург. XX гасыр башы

«Безнең мирас»

елъязмасы /ноябрь

● 185 ел элек (1830)

Атаклы фабрикант Әсфәндияр Акчурин (1830-1903) дөньяга килә.

● 120 ел элек (1895)

Күренекле милли сәясәтче Ильяс Алкин (1895-1937) дөньяга килә.

● 110 ел элек (1905)

26 ноябрьдә Уральскида (Жаек) татар телендә беренче демократик «Фикер» газетасы (1905-1907) чыга башлый.

● 85 ел элек (1930)

2 ноябрьдә Казанда Идел буе милләтләре вәкилләренең киңәшмәсе ачыла.

10 ноябрьдә Донбасста татар телендә «Пролетар» дип аталган газета нәшер ителә башлый.

● 80 ел элек (1935)

1 ноябрьдә Мукден каласында (Кытай) татар мөһаҗирләренең «Милли байрак» исемле газетасы чыга башлый.

● 75 ел элек (1940)

17 ноябрьдә тел галиме, профессор Хуҗа Бәдигый (1887-1940) вафат була.

● 60 ел элек (1955)

28 ноябрьдә шагыйрь Әхмәт Исхак (1905-1991) илле яше тулу уңаеннан СССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

● 50 ел элек (1965)

11 ноябрьдә татар совет шагыйре Зыя Мансур (1916-1965) вафат була.

24 ноябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» пьесасы буенча эшләнгән спектакль сәхнәгә куела (режиссёры — Хөсәен Уразиков). ■

Абрек Абзгильдин

Абрек Әмир улы Абзгильдин 1937 елның 1 мартында Башкортстанның Баймак шәһәрендә туа. Казан сәнгать училищесын (1965), В.И.Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтын, К.П.Тутеволь җитәкчелегендәге монументаль нәкыш сәнгате остаханәсен (1970) тәмамлый.

Абрек Абзгильдин — 1993-2007 елларда ТР Рәссамнар берлеге рәисе, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1997), Татарстан Республикасының халык рәссамы (1995). «Бакый Урманче» (1989), «Дәрдемәнд» (1997), «Салих Сәйдәшев» (2000) портретлары авторы.

Рәссам 2013 елның 24 декабрендә Казанда вафат була.

Тукайның төше. 1980. Киндер, майлы буяу

Бакый Урманче. 1989. Киндер, майлы буяу

Уйна, гармун. 2006. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА:

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ. «МӘДРӘСӘ ҖИМЕШЕ»
ҖӘҮДӘТ МИҢНУЛЛИН. «КЕМ УЛ – ЗАКИР ГАЛИЕВ?»
ФӘНЗАМАН БАТТАЛ. «КОЛХОЗЛАШТЫРУ»
ЗӘКИ ЗӘЙНУЛЛИН. «ИЗГЕ КАПКА КЫЙССАСЫ»
АЛЬБЕРТ ХӘСӘНОВ. «ФӘНИС ЯРУЛЛИН ТУРЫНДА БЕР ИСТӘЛЕК»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:

• www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә – 498 сум

• редакциядә – 380 сум

• www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия – 350 сум

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» АҖ бинасындагы китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172

№11 / 2015